МИНИСТЕРСТВО ОБРАЗОВАНИЯ И НАУКИ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ГАПОУ «МЕНЗЕЛИНСКИЙ ПЕДАГОГИЧЕСКИЙ КОЛЛЕДЖ
ИМЕНИ МУСЫ ДЖАЛИЛЯ»
РЕСУРСНЫЙ ЦЕНТР ПО ПОДГОТОВКЕ НАЦИОНАЛЬНЫХ КАДРОВ



IX Республиканская научно-практическая конференция имени Мусы Джалиля, посвященная Году науки и технологии в Российской Федерации и Году родных языков и народного единства в Республике Татарстан, среди обучающихся и учителей общеобразовательных школ, студентов и преподавателей профессиональных образовательных организаций Республики Татарстан

# МАТЕРИАЛЫ КОНФЕРЕНЦИИ

Мензелинск, 2021

УДК 004.9, 377, 372.8
ББК 74.47, 74.48, 74.2, 74.1
**Составитель:** Талипова Г.Ф., заведующий по национальному образованию ГАПОУ “Мензелинский педагогический колледж имени Мусы Джалиля”
**Научный консультант, редактор:** Галиева Л.А., кандидат филологических наук, заместитель директора по национальному образованию МБОУ “Гимназия” г. Мензелинск
**Ответственный за выпуск:** Талипова Г.Ф., заведующий по национальному образованию ГАПОУ “Мензелинский педагогический колледж имени Мусы Джалиля”
**Технический редактор:** Шарифуллина Г.Н., преподаватель информатики ГАПОУ “Мензелинский педагогический колледж имени Мусы Джалиля”

Материалы IX Республиканской научно-практической конференции имени Мусы Джалиля (15 февраля 2021 года, Мензелинск). – Мензелинск, 2021. - 204 с.

**Оглавление**

*Аглиуллин М.М.* Использование средств языковой выразительности, на примере стихотворений М. Джалиля ........................................... 6

*Алеева Г.У.* Иҗтимагый сәяси үзгәрешләр һәм бердәм информация-мәгълумат киңлеге шартларында татар терминологиясе үсеше........... 8

*Алеева Г.У.* Общеалтайский пласт татарского языка (на примере общественно-политической лексики)........................................... 12

*Арсланова С.С.* Әдәби әсәрдә сурәтләү чараларының куллану үзенчәлеге (Муса Җәлилнең "Илдар" либреттосы мисалында)........... 18

*Арсланова Г.М., Хаҗиева Р.Р.* Аяз Гыйләҗев иҗатында диалектларның кулланылышы............................................................... 25

*Әхмәтҗанова Х.Ә.* Халыклар дуслыгы һәм татар әдәбиятында бу теманың чагылышы............................................................ 29

*Березина Н.Н.* Средства художественной выразительности в рассказе В.М.Шукшина «Выбираю деревню на жительство»........................ 36

*Бокова В.Л.* Особенности использования средств языковой выразительности (экзотизмов, варваризмов, диалектизмов, профессионализмов, жаргонизмов) в художественной литературе и их роль в произведении............................................................ 40

*Бутакова Г.С.* Татар һәм рус әдәбиятында халыклар дуслыгы чагылышы темасы........................................................................... 45

*Габдуллина Г.М.* Әдәби әсәрләрдә (экзотизм, варваризм, диалектизм, һөнәрчелек, жаргоннар) сурәтләү чараларын куллану үзенчәлекләре һәм аларның әсәрдәге роле........................................................................ 51

*Галиева И.М., Шайсуварова Л.Х.* Удивительное – рядом.................. 55

*Галимова Ф.А.* Туфан Миннуллин иҗатында халыклар дуслыгы мәсьәләсе.................................................................................... 58

*Галәветдинова Л.Р.* Нурзия Мирхазованың «Үтәлмәгән вәгъдә» әсәрендә сәнгатьчә бизәү чарасы буларак мәкальләр...................... 66

*Гыйлаҗетдинова Г.М.* Галимҗан Ибраһимовның "Казакъ кызы" романындагы экзотизмнарның лексик-семантик катламнары .......... 71

*Гыйльметдинова И.М., Зиязиева Р.Ш.* Ф. Латыйфиның «Хыянәт» романында татар халкының милли характер үзенчәлекләре 74

*Ибрагимова Ф.Г.* Ислам и мусульмане в литературе…………………… 77

*Ильина Д.Р.* Т.Миңнуллинның “Гөргөри кияүләре” комедиясендә тел-стиль чаралары........................................................................................ 83

*Исламова Л.Ф.* Отражение темы дружбы народов в татарской и русской литературе…………………………………………………………… 89

*Камалова З.Ә., Гизетдинова Г.Т.* Татар әдәбияты дәресләрендә милли үзенчәлекне исәпкә алып эшләү алымнары............................................. 95

*Лукьянова И.В.* Отражение темы дружбы народов в татарской и русской литературе.................................................................................................. 97

*Мадиева Т.А., Багманова Н.М.* Система образно-выразительных средств в либретто Мусы Джалиля «Алтынчэч». Муса Җәлилнең «Алтынчәч» либреттосында образлы сурәтләү чаралары……………………………… 102

*Маслова Э.Ф., Глухих А.У.* Личные имена собственные в романе Л.Улицкой «Даниэль Штайн, переводчик» как отражение историко-культурных изменений в языке............................................................... 104

*Мельников А.П., Юлдашева Л.М.* Отражение темы дружбы народов в татарской и русской литературе............................................................ 109

*Назмутдинова Ч.М., Шайхразиева Г.Р.* Гаяз Исхакый иҗаты үрнәгендә татар әдәбиятында халыклар дуслыгы...................................................... 115

*Нуриева Л.Ф.* Татар әдәбиятында халыклар дуслыгының чагылышы....... 120

*Романова В.Г., Мухамадеева Р.М.* Тема дружбы народов в повести татарского писателя Наби Даули............................................................. 123

*Романова Г.Н.* Тел мәсьәләләре................................................................. 130

*Сабитова З.А.* Исследование противоречивых точек зрения на жизнь и творчество героя – поэта Мусы Джалиля................................................. 137

*Сахапова Л.Ф.* Актуальные проблемы обучения татарской литературе и особенности использования средств языковой выразительности через проектно-исследовательскую деятельность студентов............................ 140

*Сулейманова А.Э.* Использование просторечных и жаргонных слов в рассказах М.М. Зощенко........................................................................ 145

*Титова Н.М.* Тюркизмы в русском языке.................................................. 151

*Төхфәтуллина Ә.Г.* М.Мәһдиевнең “Без – кырык беренче ел балалары” повестенда юмор тудыру чаралары .......................................................... 158

*Хамаева Г.Ә.* Татар әдәбиятында әдәби чаралар куллану һәм аларның әһәмияте (Экзотизмнар, варваризмнар, диалектизмнар, профессионализмнар, жаргоннар)............................................................. 163

*Хәйруллина И.М., Талипова Г.Ф.* Камил Кәримов әсәрләрендә һөнәрчелек лексикасының кулланылышы............................................ 171

*Хуснуллина З.М.* Муса Җәлилнең “Алтынчәч” либреттосында күчерелмә мәгънәдәге сүзләрнең кулланылыш үзенчәлекләре.................................. 174

*Шәйдуллина Ф.М., Заһирова Г.М.* Мөхетдин Корбангалиевнең татарларда аваз методын фәнни нигезгә салудагы эшчәнлеге................ 179

*Шәймарданова М.К.* Минем уйлануларым................................................ 185

*Шайхатарова Э.Г.* Халыклар дуслыгы – әдәбиятлар дуслыгы (Зариф Бәшири иҗатында милләтара дуслык темасы “Чуаш кызы Әнисә” мисалында)........................................................................................ 191

*Шаһиева Н.М.* Хисаметдин Исмәгыйлевнең “Никах” повестендә тел-стиль үзенчәлекләре 197

*Юсупова Г.Ф.* Алынмалар белән чуарланган әдәби тел........................... 199

# Использование средств языковой выразительности, на примере стихотворений М. Джалиля

*Аглиуллин Марс Маратович,*
*преподаватель родного языка и иностранного языка (английский,*
*ГАПОУ «Альметьевский торгово-экономический техникум»*

Одним из актуальных аспектов обучения родному (татарскому) языку и литературе в образовательном процессе является формирование образности речи учащихся. Особую роль в этом процессе играет изучение изобразительных средств речи, которые выступают и как способ познания нового, и как форма осмысления окружающей действительности, и как логическая модель построения языковых структур. [1]

Студенты практически не пользуются образными средствами языка для придания речи выразительности, яркости. Причиной этому является отсутствие специальной работы на занятиях родного (татарского) языка и литературы по обогащению речи учащихся изобразительными средствами.

На занятиях уделяется явно недостаточно внимания речевому развитию учащихся. Эстетический аспект художественных текстов, используемых при обучении, рассматривается крайне редко. Изучаемая на занятиях грамматика не может быть только описательной. Она должна быть функциональной, действенной, чтобы служить достижению главной цели обучения – речевому развитию студента. [2]

Само по себе использование художественного текста в качестве дидактического материала ещё не ведёт к поступательному развитию навыков оценки и употребления в речи выразительных средств языка. Практика показывает, что необходима специально организованная работа, направленная на развитие «способности оценить эстетическую ценность текста, объяснить языковые истоки его образности и выразительности» у студентов.

Таким образом, комплексный подход к рассмотрению фактов и явлений языка на материале художественного текста является наиболее важным для

обучения, поскольку, он готовит студента к тому, чтобы «читать художественное произведение филологически вооруженным глазом».

На занятиях по родному (татарскому) языку и литературе делается акцент на художественные произведения известных писателей, поэтов. Одним из таких часто рассматриваемых является Муса Джалиль (Муса Мустафович Залилов). Читается его биография, его произведения. Также делается анализ на некоторые стихотворения. При анализе рассматриваются средства художественной выразительности, определяется их роль в произведении.

Внимание привлекает то, что в стихотворениях поэт много использует:

- эпитеты («бессильных женщин», «худеньких ребят» - «Варварство»; «вольный сквозняк», «каменные своды» - «Последняя песня»);

- метафоры («душа крылатая», «плещет дождями свобода» - «Последняя песня», «оседает в траве не роса, невинные слёзы цветов» «Волки»);

- сравнения («и берёза качалась над ним, словно мать убивалась над ним» - «Волки»);

- олицетворения (пленные руки, лица цветов, слабеющие слова, объятия света - «Последняя песня»; «плакали…реки», «в ярости рыдала мать-Земля» - «Варварство»), [3]

- разговорную лексику («топчется», «попятился» - «Случай в подъезде»).

Также в своих произведениях Муса Джалиль использует, но реже, такие средства языковой выразительности, как:

- экзотизмы («Мы встретимся и будем пить кумыс, И наши песни петь за чаркой» - «Утешение»;«Знаю, в песне есть твоей, джигит,Пламя и любовь к родной стране» - «О героизме»);

- варваризмы («С кличем «Рот фронт», колоннами, маршем, Правый кулак подняв на ходу!» - «В стране Алман»),

- профессионализмы («Вот одной перестрелки цена!Вот ночной урожай батарей!», «Люди в тело загнали сперваРаскаленные шомпола» - «Волки»; «Враг скрутил ему руки веревкой, И погнал его в тыл под бичом» - «Раб»);

- жаргонизмы («Рыщут волки всю ночь напролет» - «Волки»). [3]

С помощью них он пытается передать читателю дополнительный, скрытый смысл своих произведений.

СПИСОК ЛИТЕРАТУРЫ:

1. Быстрова Е.А. Коммуникативная компетенция методика в преподавании родного языка // Русский язык в школе. – 1996. – № 1. – С.20-23.

2. Голуб И.Б., Розенталь Д.Э. Занимательная стилистика / И.Б. Голуб, Д.Э. Розенталь. М.: Просвещение. – 2013. – 207 с.

3. Муса Джалиль. Избранные произведения / Р. Мустафин. — Издательство «Советский писатель». Ленинградское отделение, 1979.

Назад

## Иҗтимагый сәяси үзгәрешләр һәм бердәм информация-мәгълумат киңлеге шартларында татар терминологиясе үсеше

*Алеева Гульназ Усмановна,*
*преподаватель родного языка и литературы,*
*ГАПОУ ККСАГХ, г.Казань*

Икътисади, социаль-сәяси һәм рухи-мәдәни үсешнең төп этаплары БДБ илләрендәге, шул җөмләдән Россиядәге һәм аның аерым регионнарындагы, шул исәптән Татарстандагы, шулай ук якын һәм ерак чит илләрдәге милләтара, телара мөнәсәбәтләрнең камилләшүе белән органик бәйләнештә тора. Дәүләтара, милләтара һәм тел ара мөнәсәбәтләрнең хәзерге заман рухында яңарышы төрле төзелешле телләрдә гомумлексик, гомумтерминологик фондның формалашуын күздә тота [1, 31]. Бу лексик терминологик фондның оешуы, үсеше телләр һәм җәмгыять үсеше кануннары нигезендә дәвам итә. Әлеге интеграцион күренеш телләр өлкәсендә сан һәм сыйфат яңарышы кичерүгә ярдәм итә.

Тормышыбыздагы компьютерлашуның бердәм мәгълүмат киңлекләре барлыкка килүнең хәзерге чорында төрле төзелешле телләрдәге гомумтерминологик фондтан нәтиҗәле файдалану машина тәрҗемәсен, чит телләрне интенсив рәвештә үзләштерүгә булыша.

Хәзерге фән, аның терминологиясе үз кабыгына бикләнеп, региональ дәрәҗәдә генә үсә алмый, ә дөнья берләшмәсенең фән-техника казанышларын

берләштереп, халыкара дәрәҗәдә генә чын үсешкәирешә ала, иҗтимагый-социаль һәм тел үсеше кануннары җирлегендә үсә. Биредә, һичшиксез, интернациональ фәнни-техник терминология тел лексикасы үсешендә үзенә лаеклы урынны биләп тора. Фәнни-техник революция, бер яктан, кардәш булмаган, төрле төзелешле телләрнең үзара баетылуына китерсә, икенчедән, телдәге терминологик фондның чагыштырмача стандартлашуына (бертөрлелегенә) китерә. Әгәр дә барлык яңа фәнни-техник терминнар да аерым милли телләрдә аерым-аерым ясалсалар, бу хәл төшенчәләрне белдерүдә буталчыклыкка, аңлашылмаучылыкка китерер иде.

Алынмалардан, интернационализмнардан качып, яңа фәнни-техник, иҗтимагый-социаль терминнарны пуристик нигездә ясарга омтылу (һәр милли тел җирлегендә генә) үзизоляциягә алып барыр иде, ә бу хәл фәнни интеграция процессына каршы килә [2, 59].

Фәнни хакыйкатьне чагылдыручы фәнни терминнарның дөреслеген билгеләгәндә, бик хаклы рәвештә Д.С.Лотте билгеләп үткәнчә, критерия булып аларның килеп чыгышы түгел, ә бәлки аларның фонетик, морфологик, лексик-семантик үзләштерелү дәрәҗәсе тора [Лотте Д.С, 1982, 105].

Һәрбер милли телдә бер үк вакытта милли дә, халыкара байлык та булып санала торган саф милли һәм алынма фәнни терминнар бар. Халыкара терминнарның нигезе интернациональ була, ә аларга ялганган суффикслар, префисклар  интернациональ дә, милли дә булырга мөмкин: *прагматизм, министерство, министрлык, агрессивлык, мәдхиячелек, экспрессионизм, компьютерчы, компьютерлаштыру һ.б.*

Мондый сүзләр татар телендә, башка төрле структурадагы телләрдә фонетик, грамматик яктан төрле дәрәҗәдә үзләштереләләр. Халыкара терминнарның телләрдәге кулланылу, үзләштерелү дәрәҗәсе иҗтимагый-социаль, лингвистик факторлар нигезендә, телләр үсешендәге эчке структур үсеш кануннары җирлегендә гамәлгә ашырыла.

Аерым алганда, мәсәлән, *робот, компьютер, компьютеризация, компъютерлаштыру, реконструкция, модернизация, интеграция,*

*дифференциация, клонирование, клонлаштыру, генная трансформация, генетик трансформация, психотерапия, микроклимат, психотерапия, реалия, партократия, сигнализация, сигналлаштыру, генная трансформация клеток, күзәнәкләрне геннардан трансформацияләү, ксерокс, ксерокопирование, ксерокслау, клон...* тибындагы фәнни-техник терминнар бик күп телләрнең фонетик, морфологик, лексик-семантик системасына үтеп керделәр, шул җөмләдән татар теленә дә кабул ителделәр, аларның тамыры охшаш, ә кушымчалары күпмедер дәрәҗәдә охшаш та, милли дә булырга мөмкин. Бу алынма терминнарның телдә үзләштерелү дәрәҗәсе бик күп тышкы һәм эчке факторларга, иҗтимагый кануннарга бәйле.

*Компьютер, робот, перестройка, гласность, үзгәртеп кору, хәбәрдарлык* кебек сүзләр, заманында бик күп телләргә үтеп кергән *атом, йод, газ* терминнары кебек, дөньядагы, барлык тел регионнарына диярлек кабул ителә, алардан өр-яңа сүзләр дә ясала: *роботчы, компъютерлаштыру* һ.б.

Тормышыбызның хәзерге яңарыш чорында сәяси, икътисади, рухи, мәдәни үзгәрешләр дәверендә лексика-терминология өлкәсендә дә үзгәрешләр булып тора: яңа төшенчәләрне белдерү өчен сүзләр туа тора, яисә искеләре яңа мәгънә төсмерләре алып кулланыла башлый, чит телләрдән сүзләр алына, бигрәк тә яңа чит тел сүзләре инглиз теленнән кабул ителә, яки элек кабул ителгән гарәп, фарсы, төрек сүзләре тергезелә, активлаша төшә, чөнки бөтен дөньяда барган интеграцион процесс, бердәм мәгълүмат киңлекләре булдыру зарурияте, интернет челтәре, компьютерлаштыру процессы аерым милли телләр үсешенә, аларның терминологиясе камилләшүенә тәэсир итмичә калмый. Бу – закончалыклы, табигый халәт. Мәсәлән, аерым алганда, татар, башкорт, үзбәк, кыргыз, төрекмән, алтай, мари, удмурт, чуваш һ.б. телләрдә яңа төшенчәләрне, күренешләрне аңлату өчен яңа сүзләр туа тора. Мисалларга мөрәҗәгать итәргә мөмкин: мәҗлес, бәйге, берлек, корылтай, хосусыйлаштыру, базар икътисады, сәяси каршылык, социаль киеренкелек; партократия, авторитарлык һ.б.ш. Югарыда китерелгән сүзләрнең күбесе күпчелек төрки телләрдә милли җирлектә ясала, ә кайбер төрки телләрдә (алтай телендә) чуваш телендә, рус телендәге

вариантлар кулланыла: алтай, чув: рыночная экономика, приватизация, Угрофин телләреннән мари, удмурт телләрендә дә рус телендәге вариантлар урын ала: чув. мари. удмурт рыночная экономика, приватизация. Әлбәттә, биредә терминология үсеше мәсьәләләрендә беренче чиратта хәлдән килгән кадәр милли телләрнең үз потенциаль мөмкинлекләренә мөрәҗәгать итәргә кирәк. Татар телендә дә мондый милли җирлектә туган сүзләр, терминнар күп: «*БДБ* (СНГ)», *туңдырма, кабул итү бүлмәсе, берлек, бәйге*, *кертем* һ.б.ш.

Әмма терминология бары тик үз милли кысаларында гына үсә алмый, анда алынмалар да урын ала*мәдәният, сәясәт, хан, ханбикә, чәй, фирма, чек, дотация, компенсация, реструктуризация, компромисс, патриант, репатриант, компьютерлаштыру, интернет челтәре, факс, телефакс: Дәүләт Советы.*

Фән үсеше белән мөнәсәбәттә бик күп яңа физик, математик, астрофизик, химик, биологик, генетик, техник терминнар ясала. Яңа фәнни терминнарның барысын да милли тел җирлегендә генә ясау һич мөмкин түгел, бу хәтта фикерләүдә узизоля-циягә, торгынлыкка китерер иде.

Биредә күптән телләргә үтеп кергән халыкара сүзләрдән дә файдаланмыйча ярамый. Әйтик, халыкара «компьютер» сүзен һич кенә дә азапланып «тамгасар», «санак» терминнары белән алмаштырырга кирәкмәстер, термин буларак «компьютер»не телдә калдырып, аның синонимик варианты, гадәти сүз буларак бәлки татарча параллельләрен дә алырга була торгандыр.

Әмма кайбер фәнни терминнарны бер телдән икенчесенә тәрҗемәләрендә милли телләрнең үзенчәлекләре, төзелешләре, традицияләре исәпкә алынырга тиеш. Мәсәлән, «идеаль газ», «идеаль сыеклык» немец, инглиз телләреннән «инерт газ, инерт сыеклык» дип тәрҗемә ителсә дә татар телендә «идеаль металл» «затлы металл» дип тәрҗемә ителә.

Телләрдә кулланылырга лаек халыкара фәнни терминнарны ясаганда, бер телдән икенчесенә кабул иткәндә хәзерге иҗтимагый-сәяси һәм фәнни-техник үзгәрешләр чорында, аеруча бердәм информация-мәгълүмат киңлеге шартларында түбәндәгеләр күз уңында тотыла:

1.Фәнни халыкара атамаларны телгә кабул иткәндә, аларныц фәнни мәгънәсенә зарар китермичә, терминнарның чагыштырмача барлык телләрдә дә бертөрлелегенә (стандартлылыгына) ирешү зарур.

2. Бердәм информация-мәгълүмат киңлекләре, компьютерлаштыру, интернет челтәре туу кысаларында телләр үсешендә интеграцион-дифференциаль күренешләрнең диалектик бөтенлегенә ирешү кирәк.

3.Халыкара фәнни-техник терминнарны кулланганда, алардан яңа төсмерле сүзләр ясаганда , аларның нигезе күп телләрдә күбесенчә уртак була, ә ялганган сүзъясагыч, формаясагыч суффикслар исә милли булырга мөмкин.

4.Яңа фәнни-техник, иҗтимагый-сәяси төшенчәләрне аңлаткан сүзләрнең халыкара вариантлары телдә термин буларак актив кулланыла, әмма аларның кайберләре поэзиядә, матур әдәбиятта, сөйләм телендә гадәти сүз буларак милли калыпта да урын алырга мөмкин: *компьютер* - *санак, тамгасар, президент* - *илбаш, конституция – кануннамә, устав* - *низамнамә* һ.б.

Җыеп әйткәндә, телдә уңышлы ясалган фәнни-техник, иҗтимагый-сәяси халыкара терминнар актив кулланыла, алардан яңа сүзләр дә ясала.

ӘДӘБИЯТ

1. Беляева С.А. Английские слова в русском языке XVIII—XX вв.– Д.В.:Изд.-во Дальн. вост.ун-та, 1984.—168 с

2. Лотте Д.С. Вопросы заимствования и упорядочения иноязычных терминов и терминоэлементов.~М.: Наука, 1982.-149 с.

Назад

## Общеалтайский пласт татарского языка (на примере общественно-политической лексики)

*Алеева Гульназ Усмановна,*
*преподаватель родного языка и литературы,*
*ГАПОУ ККСАГХ, г.Казань*

Сравнительно-исторический анализ общественно-политической лексики показал наличие у тюркских народов с давних времен слов,относящихся к общественно-политической лексике. Такие слова как *хан,байлык, кабала, түләү*

и т.д. имеют место в большинстве алтайских языках иявляются самыми древними наименованиями.

Общеалтайский пласт выявляется через изучение тунгусо-манжурских, монгольских и тюркских языков, а также путем анализа лексических соответствия тюркских, монгольских и тунгусо-манжурских языков. Слово должно встречаться во многих монгольских и в большинстве тюркскихязыках. Как нам удалось выяснить, следующие слова являютсяобщеалтайскими словами.

*хан* 'хан' - титул правителя у тюркских и монгольских народов, а также лицо, носящее этот титул. *Ничәмә-ничә гасырлар яшәгән, үзенең азатлыгы, бәйсезяеге өчен явыз ханнарга, патшаларга каршы көрәшкән халык: "Ир-егет үзе өчен туа, иле өчен үлә", дигән* [Әпсалямов]. *Бирегәтаба томырынып, җир селкетеп хан гаскәре кайтып килә* [Әпсалямов].

Впервые данное наименование зафиксировано в древних письменныхпамятниках: в словаре М.Кашгари (XI в.) слово *han* в значении 'хан правитель' [1, 636], в словаре Codex Cumanicus (1303) - *han, chan* 'король, царь'(материал взят из статьи Л.Г.Махмутовой; [2, 143]. в произведениях Мухаммедьяра (XVI в.) *хап* [3, 201]. Ср. башкирское, карачай-балкарское, татарское *хан* 'хан', караимское *хан* 'хан, царь' [4, 361]. В словарях И.Гиганова (1801), С.Кукляшева (1859), К.Насыри (1878) данное слово приведено *хан*и в значении "царь", а в словаре И.П.Березгина (1914) зафиксировано в форме *кан* в значении 'хан, князь'.

Слово *хан* встречается в следующих алтайских языках: татарском *хан,*ногайском*хан,* башкирском *хан,* карачай-балкарском *хан,* азербайджанском кан,кумыкском *хан,* каракалпакском *хан,* узбекском *хон,* туркменском *хан,*уйгурском *хан,* казахском *хан,* тувинском *хаан,* в алтайском *хан,* киргизском*кан и хан,*турецком *han,* хакасском *хан,* чувашском *хан и хун,* якутском *хан;*в бурятском*хаан,* калмыцком *хан,* монгольском *хаан;* в тунгусо-манчжурских: эвенкейском *каан,* эвенском *хан.* Примеры показывают, что в

тюркских языках данное слово употребляется лишь с незначительными фонетическими вариантами.

Опроисхождении термина *хан* у исследователей имеется разные взгляды и гипотезы. Слово *хан* по своему происхождению, как пишет З.Валиди, не произошло от укорачивания слова *кахан* [5, 92], а имеет свое независимое значение. По своему содержанию слово *хан* близко к значению таких слов как *идарәче* 'руководитель', *хөкемдар* 'правитель', т.е. онообозначает название главы ханства, которое подчиняется *каханству.* В империи Чингизхана (каханстве) глава улусов, правитель назывался не*каханом, а ханом.* Например, в Джучиевом улусе правил Бату хан, в Синей Орде (Күк Урда) - Шайбан хан, в Белой Орде (Ак Урда) - Ичин хан.

Значит, что слово *хан* не произошло от усечения слов кахан - каханлык, а лишь обозначали иерархию понятий социально-политических терминов во взаимоотношениях между государствами. Слово *хан* по своему статусу было ниже чем *кахан,* и исходя от этого *ханлык* также обозначал лишь одну из частей *каханства,* и назывался улусом. Правда, затем ханствапревратились в самостоятельные государства [6, 12-13].

В «Татарско-русском словаре» слово *хан* дано в значении хан *(ист.)* [7, 373].

*байлык* 'богатство' - обилие материальных ценностей. *Русиянен хисапсыз табигый байлыклар өстендә утыруына да карамастан, халыкныңкүпчелек өлеше көч-хәл белән очны-очка ялгап яшәргә мәҗбүр [МҖ,* 2008, 5 сентябрь].

Впервые данное наименование зафиксировано в словаре М.Кашгари (XIв.), а также форма *байлыг, байлук*в значении 'богатство' приведена в ДТС [79]. В труде "Codex Cumanicus" встречается слово *байлыг, байлык, баулик* [баилык] в значении 'богатство' [2, 85].

В словарях XIX века, например, у И.Гиганова (1801) дается форма слова *байлыкъ* в значении 'богатство'. В словаре Н.П.Остроумова (1876) это понятие выражается в форме *байлык;* в словаре К.Насыри (1892) *байчык* 'богатство'; у

А.Воскресенского (1892) уже приводится три синонима этом) понятия слова *байлый, мал, дяулят* 'богатство'. В словаре И.П.Березгина (1914) это слово дается в форме *байлык* в значении 'богатство'

Слово *байлык* встречается во всех алтайских языках с некоторыми фонетическими изменениями, за исключением азербайджанского, хакасского, калмыцкого и эвенкского. В современном татарском языкеслово *байлык* используется в таком же значении, оно присутствует и вбашкирском, алтайском, казахском, ногайском, киргизском, туркменском языках, а в каракалпакском и кумыкском языках слово *байлык* имеет форму *байлый,* карачай-балкарском *байлыѓъ,* в тувинском *байлак,* в узбекском *бойлик,* в уйгурском *байлиг,* в якутском *баай,* в турецком *боллюк,* в чувашском *пуянлах,* в эвенкейском *бай,* в монгольском и бурятском *байан.*

Татарское, башкирское и общетюркское (с закономерными фонетическими вариантами) *бай* 'богатый, богатство' в чувашском языке имеет морфологическую оригинальную структуру *пуянлах, паянлах,* который является продолжением общемонгольского и общетунгуского *байа, байан* - якутского *буйан* <древнемонгольского, древнетюркского *буйап* 'богатство', который возводится к санскритскому *punja* 'богатство' [8, 104|.

В «Татарско-русском словаре» [7, 48] к лексеме *байлык* даны 4 значения: 1) богатство, достояние, состояние; 2) ресурсы; 3) ценности; *4)* запас.

*түләү* 'выплата' - отдавать деньги или иные ценности в возмещение чего-либо, прекратить действие чего-либо, сделать недействительным.*Татарстан Республикасында дәүләт вазыйфасын биләүче затларга гомуми хезмәт хакыннан тыш, өстәмә рәвештә ай саен акчалата кызыксындыру чаралары, премияләр түләнә, шулай ук закон нигезендә бүтән түләүләр дә башкарыла* [МЖ, 2008, 5 сентябрь].

Впервые данное наименование зафиксировано в словаре М.Кашгари (XI), а также форма *tola-* в значении 'платить, уплачивать' приведена в ДТС [1, 569]. В памятнике XIII века Codex Cumanicusданное слово имеет форму *to1a, toj1a* [to1a] в значении 'платить, заплатить'; казанско-татарском *тула* [2, 140]; в

грамматическом трактате XIV века "Ат-тухфа" дано в форме *tolu-, tol-* [9, 382]; в документах на кыпчакском языке XVI в. слово *түләү* имеет вариант *1о1а-*[ 10, 196] и др.

Из 23-х алтайских языков, подвергнутых нами изучению общественно-политической лексики, слово *түләү* имеется в 11 тюркских и 2 монгольских языках. Так, в татарском *түләү,* башкирском *түлләү,* каракалпакском *төьлеу,* карачай-балкарском *тёлеу,* алтайском *толу,* казахском *төьлеу,* киргизском *төлөө,* хакасском *толег и топес,* узбекском *тулое и тулаш,* туркменском *толеме и телег,* кумыкском *борчун тёлев,* ногайском *тоьлеп кутылув,* якутском *төлөбүр,* уйгурском *төдәш,* монгольском *толбор* и *төлөох,* бурятском *түлэлгэ,* эвенском *дё'лдан,* эвенкейском *толош.*

Слово *түләү* в значении а) *платить, уплачивать* - имеет место во всех языках, кроме чагатайского, турецкого диалекта; б) *возмещать* [убытки, долги] – турецком диалекте, туркменском, татарском, ногайском, казахском; в)*компенсировать* - туркменском, чувашском; г) *менять, заменять* - чагатайском.

Г.Рамстедт и М.Рясянен считают тюркское tolu, tole'платить' имонгольское tulu-, *tolie* то же прародственными. Н.Поппе относит тюркскоеtoleк монголизму. Г.Дерфер [11, II, 980] пишет, что для монгольского слованет этимологии, а тюркское tolu -, возможно, <*tol+a-'*давать потомство';если древнетюркское tolu'плата, возмещение' <tola-, то следует вывод осуществовании тюркского глагола в домонгольское время. Г.Дерфер однако отмечает, что tole - не зафиксирован в ожидаемой форме *(dole-)* в тюркскихязыках юго-западной группы, что говорит в пользу допущения Н.Поппе.

Для установления генезиса tole - интересны шорское tol- 'плата' [12, 1884, 367; 13, III, 1260], и кыпчакское tol- 'платить долг' [9, 382], в которых можно видеть глагольно-именную основу, восходящую к гипотетическому to, упомянотому Г.Рамстедтом [14, 406]. Шорское слово tol- могло возникнуть и

из tolu - в сочетании tolgeber- 'дать под уплату в долг' в результате выпадения краткого узкого гласного. В чувашском диалектеtyvle'платить' [15, 264].

Из именных производных tole- отметим содержащие монгольскиесловоообразовательные суффиксы, что косвенно подтверждает имонгольский источник производящей глагольной основы: тувинское tolevir“плата, платить, оплата', якутское tolybur'плата, цена', киргизское tolu*omor*'оплата, возмещение', ср. письменное монгольское tolu*eburi,* калмыцкое tolwr[14,73].

В «Татарско-русском словаре» к лексеме *түләү* даны два значения: 1)плата, оплата, платеж, выплата; *2) разг.* налог [7, 354].

Итак, общеалтайский пласт, в татарском языке сохранился в немногих словах, но они практически употреблялись во все времена существования татарского языка.

ЛИТЕРАТУРА:

1. Древнетгоркский словарь. - Л.: Наука, 1969. -676 с.

2. Махмутова Л.Т. Татарский язык в его отношении к древнеписьменному памятнику Codex Cumanicus по данным лексики (краткий анализ и приложение) // Исследования по исторической диалектологии татарского языка: сб. ст. / Отв. ред. Д.Б.Рамазанова. - Казань, 1982.-С. 68-153.

3. Кадирова Э.Х. Поэмы Мухаммадьяра «Тухва-и Мардан» и «Нур-иСодур»: Лексика. - Казань: РИЦ «Дом печати», 2001. - 232 с.

4.Шипова Е.Н. Словарь тюркизмов в русском языке. - Алма-Ата: Фан1976. - 678 с.

5.Вэлиди Ә. Кыскама төрек-татар тарихы. - Казан, 1992.-94 б.

6.Ганиев Ф.Ә. Татар телендә социаль-тарихый терминнар турында// Проблемы лексикологии и лексикографии татарского языка: сб. ст. - Вып, 3 -Казань, 1995.-С, 12-16.

7.Татарско-русский словарь / Под. ред. Ф.А.Ганиева. - Казань: Татар кит. нәшр., 2002. - 488 с.

8.Ахметьянов Р.Г. Общая лексика материальной культуры народи» Среднего Поволжья. - М.: Наука, 1988. - 200 с.
9. Изысканный дар тюркскому народу. - Ташкент: Фан, 1978. - 450 с.
10.Документы на половецком языке XVI века: (Судебные аюы Каменец-Подольской армянской общины) / Транскрипция, пер., предисл. , введ., граммат. коммент. и глоссарий Т.И.Груниной. - М.: Наука, 1967. 'ІШ с.
11.Вербицкий В. Словарь алтайского и аладаргского языка. - Казань 1884.- 523 с.
12.Радлов В.В. Опыт словаря тюркских наречий: Т. *1*-\\. - СПб.: Тип Акад. наук, 1893-1911.
13.Рамстедт Г. Грамматика корейского языка. - М., 1951.
14. Егоров В.Г. Этимологический словарь чувашского языка. Чебоксары, 1964. - 576 с.
15. Пояснения и толкования приведенных общественно-политических слов даны по словарям: «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге». –В 3 томах. - Казан Тат.кит.нәшр., 1979-1981; Татар теленең аңлатмалы сүзлеге. - Казан: Матбугатйорты, 2005; Толковый словарь русского языка. В 4 томах. - М.: «Русскийязык», 1981 -1984.

Назад

## Әдәби әсәрдә сурәтләү чараларының куллану үзенчәлеге
## (Муса Җәлилнең “Илдар” либреттосы мисалында)

*Арсланова Сәлимә Сәләхетдин кызы,*
*татар теле һәм әдәбияты укытучысы, филология фәннәре кандидаты,*
*ДАҺБУ “Тәтеш дәүләт гражданнарны яклау көллияте”, Тәтеш шәһәре*

Татар халкының бөек шагыйре, Ленин премиясе лауреаты, Советлар Союзы герое, шагыйрь Муса Җәлилнең исеме бөтен дөньяга билгеле. Аның “Моабит дәфтәрләре” шигырьләре йөзләгән телләрдә яңгырый. Үзенең телен, Ватанын сөйгән һәр татар кешесе өчен Муса - зур горурлык, ул аның йөрәк түрендә яши һәм яшәячәк. Шагыйрьнең тормыш юлы, иҗаты җентекләп

өйрәнелгән, үлемсез образы күп кенә әдәби, музыкаль әсәрләрдә, сынлы һәм тасвирлы сәнгатьтә, кино һәм театрларда мәңгеләштерелгән.

Муса Җәлил турында бик күп сөйләнелгән, язылган булуга карамастан, шагыйрь язмышы белән кызыксыну кимеми, аның иҗаты турында яңадан-яңа тикшеренүләр туа тора. Һәр яңа буын галимнәр, язучылар Җәлилнең иҗади мирасына мөрәҗәгать итә, аннан өйрәнә. Шагыйрьнең үз сүзләре белән әйткәндә, шигырьләрендәге сөю, ут һәм ялкын очкыннарының кайчан кабынуы, сәнгати югарылыкның нинди әсәрләрдән башлануы, гомумән, иҗатының чишмә башы кайда булуы турындагы сораулар кызыксындыра аларны.

Мәгълүм ки, бернәрсә дә юктан бар булмый, буш җирлектә дә барлыкка килми. "Моабит дәфтәрләре" циклы туының алшарты һәм тоткынлыктагы иҗатның тотрыклы нигезе булып, безнеңчә, каһарман шагыйрьнең сугышка кадәрге тормышы, иҗади эзләнүләре һәм сәнгати табышлары тора. Сугышка кадәрге елларда талантлы шагыйрь тарафыннан шигырьләр генә түгел, татар операсы формалашуга зур өлеш керткән "Алтынчәч" һәм "Илдар" либретолары иҗат ителә.

Либретто – опера өчен язылган драматик поэма. Ә либреттист – шагыйрь дә, драматург та һәм шул ук вакытта музыкант та. Муса Җәлилнең либреттолары поэзия белән музыканың чын гармониясен, идеал бердәмлеген чагылдыра. "Алтынчәч" поэмасы, "Илдар" белән чагыштырганда, киңрәк таралыш алган, тирәнрәк өйрәнелгән һәм күп белгечләр тарафыннан шагыйрь иҗатының иң югары сәнгати ноктасы буларак билгеләнгән. Либреттоларның икесе дә бер үк идея – халык азатлыгы һәм ирек өчен көрәш тирәсендә корылган. Темалары да уртак: туган илгә мәхәббәт, Ватаның, халкың өчен көрәшкә әзер булу, ике яшь йөрәкнең мәхәббәте, ана мәхәббәте һ.б. Тик әсәрләрдәге вакыйгалар генә икесе ике чор, ике идеология тирәсендә сурәтләнә. Романтик-фәлсәфи рухтагы "Алтынчәч" нигезенә "Җик Мәргән" эпосы, "Алтынчәчле кыз", "Туктар " экият мотивлары салынса, "Илдар" либреттосында конфликтлар фин сугышы белән бәйләп бирелә, вакыйга Идел

буе авылларының берсендә бара. Менә шушы факт либреттоларның лексикасындагы аерымлыкларга китерә. Алга таба без әдәби әсәрдә сурәтләү чараларын куллану үзенчәлеген драматик поэмаларның галимнәр тарафыннан азрак өйрәнелгәне - “Илдар” поэмасы мисалында карарбыз.

Сурәтләү чаралары металогик һәм автологик төрләргә бүленәләр. Тел белемендә металогик алым дип образ, сурәт тудыруда, тасвирлауда күчерелмә мәгънәлелеккә нигезләнгәнсурәтләү чараларына мөрәҗәгать итүне атыйлар. Металогик алымның капма-каршысы булып автологик алым санала. Соңгысы, сүзләрне туры мәгънәсендә кулланып, поэтик текст барлыкка китерүне күз алдында тота.

Муса Җәлилнең “Илдар” либреттосы да, “Алтынчәч” кебек үк, татар поэзиясенең шедевры. Биредә дә шагыйрь халык иҗатына, җырларга, әйтемнәргә мөрәҗәгать итә:

Әй икегез, икегез,
Икегез дә бер тигез;
Икегез дә пар килгәнсез,
Тигез гомер итегез [2, 335 б.].

Либреттода шулай ук табигать күренешләренә мөнәсәбәтле бик матур чагыштырулар да урын алган:

*Таң Чулпаны төсле*, йөрәкләрдә
Сөю уты бергә кабынды.
*Таң шикелле якты* теләкләргә
Барыр юллар бергә табылды [2, 335б.].

Кашы-күзе нәкъ үзе
Тулган ай төсле йөзе [2, 403 б.].

Безнең *бәхет балкыр кояш төсле,*
Без мәңгегә бергә яңадан [2, 407 б.].

Әсәр тукымасына зәвыклы бизәк булып төшкән тагын бер чагыштыруга аерым игътибар итмичә булмый: *хыял төсле татлы безнең ил* [2, 408б.]. Туган илен бөтен барлыгы белән өзелеп яратучы кеше генә аны шулай татлы хыял

белән тиңли ала торгандыр. Ватаны, халкы өчен гомерен дә кызганмаган Муса каләменнән хыяллар татлы, таңнар якты, көннәр матур булып туа, ә газиз туган иле - татлы да, якты да, матур да.

Әдәби әсәрләрдә төрле вакыйгаларны, образларны төгәл һәм кыска сурәтләүгә хезмәт итә торган сурәтләү чарасы – метафораларны да киң куллана шагыйрь. Ул халык телендәге әзер формаларны да (*кайнар йөрәк, йөрәк ярасы, сөю уты, бөдрә таллар, зифа буйлы* һ.б.), иҗатчының үз табышы гына дип атарга мөмкин булганнарын да (*шайтан кыз, шомырт күзләр* һ.б.) файдалана.

Алда әйтеп үткәнебезчә, “Илдар” либреттосы ил тарихындагы төгәл бер чор, конкрет вакыйгалар тирәсендә барганга, шагыйрь тасвирлауда конкретлыкка нигезләнгән автологик алымга өстенлек бирә һәм шул юл белән югары сәнгатьлелеккә дә ирешә. Һәр кешегә аңлаешлы тел, киң кулланыштагы сүзләр белән язылганлибретто бакчада алма җыючы кызлар җыры белән башланып китә. Җыр татар халык иҗатына якын, текст җырлап укыла. Авторның әйтергә теләгән фикере, күрсәтергә теләгән нәрсәсе – бәхетле тыныч тормышның матурлыгы, күмәк хезмәт барышы, рухи күтәренкелек, оешканлык. Менә шулар стилистик битараф сүзләрнең сәнгатьчә оештырылышы ярдәмендә җиткерелә. Бу очракта В.В. Виноградовның “әдәби әсәрдә махсус сурәтләү чаралары гына түгел, ә гомумхалык сүзләре дә сәнгатькә һәм эстетик максатка хезмәт итәләр”,– дигән фикере бик дөрес туры килә [1, 8 б.]

Либреттода акфиннар белән сугыш вакыйгалары сүрәтләнгәндә, әсәр телендә, шушы хәрби атмосфераны бирү максатыннан, хәрби атамалар кулланыла. Алар вакыйгаларның асылын тулырак аңларга, сулышын тоярга ярдәм итәләр:

Иптәш командир!

*Ротада* бар да тыныч ... [2, 380 б.].

*Разведкага* үзем китәм.

Беренче *взвод*, хәзерлән! [2, 381 б.].

Вакыт үткәрмә бушка,

Ашык хәзер *штабка* [2, 388 б.].

Командир *засадага* эләккән [2, 389 б.].

Хәрби терминнар шулай ук автор ремаркаларында да очрый: траншея, приказ, взвод, часть, связист, кызылармеец, пулемёт, оборона, пуля, граната һ.б. Армия, фронт сызыгында, сугыш кырында кулланылган махсус хәрби терминнар рус теле яки аның аша башка чит телләрдән кергән алынма сүзләрдән тора. Алар сөйләнелгән вакыйгага бәйле һәм теманы ачуга хезмәт итәләр. Шагыйрь үзе кулланган алынмаларның барысын да оригинал телдәгечә ала, бернинди ясалма тәрҗемә итү, татарчалаштыру омтылышы күзәтелми. Карап киткән мисаллар әсәрдә әһәмиятле стилистик функция башкаралар: урыны белән әсәргә җитдилек төсмере өстиләр, вакыйгалар бирелгән чорга, сюжет линиясенә хас атмосфера тудыралар.

Алда әйтеп үтелгәнчә, вакыйга Идел буе авылларының берсендә бара. Ситуация әледән-әле үзгәреп тора: мәхәббәт күренеше дә, тыл хезмәте дә, акфиннар белән сугыш та сурәтләнә, һәм әсәр җиңү, тантана белән тәмамлана. Шагыйрьнең туган якның ямьле табигате кочагында яшәүче көр күңелле авыл кешеләре телен гади сөйләм сүзләреннән төзүе бик табигый. Гыймади, Сабира, Маһирә образлары, гомумән, тапкыр сүзләр аша бирелә. Хәйрүш образы исә бөтенләй юмористик планда эшләнгән. Персонажларның индивидуальлеге аларның үз репликаларында да ачыла. Мәсәлән,

Әйдә, кияү, юлдан арып,

*Ватылып* килгәнсеңдер [2, 336 б.].

*Валлаһи* , гашыйк булгансың.

Күзләрең уттай яна [2, 342 б.]

Саҗидә, зинар, тап, *малай*! [2, 350 б.]

Ууу .... *бирән* [2, 350 б.]

Бары тик сөйләү стиленә генә хас мондый сүзләр сөйләмгә җанлылык өстиләр, образларны ачуда, аларны индивидуальләштереп бирүдә аеруча зур роль уйныйлар.

Драматик поэмада автор файдаланган тагын бер автологик алым бар. Ул да булса - диалекталь лексикага хас сүзләр куллану. Мәсәлән,

Чынлап, Гыймади агай!

Үзең баш кода булсаң,

*Күнәр иде* ичмасам [2, 325 б.].

“Лексик-семантик категория буларак, диалекталь сүзләрнең гади сөйләм сүзләре белән бик якын уртаклыклары бар: алар икесе дә әдәби нормалашмаган сүзләр. Һәр икесе дә әдәби телгә яңа сүзләр, әйтелмәләр бирә торган бай чыганаклардан саналалар”,-дип яза М. Г. Мөхәммәдиев [3, 27 б. ]

Автор ремаркасындагы *пима* (әдәби варианты – киез итек) сүзе дә шулай ук диалекталь лексикага карый.

“Илдар” либреттосы теленең лексик составында һөнәрчелек лексикасының берничә тармагын аерып чыгарырга була. Мәсәлән, бакчачылык лексикасына караган сүзләр: *алма үлчәүчеләр, алма кабул итү, сортларга аеру, ящикларга тутыру*һ.б.Чигү-бәйләү һөнәренә караган сүзләр*: чачаклы сөлге, көмеш саплы энә, өлге, ука йөртеп чигү, шәл бәйләү.*Әлеге сүзләрнең барысы да диярлек инде киң кулланыш лексикасы яки гомумхалык лексикасы сүзләренә әйләнгән. Автор аларны стилистик чара буларак та, билгеле бер хезмәт процессын сурәтләү өчен дә файдалана.

Гомумкулланыш сүзләренең, күңел өшеткеч буяуларга манылып, үтә караңгы сүзләр теземе ясап килгән очраклары да бар текстта:

Ачлык елны ирем үлеп калгач,

Икмәк эзләп Ташкент ягына

Улым белән икәү чыгып киттек,

Эшләрбез дип тамак ялына [2, 329 б.].

*Тамак ялы* сүзтезмәсе хәзерге сөйләм теленнән инде төшеп калып бара. Әлеге факт - телнең һәрвакыт үзгәрештә, хәрәкәттә булуына дәлил. Ә шагыйрь аны, вакыйгаларны бәян итү белән беррәттән, ачлык елларын контраст итеп куеп, халыкның хәзерге тыныч, мул тормышын күрсәтү максатыннан файдаланган.

Әйтергә кирәк, Муса Җәлилнең “Илдар” либреттосында һәр сүз үз урынында, әсәрнең телен баета, һәр лексик берәмлек аны сәнгатьлерәк ясый, эчтәлеген ачарга ярдәм итә. Шагыйрь каләменә бер генә сүз дә урынлы-урынсыз барып эләкмәгәне күренеп тора.Шагыйрь-либреттист, бай лексикабызның төрле катламнарыннан сүзләр алып, әсәр тукымасына әдәби энҗеләр тезә. Ул үзенә генә хас осталык белән сүз-образлар аша тормыш күренешләрен чагылдыра, гомумхалык телен бик уңышлы кулланып, чынбарлыкны җанлы күзаллау мөмкинлеге тудыра һәм, эчтәлекне генә хәбәр итеп калмыйча, хәбәр ителгәнгә үзенең мөнсәбәтен дә белдерә. Гади, аңлаешлы, шул ук вакытта төрле сурәтләү чараларына бай тел белән яшьләрнең эчкерсез саф мәхәббәтенә, эш сөюче, уңган халыкның туган иленә бирелгәнлегенә, аяусыз батырлыгына дан җырлый.

Шулай итеп, без татар халкының сүрелмәс горурлыгы, каһарман-шагыйрь Муса Җәлилнең әдәбият һәм сәнгать өлкәсендә якты йолдыз булып балкып торучы әсәрләренең берсе – “Илдар” либреттосының теленә өлешчә анализ ясадык. Анализдан күренгәнчә, сугышка кадәр үк иҗат ителгән либреттоның теле үткен, һәртөрле сурәтләү чараларына бай, сыгылмалы, үзенчәлекле. Әсәрнең сюжетында да, кулланган һәр сүзендә дә авторның үз “мин”е чагыла, туган иленә, газиз халкына чын йөрәге белән бәхет теләүче, ирек сөюче шәхес тоемлана. Муса – үз каләме тудырган Илдарларның берсе. Ватанына, халкына булган мәхәббәтен үлмәс шигырьләре белән генә түгел, тиңдәшсез гомере һәм үлеме белән раслаган шагыйрь – Алтынчәче, Җик, Арслан һәм Илдары кебек үк, ирек, азатлык, матурлык, тугрылык, саф мәхәббәт символы!

КУЛЛАНЫЛГАН ӘДӘБИЯТ ИСЕМЛЕГЕ

1. Виноградов В.В. О языке художественной литературы. – М.: Гослитиздат, 1958. – 654 с.

2. Җәлил М. Әсәрләр: 4 томда. - Шигырьләр (1941-1944). Либреттолар. – Казан: Тат.кит. нәшр., 1976. 2 т. – 590.

3. Мөхәммәдиев М.Г. Шәриф Камал прозасының теле. – Казан: Фикер, 1991. – 135 б.

Назад

## Аяз Гыйләҗев иҗатында диалектларның кулланылышы

*Арсланова Гөлия Мөхәмәтлатыйп кызы,*
*МГБББУ "Сарман гимназиясе"нең югары категорияле*
*туган тел, әдәбият укытучысы*
*Хаҗиева Равия Рафаэль кызы*
*югары категорияле башлангыч сыйныф укытучысы*

Интернеттан мәгълүмат эзләгәндә, шундый язмага тап булдык: "Google инкыйраз янаган телләрне коткару эшенә алынды. Исемлегендә татар диалектлары да бар". Әлеге язу сискәндереп җибәрде. Белгәнебезчә, хәзерге татар милли әдәби теленең лексик, фонетик нормалары, нигездә, урта диалекттан, морфологик нормалары – мишәр диалектыннан, синтаксик нормалары һәм стилистик эшкәртелеше иске татар язма әдәби телдән килә. Шуңа күрә дә Сарман районы диалектизмнарын өйрәнелде. Татар әдәбиятына күпсанлы шагыйрь-әдипләр биргән районыбыз язучылары, әсәрләрендә безнең төбәк диалектизмнарын кулланып, туган ягыбыз телен мәңгеләштергәннәр, образлырак итеп әйтсәк, телебезгә һәйкәл койганнар икән лабаса.

Диалектлар мәсьәләсе Аяз ага Гыйләҗев иҗаты аша тикшерелде. А.Гыйләҗевнең "Үги ана яфраклары", "Тәрәзәләр" хикәяләре, "Яра", "Мәхәббәт һәм нәфрәт турында хикәят", Язгы кәрваннар" повестьларына күзәтү үткәрелде.

Диалектизмнарның берничә төре бар: фонетик диалектизм - әдәби телдән аваз составы белән аерылып тора торган сүзләр (җылап - елап, катын - хатын);лексик диалектизм– аерым территориядә яшәүчеләр арасында гына таралган сүзләр (тәкә – ризык төре, төнәген - кичә);морфологик диалектизм – грамматик формасы белән әдәби телдән аерыла торган сүзләр (баргачтын, киткәндәген, сөйлидерие); семантик диалектизм – мәгънәсе белән әдәби телдәге сүздән аерылып тора торган берәмлек (болгавыр-мәшәкатьле, кәтәнә-кыска буйлы); алынма диалектизм – рус һәм башка телләрдән алынып, татар теленә яраклаштырып әйтелә (жәл-жаль, дәдәң-дядя, тута–тетя), этнографик диалектизм – төбәк халкының гореф-гадәтенә, көнкүрешенә хас булган һәм башка җирләрдә очрамаган сүзләр (мәсәлән, Сарман районы Каран авылында

үткәрелүче Әрәпә бәйрәме); фразеологик диалектизмнар – фразеологик әйтелмә буларак, аерым төбәктә кулланылучы сүзтезмәләр (кар өстендә казан кайната – булган кеше). А.Гыйләҗевнең әсәрләрендә әлеге диалектизмнарның морфологик, этнографик төрдән калганнары барысы да күзәтелә.

Безнең Сарман районы кешеләренең сөйләме Урта диалектның минзәлә сөйләшенә туры килә. Урта диалектның казан арты, минзәлә, тау ягы, бәрәңге, касыйм сөйләшләре өчен иң характерлы фонетик үзенчәлекләрнең берсе булган җ-лаштыру, ягъни сүз башында әдәби телдәге [й] урынына [җ] куллану хас: “Тутаңның балалары җылашып калдымы?” (“Язгы кәрваннар”), “Прахуттан төшкәч, җирне кочаклап җылашабыз” (“Яра”).

Без Сарманлыларда да бу диалект кулланыла. Әлеге күренеш А.Гыйләҗевнең “Мәхәббәт һәм нәфрәт турында хикәят” повестенда - 14, “Язгы кәрваннар”да - 9, “Яра” повестенда - 14 , ”Үги ана яфраклары” хикәясендә - 1, “Тәрәзәләр” хикәясендә 2 тапкыр очрый.Күзәтүләрдән шулай күренә: А.Гыйләҗев әсәрләрендә фонетик диалектизмнардан җ-лаштыру күренеше иң еш очрый торганы булып тора.

Аяз Гыйләҗевнең балачагы элек Сарман районына караган керәшен татарлары яшәгән Баграж авылында үткән. Сарман ягында гомер итүче керәшен татарлары сөйләшенә **х-к чиратлашуы** хас: катын – хатын. **х-к** чиратлашуы чагыштырмача сирәк очрый. Шулай ук керәшен татарларындагы дәдә (дядя сүзеннән), тута (тетя сүзеннән) кебек алынма диалектизмнар язучы әсәрләрендә шактый кулланыла.

Сарманлылар телендә **җәл** сүзе шактый еш кулланыла. Әлеге сүз рус телендәге жаль сүзеннән алынган һәм кызганыч мәгънәсен белдерә. Бу алынма диалектизм Аяз Гыйләҗев әсәрләрендә дә еш очрый.

Алынма диалектлардан тагын рус теленнән кергән пүч (пусть), кәнсәләр (канцелярия - колхоз идарәсе мәгънәсендә), симәнә (семена), мужыт (может), матри (смотри), кенәгә (книга), чүт-чүт (чуть-чуть), кантур (контора - колхоз идарәсе мәгънәсендә), түтенкә (тётенька) (“Язгы кәрваннар”) сүзләре очрый.

А.Гыйләҗев иҗатында иң күбесе - лексик диалектизмнар. Лексик диалектизмнардан барысыннан да ешрак кечкенә мәгънәсендәге **бәләкәй** [2, 109б.] сүзе очрый.

Бу сүз Сарманлылар өчен генә түгел, ә, белгәнемчә, татарларның күпчелеге өчен хәтта диалект сүзе буларак та күзалланмый. Шул рәвешле бәләкәй диалектизмы әдәби телгә кереп китү алдында тора дип әйтергә була.

Моннан тыш язучы **ятьрәк** [2, 245б.] диалектизмын куллана. Тексттан бу сүзнең мәгънәсе бик тиз (ялт итеп) буларак аңлашыла. Әлеге сүз “Мәхәббәт һәм нәфрәт турында хикәят” повестенда - 1, ”Үги ана яфраклары” хикәясендә 1 тапкыр кулланыла.

А.Гыйләҗев әсәрләрендәге диалектизмнарның беркадәр өлешенең мәгънәсе контексттан аңлашылса, кайберләренең эчтәлеген ачыклау өчен, диалектологик сүзлекләрдән файдаландык. Әйтик, “Мәхәббәт һәм нәфрәт турында хикәят” повестеннан шундый өзекне алыйк: “Һәр авылдагы кебек бездә кар өстендә казан кайнатырлык уңганнар күп, ялкау-үшәннәр дә җитәрлек, тешләкләр янәшәсендә телгә беткән лыгырдыклар яши, бар астыртыннар, **мүкләкләр**, симез былкыннар, юаш күпәшләр, аңгыра брыйлар, колгалар, кәтәнәләр, сукыр-букырлар, колакай саңгыраулар, күрә караулар, **аю табаннар**, солдаткалар, толлар, тол дүдәк ирләр, гөсләчеләр, мәшһүр биючеләр, аш-су осталары, чигүчеләр, җөйчеләр, итек басучылар, тире иләүчеләр, күмер яндыручылар, кендек әбиләр, **эпчи карчыклар**, ...өй борынча биләмгә йөргән бистә бикәләре, ..... Югары очта пышылдаса, Түбән очка төшеп яңгыраган бакыр бугазлы касамаллар, ...... бер утыруда егерме җиде дурычмак, утыз ике өчпочмак сыпырып куючы бирән кормаклар, **шифыртлар**........., кыскасы, кемнәр генә булмаган да, кемнәр генә гомер кичерми безнең Югары авылда”.

Әлеге диалектизмнардан астына сызып билгеләнгәннәренең мәгънәсе контексттан аңлашылса, калын хәрефләр белән бирелгәннәренең эчтәлеген сүзлектән каралды.

Әлеге өзектә диалектизмнарның төрләре: 1)фразеологик диалектизм: кар өстендә казан кайната – уңган, булган кеше, телгә беткән лыгырдык- күп сөйләшүче, колакай саңгырау – аермачык әйткәнне дә ишетмәүче кеше, күрә карау – каршында торган әйберне дә күрмәүче кеше, әпчи карчык - күп сөйләүчән, күпне белергә, тикшерергә яратучан хатын-кыз [1,85б], бакыр бугазлы касамал – кычкырып сөйләшүче кеше, аю табан – агач аяк, каты басып йөрүче кеше.

2) лексик диалектизмнар: тешләк – аз сөйләшүче кеше; мүкләк – йомшак характерлы, җебегән, булдыксыз кеше турында әйтелә; симез былкын – таза, симез кеше; юан күпәш – юан кеше; аңгыра брый – акылсыз, аңгыра; дурычмак – ачы камыр өстенә төелгән бәрәңге ягып, аның өстенә туглаган йомырка сылап пешерелгән ризык.

3) семантик диалектизмнар: колга – озын буйлы кеше; кәтәнә – кыска буйлы кеше; шифырт (бу сүзнең мәгънәсен белә алмадым, кушымтадагы таблицада аңлатмасы китерелә).

”Үги ана яфраклары” хикәясендә **төнәген**[2, 644б] диалектизмы очрый. Әлбәттә, бу сүзнең мәгънәсен контекст аша гына белеп булмый: “Чәчәкле кишәрлекне төнәген үк күреп киткән һәм сокланып үткән иде Галимҗан. Төнәген үк аның башында бер план да төзелгән иде.” Диалектологик сүзлектә бу сүз **көнәген**[1, 127б], ягъни **к-т** чиратлашып бирелә. Халык телендә, күрәсең, бу сүзнең ике варианты да кулланыла. Ә эчтәлеге белән ул кичә (үткән көн) дигәнне белдерә.

Тагын **кыйрата**[2, 438б] дилектизмы бик кызыклы. “Мәүлиха апаңниләр кыйрата?” (“Мәхәббәт һәм нәфрәт турында хикәят”). Контексттан бу сүзнең мәгънәсен эшли дип аңларга була. Ә сүзлектә [2, 438б] исә ул кыру (истреблять) буларак бирелә. Халыкның сөйләмә телендә: “Ни эшләр җимерә?” – дип сөйләшү бар. Кыру һәм җимерү сүзләрен синоним итеп карасак, мәгънәсе буенча бу сүзләр бер-берсенә туры килә дип әйтергә була.

Кайбер диалектлар А.Гыйләҗевнең төрле әсәрләрендә кабатланып килә. Болар - ж-лаштыру күренеше, бәләкәй, кәй, ятьрәк, жәл, кыдрач, каулау,

каударлану, бәлтерәгән сүзләре. ж-лаштыру күренеше, бәләкәй диалектизмнары – мин күзәтү ясаган барлык әсәрләрдә дә, калганнары “Мәхәббәт һәм нәфрәт турында хикәят”, “Яра” повестьларында күзәтелә.

Язучылар, диалектизмнар кулланып, әдәби әсәрнең телен образлы итә, әсәрдә сурәтләнгән төбәкнең үзенчәлеген оста итеп җиткерә, сүз белән сурәт ясый. Ләкин диалекталь сүзләрне урынлы, белеп кулланганда гына, күңел түрендә урын ала.

ФАЙДАЛАНЫЛГАН ӘДӘБИЯТ

1. Аяз Гыйләҗев.- Әсәрләр. Дүрт томда. 1 том. - Казан, Татарстан китап нәшрияты, 1994.

2. Аяз Гыйләҗев.- Яра. Повесть, роман, хикәя. - Казан, Татарстан китап нәшрияты,1991.

3. СССР Фәннәр Академиясе Казан филиалы Тел, әдәбият һәм тарих институты. -Диалектологик сүзлек. - Казан, Татгосиздат, 1953.

4. Татарстан Республикасы Фәннәр Академиясе Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты. - Татар теленең зур диалектологик сүзлеге. - Казан, Татарстан китап нәшрияты, 2009.

5. СССР Фәннәр Академиясе Казан филиалы Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институты. - Татар теленең аңлатмалы сүзлеге. - Казан, Татарстан китап нәшрияты, 1979.

Назад

## Халыклар дуслыгы һәм татар әдәбиятында бу теманың чагылышы

*Әхмәтҗанова Хәмдия Әхтәм кызы,*
*татар теле һәм әдәбияты укытучысы,*
*ДАҺМУ”Актаныш технология техникумы”, Актаныш авылы*

Татар әдәбиятында һәм тарихта “Кеше хөр булырга тиеш!” дигән шигарь элек – электән үк яшәпкилә. Ләкин бу тигезлеккә ирешү юлы бик нык сикәлтәле һәм авыр була. Тик шулай да, һаман да кешеләрнең һәммәсе дә тип – тигез яши дип әйтеп булмый әле.

Моңа бер генә нәрсәне сәбәп итеп алып булмый. Сәбәпләр күп... чиксез... Мәсәлән моңа җәмгыять тә, тирә – юнь дә, кешенең нәселе дә, бер кешенең икенче кешегә мөнәсәбәте дә, үзенең ваемсызлыгы да, битарафлыгы да, ялкаулыгы да һәм башка бик күп нәрсәләр сәбәпче булырга мөмкин. Тормыш бик тә катлаулы шул. Шулай булса да һәркем тигезлектә, муллыкта, сәламәт булып яшәсен иде... Халыклар, милләтләр дус булсын... Җирдә көчләүләр, изүләр булмасын иде... Безнең республикада моның өчен күп кенә эшләр башкарыла.

...Без – укытучылар, студентларыбызга уку планы буенча гына түгел, башка өлкәләрдәдә күп кенә белем бирергә тырышабыз. Үз студентларыбызны, сау - сәламәт, интеллектуаль яктан үсеш алган, акыллы, ярдәмчел, ачык күңелле, үз тирә-юнендәге матурлыкны аңлаучы, һәм, әлбәттә, үзебезнең күпмилләтле илебездә тынычлыкта һәм татулыкта яшәүче итеп күрергә телибез.

Илебездә 115 тән артык милләт яши. Бу, һичшиксез, горурланырлык. Безнең яклар башка милләт вәкилләрен үзенә аеруча җәлеп итә. Татарстанда үзебезнең күпмилләтле халыкка гына түгел, чит илләрдән күчеп кайтучыларга да урын тар түгел.

Республикада күп кенә милли-мәдәни иҗтимагый оешма теркәлгән, аларның күбесе халыклар Ассамблеясында катнаша, бездә Халыклар дуслыгы йортлары бар. Анда “Сотворение мира” тере музыка фестивале уздырыла. Озын көннәр буе тамашачылар башка халыкларның музыкасын һәм аңа гына хас башкару алымнарын, музыка коралларын, атрибутиканы күрә алалар. Бу фестиваль тагын бер кат берләшергә һәм толерантлыкка чакыра. Милли мәдәниятләрне саклау һәм үстерү проблемасын мөмкин булган барлык юллар белән хәл итәләр.

Бөтен дөньядагы тынычлык һәм татулык кешеләрнең бер-берсенә карата никадәр ихтирамлы һәм сабыр мөнәсәбәттә булуына, аларга толерантлык кебек төшенчәнең никадәр таныш булуына бәйле. Толерантлык – барыннан да бигрәк, кешеләр белән тынычлыкта һәм татулыкта яшәүне, башка милләт

халыкларының традицияләренә, мәдәниятенә хөрмәт белән карауны, нинди милләттә, нинди диндә, баймы-ярлымы, сәламәтме-зәгыйфьме булуына карамастан, башка кешене тыңлый һәм ишетә белүне күздә тота.

Дөнья мәдәнияте дигән төшенчә бар. Дөнья мәдәнияте, минемчә, башка халыкның мәдәниятенә кушылуһәм үзең өчен бу халыкның шул ук яхшылык һәм гаделлек кануннары белән яшәве, шул халыкның өмет-хыялларының һәм омтылышларының нәкъ минеке кебек булуы турында ачыш ясау. Бу матур сүзләр генә түгел. Мондый төшенчәләрне укыткан еллар дәвамында студентларыбызның аңына сеңдерәбез һәм бер-берләренә карата яхшы мөнәсәбәттә булуны да үзләре мисалларында тәрбиялибез.

Безнең техникумда да татарлардан тыш башка милләт вәкилләре дә бар. Үзбәкстаннан, Казакъстаннан кайтып төпләнүче кешеләрнең дә балалары, оныклары укый. Алар да төрле чараларда катнаша, техникум данын яклап, спорт ярышларында чыгыш ясый, кыскасы, бик дус яшиләр. Төрле милли бәйрәмнәрдә катнашалар, гомумән, физик һәм рухи яктан ныгырга мөмкинлек алалар. Барысы да үзләренең җыр-биюләрен, гореф-гадәтләрен, осталыкларын күрсәтәләр. Бәйрәмнәр бик күңелле үтә.

Үткән елларда бездә укып чыккан бер азәрбәйҗан егете турында әйтеп үтәсем килә. Ул үзен икенче төрлерәк тота иде, киенү–сөйләшүләр дә башкачарак. Студентлар аны озак кына күзәтте, аңа милләте белән бәйле төрле сораулар бирә иделәр, төрлечә кызыксындылар. Аннан соң ул “үз кеше”гә әйләнде. Монда аның ачык, аралашучан характеры роль уйнагандыр. Әлбәттә, без – укытучылар студентларны яңа милләт кешесе килүгә алдан ук әзерлибез. Шуннан соң алар бу яңа студент белән якыннанрак танышалар, аның милли мәдәнияте үзенчәлекләре турында кызыксыналар, ягъни башка милләт халыкларында нинди гореф-гадәтләр яшәвен, хәзерге гаиләдә аларның кайсылары үтәлүе, безнең республикада яшәүчеләренә нинди кыенлыклар тууын сорашалар. Азербәйҗан егете белән сөйләшкәч тә, студентларны аларның милли гореф-гадәтләренең рус һәм татарларныкы белән охшашлыклары гаҗәпләндерде һәм аңа татар телен өйрәнүдә ярдәм иттеләр.

Һәрберебезгә билгеле булганча, хәзерге җәмгыятьтә яшәүчеләргә изгелек, яхшылык эшләү кебек сыйфатлар җитеп бетми. Бу проблемага кемнеңдер, аның белән тагын да күбрәк кызыксынучының яки зур вәкаләтләргә ия булучының тотынуын көтеп ятарга кирәкми. Безнең толерант булуыбыз үзебездән тора. Бер кешене түземлелек юлына юнәлтеп, без үз өлешебезне кертәбез, чөнки зур йорт кечкенә кирпечләрдән төзелә бит.

Татарстан Җөмһүрияте дә халыклар дуслыгы турында даими кайгыртып яши.

2012 елның август аенда Казанда Татарстан халыклары дуслыгы йортының яңа бинасы ачылды. Ул - Россия Федерациясендәге иң матур һәм иң зур дуслык йорты. Аның ТР халыклары ассамблеясенә 20 ел тулган көннәрдә үз ишекләрен ачуы зур әһәмияткә ия. Анда милли берләшмәләрнең, ассамблея советы башкарма комитеты хезмәткәрләре кабинетлары, “Наш дом – Татарстан” журналы редакциясе, мәгълүмати үзәк, зур актлар залы, конференция залы, сөйләшүләр алып бару өчен бүлмәләр, дуслык музее, тантаналар залы һәм башкалар урнашкан. Яңа бинада Казанның күпмилләтле якшәмбе мәктәбе дә эшли. Төрле милләт вәкилләре спутник телевидениесе аша үзләренең милли тапшыруларын карый .

“Иң мөһиме – төрле милләтләр монда бер мохиткә туплана. Һәм илебезнең, теләсә кайсы төбәкнең иминлеге бөтен милләт һәм диннәр вәкилләренең дус һәм килешеп яшәвеннән, безнең алар арасында ни дәрәҗәдә элемтәләр урнаштыруыбыздан тора. Без моны эшли алабыз, чөнки 29 еллык ТР Халыклары ассамблеясе, Халыклар дуслыгы йорты бар.

Монда бөтенесенә бик уңайлы. Иң мөһиме – шәһәр бик күркәм бинага ия булды. Монда теләсә кайсы илдән, теләсә кайсы төбәктән кунаклар белән килеп була. Аларга биредә үзебезнең бергәләп дус һәм килешеп яшәвебезне һәм эшләвебезне күрсәтергә мөмкин. Мондый элементлар безнең җәмгыятьне, дуслыгыбызны формалаштыра. Бу эштә вак нәрсәләр була алмый”, - диде Рөстәм Миңнеханов.[1]

Президент сүзләренчә, Халыклар дуслыгы йортының яңа бинасы мөнәсәбәтләрне яңа дәрәҗәгә чыгарырга мөмкинлек бирәчәк. “Татарларның өчтән бере генә Татарстанда яши”, - дип билгеләп үтте Рөстәм Миңнеханов, республикадан читтә яшәүчеләргә туган телне, гореф- гадәтләрне, мәдәниятне саклап калуның күпкә авыр икәнлеген белдереп. Ул безнең республикадагы кебек барлык халыкларның мәдәниятләрен, гореф-гадәтләрен саклап калырга ярдәм итү, шартлар тудыру кебек үрнәкнең һәркайда булырга тиешлеген ассызыклап үтте.

“Әгәр без берләшә алсак, кешеләрне милләтләре, диннәре буенча бүлмәсәк, илнең һәр почмагында безгә ихтыяҗ булачак, бернинди конфликтлар да, дошманнарча мөнәсәбәтләр дә булмаячак”, - дип, Рөстәм Миңнеханов, милли-мәдәни мөхтәриятләр җитәкчеләре үзләренең милләт вәкилләре өчен җаваплы икәнлеген белдереп, бу юнәлештәге эшнең бик нәтиҗәле булуын белдерде. “Без мөхтәриятләрдә бөтен мәсьәләләр буенча һәрвакыт аңлау табабыз. Бу кешеләр бик зур күләмдә иҗтимагый эш алып бара, җаваплылыгы зур. Без аларны белергә һәм аларга ярдәм итәргә, аларга таянырга тиеш”, - дип белдерде ул.[1]

“Без бүген бергә булуыбыз белән үзебезнең бердәмлегебезне, илебезнең күпмилләтле икәнлеген, бу илдә менә дигән итеп яши, гореф- гадәтләрне, мәдәниятне саклый алуыбызны күрсәтәбез. Биредә төрле милләт кешеләре берәүгә дә комачауламый, Татарстан тотрыклы үсештә”, - диде президент, бүгенге көнгә урнашкан мөнәсәбәтләрне, бер-береңә ярдәм итү кебек сыйфатларны саклап калу зарурлыгын белдереп. [1]

“Татарстанда халык тынычлыкны, гасырлар буена республикада яшәгән бөтен милләтләр үсешен һәм яшәешен ТР халыклары ассамблеясе, ТР халыклары дуслыгы йорты белән бәйләп карый. Без барысы өчен дә ачык”, - диде Фәрит Мөхәмәтшин.[2]

Республикабызда төрле милләт халыклары үзара дус яшиләр: бер-берсенә кунакка йөриләр, бергәләп күңел ачалар, бәйрәм итәләр. Нәкъ шул турыда «Лехайим» журналының бер санында болай дип язылган: «Татарстан

халыкларының үзара дус яшәвенең сәбәпләре күп илне кызыксындыра. Америкадагы бер хәбәрченең әйтүенчә, әгәр чит илләргә йөз хәбәрче җибәрелсә, аның иллесе Әфганстанга, ә икенче яртысы Татарстанга төрле диндәге халыкларның үзара килешеп яшәү серләрен өйрәнүгә килә. Татарстанга шундый максат белән АКШның Россия Федерациясендәге Гадәттән тыш һәм Тулы вәкаләтле илчесе килгән иде. Ул республикабыздагы төрле дини оешма башлыклары белән күрешеп сөйләште. Илче очрашудан бик канәгать булуын әйтте һәм «Татарстан, дөрестән дә, бөтен дөнья өчен толерантлык, үзара тыныч һәм килешеп яшәү үрнәге булып хезмәт итә ала»,- дип белдерде.

Әйе, сөекле Татарстаныбызда дүрт миллионга якын кеше яши. Күпчелеген татарлар һәм руслар тәшкил итә. Шулай ук чуашлар, марилар, удмуртлар, мордвалар һәм башка халык вәкилләре дә бар. Татарстан халыклары үзара бәйләнешләр нәтиҗәсендә, тел, мәдәният һәм башка өлкәләрдә бер-берсенә йогынты ясап, күркәм тормыш итәләр. Аларның киләчәккә омтылышлары, уй-хыяллары бер-берсенә охшаган кебек. Татар шагыйре Һади Такташ үзенең шигырендә:

«... нинди охшаганбыз,<br>
Ничек охшаганбыз,<br>
Бертуганнар дисәң,<br>
Мин - Тамбовтан, ә син -<br>
Казан артыннан;<br>
Мин бер мишәр улы, кыргый үскән,<br>
Ә син<br>
Күрше чуваш халкыннан...», - дип язган. [3]

Бөек Ватан сугышы елларында халыкларның дус яшәве илгә җиңү китерүгә зур өлеш кертте, шуңа күрә Җиңү көнен һәр елны бергәләп, тантаналы рәвештә билгеләп үтәбез.

Татар әдипләре үзләренең әсәрләрендә халыклар дуслыгы темасын даими яктырталар. Мәсәлән, Л. Ихсанова «Лачын кыз» әсәрендә халкыбызның

каһарман кызы - Советлар Союзы Герое, очучы Мәгубә Сыртлановаың дуслары арасында күптөрле милләт кешеләре булуы турында оста тасвирлаган. Башкалабыз Казанның бер урамы аның исеме белән аталган...

Шушы урында Әмирхан Еникинең “Без дә солдатлар идек” дигән повестена да тукталып китәсем килә. Монда язучы сугыш чорының гадәти генә вакыйгаларына туктала. Анда сугыш кирәк-яракларын саклаучы каравыл отряды сугышчыларының тормышы яктыртыла. Әдип төрле милләт вәкилләренең (казакъ, татар, рус, чуваш) халыкчан образларын иҗат итә, аларның эчке дөньяларын укучыны җәлеп итәрлек итеп ача.

Мәҗит Гафури да сыйнфый көрәш һәмбашка темалар белән беррәттән халыклар дуслыгы темасына да яза.

Республикабыз шәһәрләрендә, авылларында мәчетләр, чиркәүләр шактый күп. Аларның кайберләре янәшәдә генә урнашкан. Дини мәсьәләләрдә толерантлык сизелеп тора. Дини оешмалар үзара киңәшләшеп эшлиләр. «Киңәшле эш таркалмас», - дигән мәкаль бар халкыбызда, бу бик тә дөрес. Мәдрәсәләр, якшәмбе мәктәпләре уңышлы гына эшләп килә. Кайбер дини бәйрәмнәрне ял көне дип тә игълан итәләр җитәкчеләребез.

Дуслык - кешеләр арасындагы мөнәсәбәтләрнең иң әйбәте. Шундый тыныч, матур, бай Татарстаныбызда яшәвем белән мин чиксез горурланам!

... Мин җаным – тәнем белән халыклар дуслыгы яклы... Яшәсен тынычлык!!!

КУЛЛАНЫЛГАН ӘДӘБИЯТ

1. Татарстан республикасы президенты РөстәмМиннеханов чыгышыннан. 29 август, 2012. (Интернет – ресурслардан алынды).

2. Татарстан республикасы Дәүләт Советы рәисе Фәрит Мөхәммәтшин чыгышыннан. 29 август, 2012. (Интернет – ресурслардан алынды).

3. Такташ Һ. Мәхәббәт тәүбәсе: Шигырьләр, поэмалар.- Казан: Татар. кит. нәшр., 1993.-47 б.

Назад

## Средства художественной выразительности в рассказе В.М.Шукшина «Выбираю деревню на жительство»

*Березина Наталья Николаевна*
*преподаватель русского языка и литературы*
*ГАПОУ «Колледж нефтехимии и нефтепереработки*
*имени Н.В.Лемаева» г.Нижнекамск*

*«И воспитание, и образование нераздельны. Нельзя воспитывать, не передавая знания, всякое же знание действует воспитательно»*

*Л.Н.Толстой*

Мы живём в непростое время. Время, когда меняются взгляды на жизненные ценности, когда быть духовно богатым человеком неловко и непрестижно, нежели быть богатым материально. Но как бы не хотелось остановить время, оно неумолимо будет идти вперед, подкидывая нам новые задачи и проблемы, которые надо решать здесь и сейчас.

Через все времена и накопления красной нитью проходят вопросы: «Кем быть? И каким быть?» На вопрос: «Кем быть?» - однозначно отвечают преподаватели, ведущие спецдисциплины в образовательном учреждении. А вот вопрос: «Каким быть?» - требует многогранного ответа. И помочь человеку растущему, готовящемуся вступить во взрослую жизнь может литература.

Один мудрый человек сказал, что человек может прожить только одну жизнь, а вот с помощью книг он проживает еще и жизни их героев.

Подтверждает эти слова французский писатель, новеллист и поэт, творивший на рубеже XIX-XX веков Марсель Пруст: «Только с помощью искусства мы можем покинуть самих себя, узнать, как другой видит вселенную!» Именно эти слова я говорю на своих первых уроках литературы первокурсникам. И хотя мы все понимаем, что читать наши студенты не будут, все равно мы должны знакомить их с классиками художественной литературы и их произведениями.

В программе изучения литературы значатся два блока: городская проза и деревенская проза.

Блок деревенской прозы представлен многими писателями, среди них: Валентин Распутин, Фёдор Абрамов, Борис Можаев, Василий Шукшин.

Произведения Шукшина очень нравятся студентам: они просты по сюжету, короткие по объему, непосредственные, иногда наивные, если судить по сегодняшним меркам. Мы их не только читаем, чтобы узнать содержание, а ещё и проводим связь с русским языком, когда находим средства художественной выразительности.

Анализируя рассказ Шукшина “Выбираю деревню на жительство”, мы вспоминаем, что средство выразительности усиливает эмоциональное воздействие на адресат.

Для произведений Шукшина актуально знать о:

- фразеологизмах (воспроизводимых в готовом виде словосочетаний и предложений, позволяющих усилить наглядность и образность текста).

- диалектизмах (словах, употребляемых на отдельных территориях, создающих местный колорит и речевую характеристику героев).

- жаргонизмах (разговорных словах и выражениях, употребляемых в отдельных социальных группах).

Произведение “Выбираю деревню на жительство” очень интересно и актуально для студентов по многим причинам. Во-первых, мы говорим о тех местах, откуда приехали наши ребята, а среди них много деревенских. Во-вторых, рассказ был написан в 1973 году, почти полвека назад, а проблема переселения людей из города в деревню до сих пор актуальна.

И вот, прочитав произведение, проанализировав его, мы начинаем работать со средствами выразительности. Не секрет, что сейчас наши студенты не знают, что такое фразеологизмы, их значение, и как следствие, мало используют их в речи. Мы составляем таблицу.

| **Фразеологизм** | **Значение** |
|---|---|
| 1) (Не) поймал за руку | (Не) поймать на месте преступления |
| 2) С совестью был в ладах | Уверенность человека в том, что не сделал ничего плохого |

| | |
|---|---|
| 3) Совесть болит | Человек не находит в себе места, переживая из-за своих поступков |
| 4) Свел концы с концами | С трудом справляться со своими нуждами, потребностями |
| 5) Дай бог ночи | Стремление убежать |
| 6) Честь по чести | Как надо |
| 7) Ныла душа | Чувство сильной тоски |
| 8) Бил кулаком в грудь | Клятвенно, крикливо уверять кого-то в чем-нибудь |
| 9) Пропади пропадом | Выражение гнева, будь проклят |
| 10) С ума сошли | Стали ненормальными |
| 11) Сверкать голым задом | Жить в большой бедности |
| **Диалектизмы** | **Значение** |
| 1) Несусветные цены | Нереальные |
| 2) Не обчистил | Не украл |
| 3) Изумляешься | Удивляешься |
| 4) Склочные | Запутанные, хитрые, мудрёные, коварные |
| 5) Оскотинеть | Обнаглеть |
| 6) Не запирает | Не закрывает |
| 7) Небось | Может быть, конечно, как видно |
| 8) Придурки | Балбесы, неуважаемые люди, сброд |
| 9) Сроду никто не зайдёт | Никогда |
| 10) Умолчать | Не сказать |
| 11) Не залупаться | Не придираться, не наглеть |
| 12) Галдеж | Шум, крик |
| 13) Степенный | Уважаемый |
| 14) Завозня | Сарай |
| 15) Пятистенок | Изба с двумя отапливаемыми комнатами |
| 16) Прихоть | Желание |
| 17) Рассудили | Решили |
| 18) А чего ради загибать | Врать, обманывать |

| | |
|---|---|
| 19) Околачиваться | Ходить рядом |
| 20) Про совесть трещать | Говорить |
| 21) Залупаться | Спорить |
| 22) Загашник | Тайник |
| 23) Огрызнулся | Возразил, парировал |
| **Жаргонизм** | **Значение** |
| 1) урка | Преступник, уголовник, вор |

Данная работа помогает вдумчиво читать произведение, обращать внимание на «мелочи», формирует лексическую зоркость.

Шукшин – большой знаток сложных, социально-психологических процессов, происходящих в сознании деревенских тружеников, испытывающих постоянное воздействие городской культуры. Юмор, которым окрашены рассказы Шукшина, выражены непосредственно в языке его героев, представляющем сложное переплетение народных говоров. Он правдиво воспроизводит стихию народной речи, на которой говорят миллионы колхозных тружеников, активно вовлеченных в процессе сближения города и деревни.

В наше время происходит «стирание граней» между городом и деревней. Говоря о диалектизмах, я спрашиваю иногородних ребят, какие слова употребляются только в их районе и непонятны для других. Они таких слов не находят. Телевидение и интернет делают свое дело… уходят из жизни носители диалектизмов, а вместе с ними уходят и слова, придающие особенный колорит местности.

ЛИТЕРАТУРА

1. В.М.Шукшин «Выбираю деревню на жительство»

2. Электронная библиотека **жаргонных словарей** русского языка

3. https://russkie-poslovitsi.ru/slovar/

4. http://fraze.ru/index.php/frazeologizm

**Назад**

## Особенности использования средств языковой выразительности (экзотизмов, варваризмов, диалектизмов, профессионализмов, жаргонизмов) в художественной литературе и их роль в произведении

*Бокова Вера Леонидовна,*
*Преподаватель русского языка и литературы*
*ГАПОУ «Мензелинский педагогический колледж имени М. Джалиля», г. Мензелинск*

Средства выразительности не только обогащают речь тем, чтодополняют основные единицы языка определенными конструкциями и приемами, привлекают внимание читателя или слушателя, придают речи яркость и наибольшую выразительность, но становятся помощниками в осознанном понимании языка как культурной ценности.

Безусловно, осознанное восприятие изобразительно-выразительных средств языка способствует развитию эстетического сознания, активизирует процессы творческой деятельности, отражает такие явления языка, которые делают речь не просто средством общения, а предметом и средством познания культуры, средством создания произведений искусства, которые ложатся воснову литературного наследия страны.

С середины XX в. язык художественной литературы стал объектом изучения языкознания и стилистики. О внимании к художественному слову говорят многочисленные статьи и монографии, посвященные вопросам стиля и языка художественной литературы. Однако, несмотря на наличие целого ряда работ, многие вопросы остаются дискуссионными, а некоторые аспекты неполно изученными. Все это позволяет говорить о несомненной важности и актуальности изучения лексико-грамматических средств выразительности.

В отличие от литературного языка, язык художественной литературы формируется с помощью различных языковых средств. Как отмечает В.В. Виноградов, многие за язык художественной литературы принимают литературный язык, хотя последний гораздо уже. Главной целью языка художественной литературы является выразительность и экспрессивность. Автор для достижения художественно-эстетического эффекта

целенаправленно не сторонится нарушений общелитературных языковых норм, включая в свои произведения нелитературные формы языка [1].

К ним можно отнести: экзотизмы, варваризмы, диалектизмы, профессионализмы, жаргонизмы и др.

Диалектизмами называются самобытные слова и обороты речи, присущие жителям определенной местности. В художественной литературе они выполняют ряд важных функций: являются источником речевой экспрессии; передают местный колорит и особенности речи героев; конкретизируют эпоху изображаемых событий; служат средством речевой характеристики персонажа.

Обращение к диалектизмам связано со стремлением писателей наиболееточно и правдиво отразить жизнь народа, передать «простонародный» колорит. Среди таких авторов, например, И.А. Крылов, А.С. Пушкин, Н.В. Гоголь, Н.А. Некрасов, И.С. Тургенев, Л.Н. Толстой и др.

У И.С. Тургенева часто встречаются слова из орловского и тульского говоров (большак, гуторить, понева, зелье, волна, лекарка, бучило и др.).

С.А. Есенин, пытаясь передать деревенский быт рязанских крестьян, в своих стихотворенияхтакже употребляет диалектизмы. Например: в ветхом шушуне - вид женской верхней одежды; в дёжке квас - в бочке из дерева; драчёны - еда из яиц, молока и муки.

Много «местных» слов встречается в произведениях В.Г. Распутина: захолонуть - замерзнуть, охладеть; покуль - пока, до свидания; гулеванить - буйствовать, бушевать.

М.А. Шолохов в «Тихом Доне» посредством диалектного говора передает всю красоту казачьей речи: баз - крестьянский двор; крыга - льдина; зябь - целина; займище - заливной луг.

Под профессионализмамипонимают слова и выражения, используемые в различных сферах деятельности человека, не ставшие при этом общеупотребительными. Чаще это обозначения орудий труда, действий, продукции, деталей производственных процессов и т.д.

В литературном языке они являются источником речевой экспрессии, служат характерологическим средством персонажа: по употребляемым в речи профессионализмам можно с определенной долей уверенности предположить, чем занимается герой произведения.

Так, профессионализмы встречаются в поэзии В.В. Маяковского, например, в стихотворении «Разговор с фининспектором о поэзии»: «Говоря по-вашему, рифма - вексель. Учесть через строчку! - вот распоряжение. И ищешь мелочишку суффиксов и флексий в пустующей кассе склонений и спряжений».

В романе И. Ильфа и Евг. Петрова «Двенадцать стульев»Никифор Ляпис, создатель новой «Гаврилиады», вводит в свои шаблонные тексты профессионализмы в целях продемонстрировать доскональное знание предмета, однако делает это неумело. Сотрудники газеты «Станок», убеждаясь в незнании Ляписом значения отдельных слов, высмеивают его очерк, повесивего на стену и обведя траурной каймой. Очерк начинался так: «Волны перекатывались через мол и падали вниз стремительным домкратом...».

Жаргонизмы представляют собой слова, ограниченные в своем употреблении определенной социальной или возрастной средой. Несмотря на то, что в литературном языке у жаргонизмов есть много семантических синонимов, функции, которые они выполняют в речи, делают их важным стилистическим средством. К стилистическим функциям жаргонизмов относятся: придание речи экспрессивности, выразительности; речевая характеристика персонажа; передача колорита окружающей обстановки.

В художественной литературе жаргонизмы также имеют место быть. Например, так называемый «денежный жаргон» неоднократно встречается в произведениях Н.В. Гоголя. Так, в «Мертвые души» Собакевич, продает души за «угол» (угол - это 25 руб.), а Плюшкин, не желает платить «красную бумагу», т.е. 10 руб., за оформление купчей.

В рассказе А.И. Солженицына «Один день Ивана Денисовича»жаргонизмы являются языковыми акцентами, которые создают

осязаемый образ лагеря и его обитателей. Наиболее значимые моменты лагерного быта окрашены жаргонизмами: ежедневная похлебка - баланда, порции хлеба - лайки, жилище зэков - вагонка, туалетные бочки - параши, ежедневные утомительные обыски - шмоны.

Живым, активно развивающимся языкам свойственно взаимодействие, в процессе которого иностранные слова проникают в язык-основу, привнося что-то новое. Некоторые заимствования настолько органично вошли в его лексическую систему, что воспринимаются как чисто русские. Другая часть, наоборот, сохраняет аромат языков-доноров [2; 77 с.]. К ним относятся экзотизмы и варваризмы.

Экзотизмы - это слова иноязычного происхождения, обозначающие реалии «чужой» культуры, т.е. такие реалии, которые не стали заимствованиями, а следовательно, отсутствуют в российской действительности[3; 208 с.].

Функции, выполняемые экзотизмами в художественных текстах, разнообразны: отражение отношения автора к проблеме лексических заимствований; речевая характеристика персонажей; живописное изображение быта других народов; демонстрация прогрессивности; сатирическое изображение действительности или героя.

Так, в поэме «Кавказский пленник» А.С. Пушкин использует экзотизмы, которые позволяют изобразить быт, нравы горских народов, а также достоверно передать местный колорит: «Под влажной буркой, в сакле дымной, Вкушает путник мирный сон»; «… К его устам кумыс прохладный Подносит тихою рукой...».

Н.М. Карамзин в своем произведении «Письма русского путешественника» также использует экзотизмы: «У дверей всякой генгеты стоят женщины с цветами. Тут молодой растрепанный франт встречается с пожилым, нежно напудренным петиметром, смотрит на него с усмешкою и подает руку оперной».

Варваризмы – это иноязычные слова, имеющие соответствия в принимающем языке, однако употребляемые в устной или письменной практике в силу моды, не зафиксированные толковыми словарями и не знакомые многим представителям языкового сообщества.

В художественной литературе в качестве варваризмов могут восприниматься: особенности произношения, например в произведении Д.И. Фонвизина «Недоросль» Вральман говорит: «Тай фолю этим плеклятым слатеям. Ис такой калафы толголь палфан?»; формы словообразования и синтаксические обороты, например, рассказ Ипполита в «Войне и мире» Л.Н. Толстого: «В Moscou есть одна барыня, une dame… И она имела une femme de chambre, ещè большой росту».

Использование варваризма в романе А.С. Пушкина «Евгений Онегин»: «Приходит муж. Он прерывает сей неприятный tête-a-tête».

Также у Л.Н. Толстого в романе «Война и мир»: «Анна Павловна кашляла несколько дней, у ней был грипп, как она говорила». В то время слово «грипп» былоновым и употреблялось редко.

В качестве художественного приема варваризмы применяются: для достижения комического эффекта: «Но панталоны, фрак, жилет, Всех этих слов на русском нет» (А.С. Пушкин, «Евгений Онегин»); для создания местного колорита; для указания на высокое социальное положение действующих лиц.

По мере повторяемости варваризмы усваиваются языком и перестают быть стилистическими варваризмами, превращаясь в слова иностранного происхождения, заимствованные в различные эпохи культурных отношений у других народов.

Таким образом, в произведениях художественной литературы помимо литературного языка, как основного, содержатсяместныеговоры и диалекты, профессиональные диалекты, жаргонизмы, слова, заимствованные из иностранных языков и представленные в нем в качестве экзотизмов и варваризмов. Все перечисленные элементы нелитературной лексики являются

неотъемлемой частью национального русского языка. В художественной литературе они позволяют придать речи экспрессивность, передать местный колорит и особенности речи героев, конкретизироватьвремя изображаемых событий, живописно изобразить быт других народов. Нелитературные формы языка выполняют важную художественную роль: позволяют обогатить литературный язык, а также помогают писателям и поэтам погрузить читателей в атмосферу той или иной эпохи, группы людей, передавая основные детали характеров и поступков героев, делая их образы яркими и запоминающимися.

ЛИТЕРАТУРА


1. Евдокимов А.Н. Диалектная и просторечная лексика в художественном дискурсе Е.И. Носова: На материале рассказов писателя: автреф. дис. … канд. филол. наук. Курск, 2005. 223 с.
2. Воронкова И.С. О понятиях «экзотизмы» и «варваризмы» // Вестник Воронежского государственного университета. 2006. № 2. С.77-79.
3. Немченко В.Н. Основные понятия лексикологии в терминах: Учебный словарь-справочник. Н. Новгород, 1995 С. 208 с.


Назад

## Татар һәм рус әдәбиятында халыклар дуслыгы чагылышы темасы

*Бутакова Гулия Сафаргалиевна,*
*преподаватель родного языка и литературы,*
*ГАПОУ “ Заинский политехнический колледж”*

Кеше тормышында аның бөтен гомере буена аерылгысыз төшенчәләр, кешеләр, әйберләр була. Шуларның берсе - аның туган теле. Ул – кешенең дөньяга аваз салган минутыннан соңгы сулышына кадәр янәшә. Кеше үзенең иң саф хисләрен бары тик туган телендә генә белдерә ала. Безнең максатыбыз-туган телебезне, тарихыбызны, рухи байлыкларыбызны, гореф-гадәтләребезне өйрәнеп, буыннар арасында ныклы бәйләнеш булдыру, бөек милләт булып яшәвебезне дәвам итү. Республикабызның күп милләтле икәнен исәпкә алсак, Татарстан халыкларының үзара дус, тату яшәве – кешеләр арасындагы

мөнәсәбәтләрнең иң югары ноктасы булып тора. Быелгы елның Татарстанда “Туган телләр һәм халыклар бердәмлеге елы” булуы да күп нәрсә турында сөйли. Төрле милләт халыклары бер-берсенең мәдәниятен, яшәү рәвешен,гореф-гадәте, йолаларын өйрәнә һәм шулар аша бер-берсенә хөрмәт тәрбияли, үз итә, дуслыгын ныгыта. Бүгенге көндә милли бәйрәмнәребез яңадан торгызылып, яңартылып, заман төсмерләре биреп үткәрелә башлады. Буыннан-буынга күчеп килгән бу рухи байлыкларыбыз безнең тормышыбызның, яшәешебезнең бизәге булып тора. Аларны халык белә, хөрмәт итә икән, милләт яши, милләт яшәгәч, тел яши, ягъни тормыш дәвам итә.

Халыклар арасында дуслык бәйләнешләрен ныгытуда исә әдәбият элек-электән зур роль уйнаган.Әсәрләр аша төрле милләт халкының күңел җәүһәрләрен барлыйбыз, үткәнен киләчәк буыннарга җиткерәбез, киләчәккә ышанычын арттырабыз, милләтләребезне саклауда бер юнәлеш булуын азсызыклыйбыз. Чөнки әдәбият аша гына халыкның бик тирәндә яткан сыйфат-хасиятләрен, үзенчәлеген, милли рухын тоеп, сиземләп була.

Үткәннәргә күз салсак, галимебез К.Насыйри беренчеләрдән булып башка халыкның телен өйрәнүне, халыкның рухын аңлау, шул халыкны хөрмәт итү идеяләрен билгеләгән. Ул бөтен гомерен халыкны агартуга, аның культурасын күтәрүгә багышлый. Әдәби, тарихи, педагогик хезмәтләре, татар халкының телен гыйльми калыпларга салуы, русча укытуга керешүе, кагылу-сүгелүләргә карамый, олы максатларга баруы К.Насыйрины фидакяр галим, энциклопедист-мәгърифәтче итеп таныта. Аның Ватанга мәхәббәт, халыклар арасында дуслык, туганлык турында гади әйтелгән зирәк сүзләре, бүген тагын да тирән мәгънә алып, яңача яңгырый.

Пушкин – Тукай... Бөек шагыйрьләр. Бөек шәхесләр. Ике халык язмышында алардан да бөегрәк кешеләр бармы икән?Казанда Пушкин урамында М. Җәлил исемендәге опера һәм балет театрының бер ягында Пушкин һәйкәле, икенче ягында Тукай һәйкәле булуы ук символик әһәмияткә ия. Еллар, гасырлар үткән саен алар тагын да биеккәрәк күтәрелә. Киләчәктә

дә аларга кабат-кабат әйләнеп кайтачаклар. Чөнки бу шагыйрьләр үз халкының милли рухын чагылдыра. Бу миллилек халыкның уй-фикерләрен, теләкләрен, хисләрен тирән аңлауда чагыла. Тукай үзен хаклы рәвештә Пушкинның укучысы дип саный. Ул шәрыкъ шагыйрьләреннән беренче булып Пушкинның реалистик традицияләрен дәвам итә, реалистик әдәбият, балалар әдәбияты өчен көрәшә һәм аны нигезли.

Габдулла Тукайның «Әлгасрелҗәдид» журналының 1906 елгы 15 нче апрель санында «Г.Тукаев» имзасы белән басылган “Пушкинга” шигыре дә бөек рус шагыйре А.С.Пушкинга булган хөрмәтенраслый:

Тиңдәшсез шагыйрь булдың (афәрин!), Пушкин Александр!

Минем дә дәртем-теләгем нәкъ синең дәртең белән бер.

Синең шигырең көенә агач, таш бии, минемчә;

Биемәслек итеп язу кимчелек шагыйрь кешегә.

Якты кояшка тиң шигырь алдында ник биемәсен;

Илаһи илһамга ия булган көчле шагыйрь бит син.

Күңелгә күләгә төшми, — шигырьләрең якты шундый,

Гүя бөтен дөнья балкый алтын кояш яктысында.

1913 елда Романовлар династиясенең 300 еллыгы уңаеннан язылган “Олуг юбилей мөнәсәбәте белән халык өмидләре” шигырендә Тукай рус халкы белән бергә дус булып яшәү турында болай яза:

*Урыс белән тормыш кичердек сайрашып,*

*Тел, лөгать, гадәт вә әхлак алмашып.*

Бер җирдә яшәүче рус һәм татар халкының күпгасырлык дуслыгы, күңел түрендәге уртак максатка бергәләшеп тарихи хәрәкәте турында да бу шигырь:

Һич бетәрме тарихи бу бергәлек? –

Без туган бер җепкә бергә теркәлеп.

Гомумән, кайсы гына шигырен алсак та, анда аң - белемне үстерергә, дус - тату, бердәм булырга кирәклек әйтелә. “Дусларга бер сүз шигырендә”:

И кардәшләр, кул тотышып алга барыйк,

Башка милләтләрнең хәлен карап карыйк;

Мәдәният мәйданында урын алыйк,-

Егъла-тора алга таба атлыйк имди,- дип яза [Тукай Г. 1985 : 42 ] .

“Иттифакъ хакында” исемле шигырендә бөтен татар дөньясы бер тән, бер җан булып, уйда, фикердә, гамәлдә берләшеп хәрәкәт итәргә тиешлекне әйтә.

Нәкъ менә шул халыкларның тарихи бергәлеге татар шагыйрен иҗатка рухландырган да инде. Бу идея XX гасыр шагыйрьләренә генә хас булмый. Әлеге проблеманы бу шигъри юллар язылганчы күп еллар алдан ук бөек төркмән классигы Махтумкули Фраги күтәреп чыга, халыкларны бердәмлеккә һәм оешканлыкка чакырып, үзенең «Держава туркмен» шигырен иҗат итә.

Туркмены!

Если бы мы дружно жить могли,

Мы осушили бы Нил,

мы б на Кульзум пришли!

Теке, йомуд, гоклен, языр и алили,

Все пять – должны мы стать единою семьею.

Г.Тукай иҗатында аерым бер урын алып торучы тәрҗемә эшчәнлеге хакында да әйтми булмый. Моңа кадәр гел шәркый традицияләр белән үскән Тукай XX йөз башында Европа әдәбиятына йөз белән борыла. Рус һәм Көнбатыш шагыйрьләренеңәсәрләрен ирекле тәрҗемә итү һәм иҗади файдалану белән Тукай татар поэзиясенә яңа тема, мотив һәм сурәтләр алып килә. Ул тәрҗемә эшчәнлеге аша татар әдәбиятын дөнья эстетик хәрәкәтенә якынайту, кушу өченбик кирәкле эш башкара. Тукай бит теләсә нинди әсәрне тәрҗемә итми, теләсә нинди фикерне алмый, ә инде “изге”фикерләренә, әдәби интересларына якын, теләктәш булганнарын гына кабул итә һәм үз иҗатын баета. Рус һәм Европа классиклары белән бәйләнеш Тукай поэзиясендәге традицион стиль катламнарының һәм җанр формаларының үзгәрешенә дә нык йогынты ясый. Шагыйрьнең беренче шигъри тәҗрибәсендә, халык җырларының, Көнчыгыш, аеруча төрек поэзиясенең XIX йөз мәгърифәтчелек әдәбиятының да йогынтысы сизелә. Г.Тукайның бөеклеге шунда, ул культура тәҗрибәсен үз халкыныкы белән генә чикләми, барлык алга киткән

милләтләрдән үрнәк алырга, аларның тәҗрибәсен өйрәнергә һәм прогресска ирешү өчен, шул тәҗрибәне иҗади кулланырга чакыра, үзе исә публицистикасы һәм шул халыклар әдәбиятын тәрҗемә итеп бу эшкә зур өлеш кертә. Г.Тукай алдынгы художество әдәбиятын, бөек рус әдәбиятын матбугатта тәрҗемә итеп бастырып чыгару юлы белән пропагандалый. Тәрҗемә өчен әсәрләр сайлап алганда ул нәкъ менә сыйнфый караштан чыгып эш итә: татар укучысына русчадан һәм башка телләрдән халык рухына туры килердәй гуманистик рухлы, искелекне инкарь итүче, азатлык идеяләре белән сугарылган әсәрләр тәкъдим итә.

Г.Тукай үзенең әсәрләрендә рус авторларының образларын теләп куллана. Бу образлар үткенләндереп җибәрү өчен дә, татар укучысын рус әдәбияты белән кызыксындыру өчен дә кулланыла. Г.Тукайның рус халкына, аның культурасына җылы мөнәсәбәте “Бер татар шагыйренең сүзләре”, “Кыйтга”, “Пушкинга”, “Пушкинә”, “Пушкин вә мин”, “Җавап”,”Бәйрәм вә дуслар”, “Толстой фикере”, “Толстой сүзе”, “Толстой сүзләре”, “Граф Лев Толстой җәнапләре язадыр”, “Толстой хакында мәшһүр татарларның фикерләре” кебек әсәрләрендә күренә.

Үз чиратында, бөек рус шагыйре А.С.Пушкин әсәрләрендә дә башка милләт халкына булган хөрмәт күренә. Ул үзенең иҗатының барлык халыклар тарафыннан да өйрәнеләсен һәм бәяләнәчәген күзаллаган. Бу турыда аның түбәндәге шигырь юллары сөйли:

Слух обо мне пройдет по всей Руси великой,
И назовёт меня всяк сущий в ней язык,
И гордый внук славян, и финн, и ныне дикой
Тунгуз, и друг степей калмык...

Төрле милләт кешеләре арасындагы гүзәл мөнәсәбәтләр каләм осталарын хәзер дә рухландыра, аларга бетмәс-төкәнмәс илһам чыганагы бирә.

Казанда Татарстан халыкларының Дуслык йорты бар. Бу йорт- Татарстан халыклары ассамблеясенә берләшкән милли-мәдәни җәмгыятьләргә ярдәм

күрсәтүче, 1999 нчы елдан эшләп килүче, Татарстан Республикасы бюджетыннан финанслаучы муниципаль, иҗтимагый оешма.

Максаты – Ансамблеягә кергән милли-мәдәни җәмгыятьләргә, милли оешмаларга дәүләт ярдәмен күрсәтү, Татарстан халыкларының мәдәниятын торгызу, аны саклау һәм үстерү. Бүгенге көндә Дуслык йорты – Татарстан халыклары Ассамблеясе һәмреспубликадагыэтник мәдәни хәрәкәтнең үзәк мәйданы.Дуслык йорты - һәр көнне эшли торган һәм һәркемгә монда кызык булырдай урын. Бу йортка кем генә кайчан гына килеп керсә дә, Татарстан турында һәм биредә яшәүче халыклар һәм республиканың милли сәясәте турында тулы мәгълүмат алу мөмкинлеге бар.

29 нчы гыйнварда Татарстан халыкларының Дуслык йортында Туган телләр һәм халыклар бердәмлеге елына багышланган чара узды. Парламент башлыгы елның әһәмияте турында фикерен әйтте.

«Татарстан халыклары ассамблеясе ешкына тел, этномәдәнилеккә бәйле тәкъдимнәр белән чыга иде, ә буюлы шушы елны Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов игълан итте. Билгеле, бутәкъдимне республикадагы барлык халык вәкилләре хуплады», — дип билгеләп узды Фәрит Мөхәммәтшин.Улбуелның бай программасы әзерләнгәнен искәртте. «Барлык чараларда бик актив катнашачакбыз. Программага тәкъдимнәрне дә керттек. Бу төрле халыклар арасында үзара ышаныч, дуслыкны тагы даарттырачак. Безнең өчен бухалыкара дуслык бик кыйммәтле. 173 милләтнең теле, традицияләре, гореф-гадәтләре безгә кадерле»,— дип белдерде.Дәүләт Советы Рәисе халыклар ассамблеясенең әһәмияте турында әйтте. «Минемчә, төбәкләрдәге халыклар ассамблеясе төрле дин һәм милләт вәкилләренең имин, тату тормышына зур өлеш кертә. Бунечкә, җаваплы эш, һәм республикада улҗитди дәрәҗәдә», — диде.

Халыклар дуслыгы – безнең иң зур байлыгыбыз. Төбәгебез халкы милли яктан бер-берсе белән якыннан аралашып, “тел-лөгать алмашып” яшәгән, яши һәм яшәр!

КУЛЛАНЫЛГАН ӘДӘБИЯТ

1.Тукай Г..Әсәрләр: Шигырьләр, поэмалар. - Казан: Татарстан китап нәшрияты, 1985. – 256 б.

2.http://gabdullatukay.ru/works/poem/1905/ittifak-hakynda/

3.https://tt.wikipedia.org/wiki/Каюм_Насыйри

4.http://addnt.ru/tt/

Назад

## Әдәби әсәрләрдә (экзотизм, варваризм, диалектизм, һөнәрчелек, жаргоннар) сурәтләү чараларын куллану үзенчәлекләре һәм аларның әсәрдәге роле

*Габдуллина Гөлчәчәк Мөхтәр кызы,*
*ДАҺБУ "В.П. Лушников исемендәге*
*Казан нефть һәм химия көллияте"нең*
*татар теле һәм әдәбияты укытучысы, Казан ш.*

Татар әдәбияты меңьеллык әдәби мирасы, бай язу культурасы, стиль үзенчәлекләре, жанрлар төрлелеге белән бөтен дөнья мәдәниятенә зур өлеш керткән әдәбият. Менә шушы бай мираслы әдәбиятка өлеш кертү юнәлешендә зур көч куйган әдипләр арасында язучы, журналист Дамир Гыйсметдин да бар.

Дамир Гыйсметдин чыгышы белән Чуаштан Республикасыннан. Аның«Чаян» журналы һәм башка көндәлек матбугат битләрендә юмор-сатира жанрындагы күп кенә хикәяләре, усал эчтәлекле фельетоннары бастырыла. Кайбер юмор-сатира әсәрләре Мәскәү басмаларына да урнаштырыла.Ул — Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре. 2002 нче елдан Д. ГыйсметдинТатарстанЯзучылар берлеге әгъзасы.

ДамирГыйсметдин – юмор-сатира әсәрләре тупланган өч китап авторы («Өметсез шайтан», 1990; «Әйтсәм әйтим», 1999; «Атта да, тәрттәдә дә…», 2007). 2014 нче елда басылып чыккан "Божра буйлап: повесть, хикәяләр, публицистик язмалар һәм сәяхәтнамәләр" китабы да тел-сурәтләү чараларына бик бай булуы белән үзенә тартып тора.

Тел-сурәтләү чараларының әдәби әсәрләрдә күпләп кулланылуы образларны ачарга, аларның характерларын күрергә ярдәм итә. Әсәр теленең

гадилеге, халыкчанлыгы, кызыклы булуы һәрбер укучыда матур әдәбиятка мәхәббәт уята.

“Божра буйлап ” повестендагы герой Марат Сабировка журналист буларак үз гомерендә күп җирләрдә булырга туры килә. Әсәрдә герой тормыш юлынпоезд тәгәрмәчләредәй тәгәрәү беләү чагыштыра. Үзенең гомер йомгагын кирегә сүтеп, “Балачак”, “Үсмер чор”, “Яшьлек”, “Өлгергән”, “Җитлеккән”, “Картлык” тукталышларын барлый. Дөньяның кайсы почмагына барып чыкса да, ул беренче булып милләттәшләребез белән очраша. Кемнәр белән генә очрашмый, нинди генә язмышлы кешеләр белән аралашырга туры килми аңарга. Бу китабында сәфәрләре барышындагы тәэсирләре яктырта, үзенең гомер тәгәрмәченең әйләнешен, еракта калган хатирәләрен яңарта.

“Божра буйлап ” повестендагы тел-сурәтләү чараларына тукталасым килә. Аларның да варваризм, экзотизм, диалекттөрләренә.

Варваризм — чыганак телдәге бөтен үзенчәлекләрен саклаган чит тел сүзе. Варваризм кабул итә торган телнең закончалыкларына тулысынча яисә бөтенләй буйсынмаган хәлдә телдә яшиләр.

Әсәрдә түбәндәге варваризмнарны санарга була.

Эшен яхшы белә, шельма!(Чая хатынның осталыгына ишарә ясый.) [1-3]

Сужденному утонуть молния не страшна! [1-4]

Кешеләргә бер-берсенә сихер яки психик энергетика аша тәэсир итүне өйрәтергә ярамый. Категорически! Недопустимо![1-4]

- Дальше что? (Марат Хәлил белән сөйләшүендә рус һәм татарчаны кушып сөйләшә).[1-8]

- Нәрсә, миллионерша, дебет-кредит, сальдо-бульдо килеп чыгамы? – Марат акча санаган Розалияне арттан кочаклап ала.[1-12]

Кинәт Хәлил йоклаган бүлмәдән... җен-пәриләр котыруын хәтерләткән какофония ишетелә башлады.[1-12]

Кайдадыр промотал, опилка баш! ( Марат Хәлилнең акчаны тотуына ризасызлык белдерә).[1-12]

- Слабак!-дип мыгырданды буфетчы хатын.[1-17]

- Маладис, улым, расхутлар бик күп... [1-20]

- Галия, пади сюда! Сматри кто здесь едит! Пулный сурприз! – диде Малик. [1-51]

- Мин сине не забыл, шельма, -диде ул.- Учти, мин злапамятни, Сабиров (Марат Сабировның авылдашы Малик Изахов-Салатов белән очрашуында). [1-52]

Французлар әйтмешли, бу дежавю иде(“Мәскәү-Тула” поездындагы очрашу исенә төшә).[1-32]

- Галия, пади сюда! Сматри кто здесь едит! Пулный сурприз! – диде Малик. [1-51]

- Мин сине не забыл, шельма, -диде ул.- Учти, мин злапамятни, Сабиров (Марат Сабировның авылдашы Малик Изахов-Салатов белән очрашуында). [1-52]

Диалекталь сөйләм үзенә генә хас үзенчәлекләре белән ул халык арасында гына яшәми, әдәби әсәрләргә дә керә, алар белән бергә татар әдәбиятын баета. Әсәрдә бу төр үзенчәлеккә дә мисаллар китерергә була.

Сибай Маратны таныды:

- Әйдә, братан, тартып җибәр әле безнеңчә, мишәрцә (диалект сөйләме). [1-22]

Бола ешрак чуваш пиччәләрен... Зөягә агызып китә (диалект сөйләме). [1-36]

-Син нәрсә, пацан, охренел, да?!.. Магаза могут повязать? Монысы нацар![1-23] Сабантуйларны чуваш акатуйлары белән бергә уздыру гадәткә керде( татар һәм чуаш авылларын бергә кушып, уртак колхоз булдыралар). [1-26]

МаратСабиров авыл сабан туйларын хәтерендә яңарта:

- Юрамас! Нильза! Пулше так ни китать! [1-28]

- У тибя ещо адин падхуд!-диде судья.[1-28]

- Сизгә азрак бикләмәк кирәк!-дип ымлады бер хәрби (Марат Сабиров Чечен генералы Дудаев белән очрашуга баргач).[1-43]

“Божра буйлап: повесть, хикәяләр, публицистик язмалар һәм сәяхәтнамәләр” җыентыгында бирелгән“Һәркемнең үз кайгысы” хикәясеннән дә экзотизм һәм варваризмнарга берничә мисал.

Экзотизм — теге яки бу халыкның үзенчәлекле милли сыйфатларын һәм көнкүрешен белдерүче чит тел сүзләре. Бу сүзләр фәнни, публицистик һәм матур әдәбиятта кулланылалар. Әдәбиәсәрдә теге яки бу мәгънәгә бәйле булган исемнәр, фамилияләргеройга характеристика да бирәләр.

Әлеге хикәядә Миргалим исемен язучы дөнья гизгән сабыр, тәрбияле егеткә бирә.

Морфлотта сигез ел хезмәтен тутырып кайткан Миргалимгә көймәнең ниндиендә генә йөзәргә туры килмәде. [1-59].

Марфлут (аңа шундый кушамат бирәләр авылда) сайлаган кызны да гаиләсендә дөрес тәрбия алган, иртәдән алып кичкә кадәр тормыш мәшәкатьләреннән арынмаган, зәңгәр күзле, чибәр, мәхәббәт өчен яратылган кызны да Сылуҗан дип атый.

Варваризмга мисалларны да хикәядә табарга була.

- Тозларга штули аларны! (Сылуҗанны эти-әнисеннән сораганда, алары ризалык белдерәләр). [1-65]

- насыпушка салды (үзләренә яшәп торырлык урын). [1-66]

- бу юлы гарантираванный фатир... (Сылуҗан күршесе Сәриягә мәңгелек йорт турында аңлата). [1-66]

Гади сөйләм - гомуми сөйләмнән аерылып торучы, билгеле бер иҗтимагый төркем вәкилләре сөйләшүенә хас булган, ясалма сүзләр белән баетылган сөйләм

Түбәндә китерелгән җөмләләр гади сөйләмгә мисал.

- Эшләр дачурта! Завудка урнашасы...ежлишто(Миргалим Сылуҗанны алып шәһәргә китеп бара) [1-66]

- Кече уллары Фәнис всүтәки хәмер ярата. [1-62]

-лутче син үз өстеңә ал (Надыйр Фәнискә гаепне үзенә генә алырга куша). [1-62]

- миңа барыбер бер канис! (Улы Фәнис Сылуҗанны куркытып, әнисенә кычкыра). [1-64]

Йомгаклап шуны әйтәсе килә: варваризм, экзотизм, диалект сүзләре һәм жаргоннар әдәби әсәрләрдә аерым урын алып торалар. Ләкин кайсы гына әдәби әсәрне алсак та, бу төр күренешләрне табарга була.

КУЛЛАНЫЛГАН ӘДӘБИЯТ

1.Божра буйлап: повесть, хикәяләр, публицистик язмалар һәм сәяхәтнамәләр/ Дамир Гыйсметдин.- Казан: Тат. кит. нәшр., 2014. – 254 б.

2. Әдәбият белеме: Терминнар һәм төшенчәләр сүзлеге. – Казан: Мәгариф, 2007. – 231б.

Назад

## Удивительное - рядом

*Галиева И.М., Шайсуварова Л.Х.,*
*преподаватели ГАПОУ «Мензелинский педагогический колледж имени Мусы Джалиля», г.Мензелинск*

…Идёт урок русского языка. В начальной школе. Молодая учительница заявляет: «Дети, запоминайте, в русском языке шесть падежей. Их названия…». Дети запоминают и в средней школе, на радость учителю, бойко отвечают: «В русском языке шесть падежей!» В нашем педагогическом колледже – ответ тот же. Когда спрашиваешь: «А всегда ли так было?», студенты молча улыбаются или утвердительно кивают головами.

Нет, не интересуются наши дети с прошлым языка, не знают они о звательном падеже. И двойственного числа им не нужно. И «алеф»-«голова быка» в перевёрнутом виде (Буква «А») современного ребёнка мало волнует… Потому что в сегодняшней школе предметом изучения является современныйязык. Раз так, вопросы истории языка отпадают сами по себе. В результате, язык - этот сложнейший организм, постоянно изменяющийся, находящийся в непрерывном развитии, - предстает перед учениками как нечто застывшее, неизменное, перегруженное большим количеством непонятных

школьникам исключений, представляющих собой осколки былой системы языка.

Всякое познание начинается с удивления. Эта бессмертная фраза принадлежит Аристотелю (384 год до н.э. – 322 год до н.э.). Действительно, удивление предшествуют любому научному познанию, ведь познание — это попытка ответить на вопрос о некоторой загадке, которая пока неизвестна. Очень часто нужно уметь удивиться тому, к чему все остальные люди привыкли и считают чем-то само собой разумеющимся. Научное познание открывается здесь, как искусство удивляться обычному. Привычка говорит нам: «Нет ничего удивительного!». Наука протестует: «Всё удивительно и таинственно!». Но удивление порождает непонимание — ведь удивительно то, что происходит, хотя не должно было бы происходить. Возникает вопрос: «Почему?».Так начинается научное познание.

Удивление на уроке есть момент пробуждения интереса к предмету изучения. В преподавании языка особое значение приобретает развитие интереса к предмету.

Очевидно: воспитанию интереса к языку и привитию национальной гордости, несомненно, будут способствовать знания о том, откуда есть пошла азбука, кто был ее создателем, какие произведения являются древнейшими памятниками письменности, о чем рассказывают берестяные грамоты и летописи, когда и кем была напечатана первая книга. Исторические экскурсы на уроках родного языка должны помочь учащимся сознательно усваивать учебный материал, убедить их в том, что современные литературные нормы являются закономерным результатом длительного процесса развития и совершенствования языка. При отборе учебного материала для исторического комментирования на уроках главное внимание должно быть уделено его практической направленности. При этом следует помнить о важнейшем принципе дидактики - доступности, учете возрастных особенностей и уровня развития учащихся определенного возраста.

Исторические справки могут явиться ценным средством создания проблемных, поисковых ситуаций на уроках родного языка. Посильные справки о происхождении слов и выражений, об истории грамматических форм - один из действенных способов сделать изучение родного языка не только обучающим, но и развивающим и интересным.

Исторический комментарий поможет учащимся сознательно усваивать учебный материал и покажет им, что современные нормы языка являются результатом длительного процесса его развития и совершенствования, что язык — это не застывшая система, а исторически развивающееся явление.

С этой целью учитель должен методически правильно отбирать материал для исторического комментирования, привлекать только такие исторические сведения, которые освещают процесс развития языка, объясняют внутреннюю логику и обусловленность существующих теперь лексических, грамматических и орфографических явлений. Например, при изучении графики учитель может предложить детям удивительные факты из истории языка:

- Самый первый алфавит-финикийский - состоял из 22 букв для согласных звуков. В этом алфавите не было букв для гласных звуков;

- Классический греческий алфавит состоял из 24 букв: 7 гласных и 17 согласных;

- Древние финикияне писали не слева направо, как пишем мы, а справа налево;

- Греки пользовались системой под названием бустрофедон-это такая система, когда писец ведет строчки, как быка по борозде - туда и обратно, туда и обратно;

- Китайцы до сих пор пишут сверху вниз, вертикальными строчками, и располагают все эти строчки по странице справа налево;

- Египтяне сделали ещё одно великое изобретение: они придумали, как изготовлять удобный, гладкий и эластичный материал, на котором легко можно писать – папирус.

- Писали в древней Руси книги и грамоты чернилами. Кроме чернил, пользовались иногда киноварью (слово греческое) — красной краской из ртути и серы. Она обыкновенно употреблялась для заглавий, начальных букв, заставок и пр., главным образом как элемент украшения рукописи. Отсюда выражение *красная строка,* отсюда и слово *рубрика* (от латинского ruber — красный) в смысле „отдел", „глава", „абзац";

- Не все знают, что «тетрадь» слово не русское, а греческое и значит по-русски «четверка»: кожаный лист складывали вдвое, и из нескольких таких листов составляли тетрадь;

- Кириллица была составлена на основе греческого (византийского) торжественного унциального письма. Часть букв создана специально для передачи тех звуков славянского языка, которых не было в греческом языке, а значит, и в алфавите. Это буквы: Б, Ж, Ц, Ч, Ш, У, Ю, Я.

Таких примеров в истории графики предостаточно. Интересен тот факт, что те буквы, которыми пользуются языки, удивительным образом похожи:

ABCDEFGHIJKLMNOPQRSTUVWYZ - А Б В Г Д Е Ж З И Й К Л М Н О П Р С Т У Ф Х Ч Ш Щ Ъ Ы Ь Э Ю Я. Только интересуйся, сравнивай, изучай!

Да, прав великий Аристотель: познание начинается, действительно, с удивления. А удивительное - рядом.

СПИСОК ЛИТЕРАТУРЫ

1.Утевская, П. Слов драгоценные клады / П. Утевская. – Москва, 1982.

**Назад**

## Туфан Миннуллин иҗатында халыклар дуслыгы мәсьәләсе

*Галимова Фәйрүзә Аксан кызы,*
*Түбән Кама педагогия көллиятенең*
*татар теле һәм әдәбияты укытучысы*

Теманы телгә алубелән: “Торсак та без төрле җирләрдә,

Без яшибез Совет илендә.

Сөйләшәбез төрле телләрдә,

Аңлашабыз дуслык телендә”,

- дип җырлап үскән балачак, яшьлек еллары искә төшә. Бик тансык, күптән көтелгән һәм әһәмиятле тема бу. Күзәтүләрдән һәм җиңелчә тикшеренүләрдән чыгып, түбәндәге фикерне әйтергә мөмкин: соңгы егерме-утыз ел эчендә әдәбият фәне өлкәсендә бу теманы уртага салып сөйләшү, фәнни югарылыкта тикшерү, ачу, бәяләү кебек чаралар үткәрелмәде. Яшәешебездә кешеләр, халыклар, дәүләтләр арасында мөһим рольне алып торган дуслык, бердәмлек мөнәсәбәтләренең сыйфаты ничектер читтәрәк калып килде. Булган әсәрләрдәге дуслыкны чагылдырган күренешләргә дә игътибар бирелмәде диярлек. Ниһаять, Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миннеханов 2021 елны “Туган тел һәм халыклар бердәмлеге елы” дип игълан итте һәм шушы нисбәттән төрле чаралар уздыру нур өстенә нур булып тора.

Үткәнне белми, киләчәккә барып булмый. Ни генә дисәләр дә, бик күп хаталар, корбаннар, югалтулар аша үтеп таркалган СССР дәүләтендә халыклар арасында интернациональ дуслык хөкем сөрә иде. Моның өчен мәдәният, сәнгать, мәгариф һәм башка өлкәләрдә зур эшләр башкарылды, үз чорында да, хәзер дә зур бәхәсләр тудырган милли сәясәт үз куйган максатларына берсүзсез иреште. Бу сәясәт нигезендә, күпсанлы милләтләрдән бер совет халкы ясарга тырышу нәтиҗәсендә вак милләтләрнең ассимиляцияләшүен, туган тел, гореф-гадәтләре онытыла баруын искә алмаганда, халыклар дус-тату яшәделәр.

Бер халык та үзе генә, ялгыз, бернинди башка милләтләр белән аралашмыйча, төрле багланышлар кормыйча, изоляциядә яши алмый. Бу мөмкин дә түгел. Татар халкы да элек-электән чуваш, мари, гарәп, фарсы, Урта Азия, төрек, рус һәм башка халыклар белән бик тыгыз бәйләнешләрдә гомер кичергән. Хәсән Туфанның: “Миндә бардыр монгол һәм фин каны, Синдә, бәлки, - гарәп, һинд каны. Безнең бабайлар да хан кулында Айкаган бит шактый дөньяны” (“Ташкент баглары”), Кемдер әйткән, имеш: “Кайсы гына русны әйбәтләп кыргычлап юма, татарга барып чыгасың...”, - дигән сүзләре дә шул хакта сөйли. Халкыбыз “Бердәмлектә көч”, “Күршең үзеңнән

яхшы булсын”, “Күрше хакы – Алла хакы”, дигән мәкальләр нигезендә үзе белән бергә гомер иткән һәм янәшә халыклар белән тату яшәгән һәм яши.

Мәдәниятнең бер төре булган татар әдәбиятында милләтара дуслык темасы һәрвакыт иркен яктыртылды. Халкыбызның башка милләтләр, бигрәк тә рус милләте белән дуслык темасы татар әдәбияты тарихы битләрендә XIX гасыр азагында XX гасыр башында күренә. Бу К. Насыйри, З. Бигиев, Г.Тукай иҗатлары белән бәйле.

“Рус җирендә без әсәрле, эзле без,
Тарихында бер дә тапсыз көзге без.
Рус белән тормыш кичердек сайрашып,
Тел, лөгать, гадәт вә әхлак алмашып”, -

дигән сүзләре моны раслый. Бөек шагыйребезнең “Тел, лөгать, гадәт вә әхлак алмашып” фикере Ф.Әмирханның “Хәят”, Г.Ибраһимовның “Казакъ кызы”, һ.Такташның “Иптәшләр”,Ф.Кәримнең “Аникин”, “Разветчик язмалары”, Г. Әпсәләмов “Ак төннәр”, “Газинур”, С. Хәкимнең “Дуслык турында поэма”, Г Бәшировның “Туган ягым – яшел бишек”, Ә. Ерикәйнең “Дуслык турында җыр” һәм башка әсәрләрдә исбатлана. Теманы бераз тарайтып, Туфан Миннуллинның өч әсәре нигезендә милләтләр арасында дуслык мөнәсәбәтләренең үзенчәлеген билгеләп карыйк. Халыклар буталган, катнашкан заманда Туфан Миннуллин бу мәсьәләне ничек чишә? Бердәм яшәү өчен нинди үрнәкләр тәкъдим итә? Дус һәм бердәм яшәүнең серләрен нидә күрә? Нинди киңәшләр бирә? Сорауларга җавапны драматургның әсәрләреннән эзлик.

XX гасырның 60 нчы елларыннаналып XXI гасыр башы татар әдәбиятын, бигрәк тә сәхнә сәнгатен язучы-драматург Туфан Миңнуллин иҗатыннан башка күз алдына да китереп булмый. Татар әдәбиятында яхшылык һәм явызлык, мәхәббәт һәм нәфрәт, бөеклек һәм түбәнлек, яшәү һәм үлем турында бәхәс алып баручы, халкыбызның гаять каршылыклы тарихы, яшәешнең милли һәм гомумкешелек кыйммәтләре, кешенең асылы һәм рухи иреге, яшәү

мәгънәсе кебек фәлсәфи, милли, әхлакый мәсьәләләрне үз иҗатының башыннан алып азагына кадәр кызыл җеп буларак яктыртучы әдип ул.

Хронологияне саклаган хәлдә, драматургның әдәби дөньяны шаулаткан “Әлдермештән Әлмәндәр” моңсу комедиясенә тукталыйк. Татар халкының рухи ныклыгын, тирән акылын, гүзәл гореф-гадәтләрен, намуслы яшәү рәвешләрен саклаган ил карты Әлмәндәр белән Евстигней дуслыгы – ике милләт арасындагы җылы мөнәсәбәтләрнең бер үрнәге. Әлмәндәр Евстигней дусты янына гомеренең азагында, үлем белән яшәү арасында калгач, Әҗәлдән качып килә. Нигә килә соң? Ул бит Әҗәлнең бу килүендә аны калдырмасын, качып кына кала алмаячагын белә. Билгеле, бакыйлыккы киткәнче саубуллашасы килә аның. Сәбәп күңелле булмаса да, алар яңадан очрашуларыны чын күңелдән сөенәләр, бер-берсен исән-сау күрүләренә, дөнья тыныч һәм матур булганга куаналар. Яшәү ямен, үзара татулык һәм дуслыкның җылылыгын, күңел көрлеген тасвирлауның чын сәнгатьле үрнәге бу. Бу ике милләт картын алтмыш елга нәрсә берләштергән соң? Әсәрдәге менә мондый юлларга игътибар итик: “... Хәтерлисеңме, безнең якка аклар килгәч. Бергәләп урманда кызылларга кушылып киткән идек. Исеңдәме колхоз төзегәндә мине үлемнән коткарып калганың, хәтерлисеңме сугыш вакытында...”, “Хәтерлисеңме, Ястәгнәй, синең Иваның белән минем Хәйретдиннең үле хәбәре беркөнне килде”. Алар икесе ике авылда яшәсәләр дә, бер болында печән чапканнар, шук яшьлек чорларын бергә үткәргәннәр. “Күршеләр, знакумнар. Хәтерлисеңме, болынга печән чабарга чыккач, җыелышып биегәндә сезнең авылның Маручкасын кочаклаган идем, шуннан минем Йөзембикә азгын дип мине әрләгән иде”. Күргәнебезчә, аларны уртак теләкләр, якты, тыныч тормышка омтылыш, илебездә булган сугышлар, уртак кайгы-хәсрәтләр, югалтулар, хезмәт, яшьлек “юләрлекләре” берләштерә. Еллар үтү белән дә бу дуслык хисләре кимемәгән, ә мәгънә ягыннан баеган. Шуңа күрә дә Әлмәндәр карт соңгы сәгатьләрендә дә, дустын исендә тотып, аның белән хушлашуны үзенең бурычы дип саный. Евстигней дә Әлмәндәрне соңгы юлга озатып кала.

Тагы бер детальгә - Әлмәндәр һәм Евстигнейның сөйләшүләренә игътибар итик. Әлмәндәр, бар белгәненфайдаланып, русча сөйләшергә, ә Евстигней, тырышып-тырмашып, татарча аңлашырга омтыла. Җырлауларына гына карагыз аларның. Әлмәндәр рус җырының сүзләрен генә дөрес әйтми түгел, ә бәлки мәгънәсен аңламый да кебек. Евстигней дә аннан ерак китмәгән, ләкин бу уртак җырлар аларны мәңгегә берләштергән. Алар тел, сүз белән түгел, ә йөрәк белән аралашалар төсле. Бер карасаң, бу – ике карт арасындагы ихлас дуслыкны чагылдыру өчен файдаланылган шартлы алым булып тоелырга мөмкин. Әмма диалог ифрат дәрәҗәдә тормышчан һәм табигый – табигать кочагында, фидакарь хезмәт һәм татулык белән яшәгән төрле милләт вәкилләре арасындагы ихласлыкны түкми-чәчми күз алдына китерә дә бастыра. Бер-береңнең телен белү, белергә тырышу – халыкны хөрмәт итү билгесе. Хөрмәт булган җирдә дуслык та була. Драматург бит ярымлык өзектә рус һәм татар халкы арасындагы ихлас дуслыкның, интернациональ бердәмлекнең чын мәгънәсендәге сәнгатьле үрнәген күрсәтүгә ирешә.

Туфан Миннуллинның “Әниләр һәм бәбиләр” драмасында өч хатынны: татар милләтеннән Гөлфинәне, рус милләтеннән Валентинаны, казах милләтеннән Алтынчәчне бала тудыру йортының бер палатасында очраштыру тикмәгә түгелдер. Табигать хатын-кызга бик зур изге бурыч – бала табып, үзенең нәселен дәвам итү бурычын йөкләгән. Унике бала анасы Гөлфинә, җиде ел буе бала көтеп, ниһаять, үз теләгенә ирешкән Валентина, яшьлегендә яраткан кешесен табып, гаилә кору бәхетенә ирешә алмаса да, ана булырга омтылган Алтынчәчләрнең ана вазифасына мөнәсәбәтләре ачыла әсәрдә.

Бу өч хатын-кызның бер-берсенә булган мөнәсәтләренә игътибар итик. Аралашу, дуслыкның башы шул ук тел белүгә барып тоташа. Гөлфинәне Алтынчәч белән бер казахча сүз - “айналаем” берләштерсә, Валентинаны исем матурлыгы якынлаштыра. Гөлфинәнең: “Һәр халыкның үз теле шул. Шуңа күрә әйбәт тә. Бөтенесе дә матур. Валентина, милый мой дорогой. Кара нинди матур сүзләр. Валентина җаным дисәң дә бик рәхәт”, - дигән репликасы һәр өч халыкта балага иркәләү сүзләре әйтүләрен ачыклау белән дәвам иттерелә.

**Валентина**. Ә балаларга сездә ничек иркәләп дәшәләр, Алтынчәч?

**Алтынчәч**. Колынчагым... Чырагым... Балапаным... Кымбатым...

**Гөлфинә**. И-и-и, кара ничаклы матур сүзләр...

**Валентина**. Ә бездә соколик ты мой, золотце мое, солнышко мое, сынуля, дочурка, лапочка, ненаглядный, ненаглядная...

**Гөлфинә.** Бигрәк тә күп инде матур сүзләр. Матур сүзләрне яратам шул мин. Бәгырь кисәгем, багалмам, йөрәк маем, матурым, тәтием, күземнең карасы, алтыным, көмешем, сандугачым, карлыгачым, гөлкәем...". Кешеләр нинди генә милләттән булсалар да, бала тәрбиясенең нигезләре бертөрле булуы балага булган мәхәббәт хисләре назлы, иркәләү сүзләрендә дә ачык сизелә. Аналар бер-берсеннән бишек җырлары өйрәнергә дә, сыйлау сүзләрен төрле телләрдә әйтергә дә, хәтта сөйдергеч догалар өйрәнергә дә атлыгып торалар. бер-берсен якларга да сакларга да әзерләр алар. Бу – телне, гореф-гадәтләрне хөрмәт итү нигезендә туган дуслык, бердәмлек үрнәге түгелмени? Ә бит аларны бер теләк – ана булу, балаларына яхшы тәрбия бирү, гаилә бөтенлеге берләштерә.

Т.Миңнуллинның үзгәртеп корулар чорындагы иң көчле әсәрләреннән берсебулган "Илгизәр+Вера" пьесасына тукталыйк. Монда бит катнаш никахлар турында сүз бара диярсез. Әйе, нәкъ шулай. Элек-электән үк барлык милләтләр дә катнаш никах мәсьәләсенә үтә дә сак булганнар. Бу фикернең дөреслеге пьесада ачык дәлилләнә. Мәсәлән, олы буын кешеләре – урыс милләтеннән булган Алексей да, татар милләтеннән булган Нурхәмәт тәВера белән Илгизәрнең бергә гаилә корырга җыенуларын курку катыш ышанычсызлык белән көтәләр. Бу авылда өч йөз ел буена татар һәм рус милләте бик дус гомер иткән. Бергә эшләгәннәр, күңел ачканнар, кыз-егетләре аулакта бер-беренә мәхәббәт сүзләре пышылдашканнар. Ләкин эш шуннан ары узмаган. Чөнки катнаш гаилә коруның һәр ике милләт өчен дә куркыныч хәлләргә китерү мөмкинлеген төшенеп яшәгәннәр борынгылар. Әсәрдә башлап, кызы Вераның күрше егете Илгизәргә кияүгә чыгу яңалыгын белгәч, Алексей зур хөрмәт белән баш иеп, Нурхәмәтләргә керә. Гасырлар буе дәвам

иткән дуслыкны бозарга теләмичә, сүзләрне сайлап кына, зур сабырлык белән бик ерактан башлый: “... Безнең халыкны монда Петр Беренче заманында көчләп күчереп утыртканнар. Бабайның әйтеп калдырганыча, Воронеж якларыннан булырга тиеш без. Кайсыбер татар авылларыннан татарларны бөтенләй куып җибәреп, безнең кебекләрне урнаштырганнар. Авыл исемнәре татарча калган. ...”, “Сезнең авылга ни өчендер тимәгәннәр. Сезнең яннан безгә җир бүлеп биргәннәр. ... Башта сакланыбрак яшәгәннәр. Сезнекеләр үзләренчә, безнекеләр үзләренчә. Бара-тора инде, үзең беләсең. ... Күз тимәсен, бер авыл, бер ил булып яшибез. Өч йөз елга якын бергә яшәп, бер генә тапкыр да сугышып урамга чыкмаганбыз. Сез безнең телне беләсез, без сезнең телне өйрәндек. Безнең бабайлар сезнең бәйрәмнәргә, сезнең бабайлар безнең бәйрәмнәргә йөргән. Безнең туйларда сез табын уртасында, сезнең туйларда без кадерле кунак”, - ди ул. Аның: “Сезнең җирегездә сезнең белән талашып яшисем килми минем”,- дигән сүзләре дә әһәмияткә лаек. Бер-берсенең телен өйрәнгәннәр, бәйрәмнәр дә уртак, туйда күңел ачканда ике халык җырларын бергәләп башкаралар, «Әпипә»не җиңел генә «Барыня-сударыня» алыштыра. Нигә өйләнмәскә? Яшьләр яшьлекләре аркасында өйләнешәләр. Моңа Илгизәрнең әнисе Даниянең да үз милләтенә “төкереп каравы” сәбәпче, билгеле. Ә бит шул ук Алексей: “Татарның татарлыгына син төкерсәң бер хәл, Дания. Менә мин төкерсәм, бик яман. Русның руслыгына син төкерсәң дә начар”, – дигән сүзләре бик гыйбрәтле. Әйе, өйләнешәләр дә – аерылышалар да. Сәбәп нәрсәдә соң? Илгизәр һәм Верага кадәр өч-дүрт буын татар, рус бабайлар аларга матур үрнәк калдырмаганмы? Илгизәрнең этисе Хәлиулла да, Вераның эти-әнисе Алексей һәм Наталья да ике күрше – ике халык арасындагы дуслык мөнәсәбәтләрен сакларга бар көчләрен куялар. Мария әби белән Нурхәмәт бабай да исән бит әле. Аларның бабалары утырткан дуслык өянкесе дә аварлык түгел.Ә гаилә таркала. Ике милләт арасыннан кара мәче уза. Моннан соң өянке белән генә аерылып торган ике халык ничек яшәр? Даниянең соңгы сүзләреннән, кыланышларыннан соң элекке бердәмлексакланырмы? “Татарның татарлыгына ...,Русның руслыгына төкерү”

түгелме соң бу?! Сәбәп нәрсәдә? Сәбәп – Илгизәр белән Верада әти-әнигә, әби-бабайга хөрмәт булмауда. Татар һәм рус халкының милли үзенчәлекләрен, дини аерымлыкларын санга сукмауда. Әдәп, әхлак кануннарының сакланмавында. Буыннар арасындагы бәйләнешләрнең өзелүендә.Һәм иң мөһиме: һәр милләт вәкиленең үз милли билгеләнүенә салкын карвында, халкың белән горурлану, аны сакларга теләү хисләренең сыеклыгында. Үзен хөрмәт иткән халыкны гына хөрмәтлиләр шул. Алексейның мондый сүзләре бар: “Безнең бабайлар безнең патшалардан акыллырак булганнар. Сез үз җирегездә рәнҗетелгән, без үз җиребездән куылган — нигә сугышырга? Язмышлар бер.”, “Безнең бабайлар бер-берсен хөрмәт итә белгәннәр. Сугыш чыгарырлык эш эшләмәгәннәр. Безнең тел бөек тел, сезнең тел бәләкәй дип, ахмак сүз сөйләмәгәннәр”.

Туфан Миннуллинның өч драмасына күзәтү ясау түбәндәге нәтиҗәләр ясарга этәрде.

1. Автор халыклар арасындагы бердәмлекне тарих, тарихи вакыйгалар (сугышлар, колхозлашу һ.б), алар белән бәйләнешле язмышлар, кичерешләр, телек-омтылышлар белән бәйләп аңлата (“Әлдермештән Әлмәндәр”, “Илгизәр+Вера”).

2. Дуслыкның фидакярь хезмәттә чыныгуын, сыналуын; халык бәйрәмнәрендә ачылуын күрсәтә.

3. Халыклар арасындагы дуслыкның нигезен гаилә ныклыгында, һәр милләтнең бала тәрбияләүдәге кыйммәтләренең уртаклыгында күрә (“Әниләр һәм бәбиләр”- унай үрнәк, “Илгизәр+Вера” – ике гаиләдә дә кире үрнәк).

4. Һәр халыкның үз һәм башка халыкларның милли теленә, хореф-гадәтләренә, дини үзенчәлекләренә хөрмәт булганда гына бердәмлекнең сакланачыгын ассызыклый (“Әлдермештән Әлмәндәр”, “Әниләр һәм бәбиләр”,“Илгизәр+Вера”).

5. Әлмәндәр һәм Евстигней, Гөлфинә, Валентина һәм Алтынчәч, Алексей, Мария, Нурхәмәт кебек персонажлар аша милләтләр арасындагы дуслыкның сәнгати үрнәген тәкъдим итә.

Татарстан – күпмиллэтле республика, башка җөмһүриятләр өчен дуслык, татулык, бердәмлек үрнәге. Аның шулай булуында Т. Миннуллин кебек олпат әдипләребезнең дә роле зур.

КУЛЛАНЫЛГАН ӘДӘБИЯТ ИСЕМЛЕГЕ


1. Миннуллин, Т. Сайланма әсәрләр, 10 томда / Т. Миннуллин, - Казан: тат. кит. нәшер., 1, 2, 3 томнар., 2002.

2. http://adiplar.belem.ru/minnullin_tufan1.htm

3. https://nsportal.ru/ap/library/literaturnoe-tvorchestvo/2012/09/22/tufan-minnullin-izhatynda-millt-yazmyshy


**Назад**

## Нурзия Мирхазованың «Үтәлмәгән вәгъдә» әсәрендә сәнгатьчә бизәү чарасы буларак мәкальләр

*Галәветдинова Люция Рәхимҗан кызы,*
*Түбән Кама педагогия көллиятенең*
*татар теле укытучысы*

«...ә менә сүздә хикмәт, акыл, тапкырлык ишетергә теләсәң, мәкаль һәм әйтемнәр укы, аларның тарихын бел», – ди бөек галим, фольклорчы, тәрҗемәче, драматург Нәкый ага Исәнбәт.

Мәкаль һәм әйтемнәрнең туу, барлыкка килү һәм үсүенә ярдәм итүче чыганаклар – экият, мәзәк, сөйләмнәрдә әйтелгән тирән мәгънәле фикерләр, язма әдәбият. Аерым язучылар, галимнәр тарафыннан әйтелгән уңышлы афоризмнар һәм «канатлы сүзләр» дә халык теленә кереп китеп, еш кына үзгәртелүләргә очрап, халык мәкале һәм әйтеменә әвереләләр.

Нәкый ага Исәнбәт биргән билгеләмәдә ул түбәндәгечә яңгырый: «Сөйләшкәндә сүзгә ямь һәм куәт бирү өчен көнкүрештә күп сыналган тәҗрибә һәм дәлил яки дә шигъри бер мисал урынында әйтеп йөртелә торган кыска, ләкин гомуми бер тирән мәгънәне эченә алган төгәл җөмләле халык хикмәте әсәрләре мәкаль дип әйтелә» [1].

Мәкальнең «сүзгә ямь һәм куәт бирү өчен» диелүенә игътибар итик. Димәк, мәкальнең ике вазифасы бар: берсе – сүзгә ямь бирә, икенчесе – куәт

бирә. Ямь булгач, ул, димәк, сүзне матурлау әйбере була, куәт булгач, димәк, анда, кешене сүзгә ышандырырлык көч тә була.

Мәкальләрдә ана телебезнең матурлыгы һәм камиллеге, төгәллеге һәм байлыгы гәүдәләнә. Халык үзе болай ди: «Әйтем – сүзнең бизәге, ә мәкаль – сүзнең җиләге».

Мәкальләр кешенең фикерләү сәләтен үстерә, акылын, тапкырлыгын тирәнәйтә, телгә мәхәббәт тәрбияли.

Мәкальләрдә халыкның әхлакый идеаллары, хезмәт сөючәнлеге, өлкәннәргә ихтирам, әдәплелек, дуслык, туган илгә булган чиксез мәхәббәте, дөреслек, сафлык кебек сыйфатлары чагылыш таба [2].

Мәкальне куллануның төп максаты – нинди дә булса бер хәбәр, информация бирү түгел, бәлки сөйләмне сәнгатьлерәк итү.

Халыкның гасырдан-гасырга күчә барган тормыш тәҗрибәсе, акыллы фикерләре, зирәклеге, кыска, әмма төгәл формалы халык авыз иҗаты әсәрләрендә – мәкальләрдә ачык чагылыш таба, чөнки «мәкаль күп заманнар буе кулланылышта булып, нык шомартылган асыл таш шикелле эшкәртелгән, чарланган хөкем яки фикердән гыйбарәт».

Мәкальләрдә төп максат – фикер әйтү. Тирән мәгънәле фикерне башкаларга аңлаешлы итеп җиткерү өчен мәкальләрне төзегәндә, халык төрле поэтик чаралардан файдалана. Аларда әдәби алымнар буларак чагыштыру, читләтеп әйтү, охшатулар еш очрый, рифма һәм ритм бик оста кулланыла.

Билгеле булганча, мәкальләрнең төп идея-максаты кешеләргә, бигрәк тә яшьләргә әхлак һәм әдәп тәрбиясе бирүгә багышланган. Татар халык мәкальләрендә яшь буынны тәрбияләү буенча үзенчәлекле милли яклар белән бергә кешелек өчен характерлы булган гомум фикерләр дә чагыла.

Язучыларыбыз әсәрләрендә халыкчанлыкка, миллилеккә, тел байлыгына, образлылыкка ирешүдә фольклор казанышларын киң файдалана. Матур әдәбият һәм фольклор гомер-гомергә бер-берсе белән җитәкләшеп, үзара керешеп яшәгәннәр һәм яшиләр. Бу ике арадагы бәйләнеш әдәби әсәр теленең матурлануына, баюына һәм камилләшүенә һәрьяклап ярдәм итә [3].

Матур әдәбият теле–образлы тел. Анда сурәтләү чаралары аша һәр язучының сөйләм үзенчәлеге күренә. Автор кулланган чаралар, алымнар җыелмасы язучының дөньяга карашын, иҗат ысулының юнәлешен дә билгели. Язучы сүзләрне, сурәтләү чараларын, шул исәптән мәкальләрне дә билгеле бер максат белән сайлап ала, урнаштыра [4]. Һәрбер язучы әдәби әсәр иҗат иткәндә үзенең стилен билгели, тел материалларын куллануда үз алымын булдыра.

Үз вакытында Түбән Кама педагогия училищесын, соңрак Яр Чаллы педагогия институтын тәмамлап, гомерен мәктәпкәчә яшьтәге балаларны тәрбияләүгә багышлаган якташ язучыбыз Нурзия Рашит кызы Мирхазова да үзенең «Үтәлмәгән вәгъдә» әсәрендә халык авыз иҗаты үрнәкләренең иң тапкыр үрнәге – мәкальләрдән оста файдалана. Беренче эш көнендә үк, Ризаэддин Фәхреддиннең «Ата вә анагызны, якын кардәшләрегезне ничек сөйсәгез, милләтегезне дә шулай сөегез, милләтегез өчен хезмәт итүне җаныгызга бәхет дип белегез», – дигән сүзләрен тормыш девизы итеп сайлаган ханым, милләткә хезмәт итүне тәрбияче буларак генә түгел, ә әсәрләрендә дә үзенә бик якын булган тәрбия темасын яктырту белән дәлилли. Мәкальләр аша ул әсәрнең телен халык сөйләменә якынайту, образлылыгын көчәйтүгә ирешә алган.

«Үтәлмәгән вәгъдә» әсәрендә Нурзия Мирхазова үз халкыңның гасырлар дәвамында сыналган йолаларын, гореф-гадәтләрен санга сукмавы аркасында, адәм баласының төрле фаҗигале хәлләргә дучар булуын тасвирлый.

Әнисе авырып, урын өстенә егылгач, Сәвия, көннең кичкә авышуына да карамыйча, әнисе янына ашыкты: «Әнием, күз нуры, берүк риза-бәхиллегеңне бирә күр... Йә, Ходам, әниемне исән килеш күрмәсәм...». Колагында һаман да әнисенең сүзләре чыңлады: «Чит кавемгә дип үстермәдем... Әгәр аңа кияүгә чыксаң, анаң барлыгын оныт!». Ләкин гашыйк Сәвиягә бу кисәтү-каргыш ошамады, ул үзенчә эшләде: күрше авылдагы чибәр генә урыс егетенә кияүгә чыкты. Ә әнисе, рәнҗүдән, аны кичерә алмый газапланды. Шулай язгандыр инде, ни хәл итмәк кирәк ... «*Узган эшкә – салават*». Әнисенең хәлен белергә

килгән авылдашларының салкын карашларыннан өстенә бозлы су, нәфрәт агыла сыман тоелды аңа. Яшь хатын барын да аңлый, тик «*үпкәне – ачу, утны май белән баса алмыйсың шул*». Абыйсы Салих белән җиңгәсе әниләрен карарга кайткач, Сәвия тулысынча аларга ышанды. Ә Салих исә, туганына ярдәм итү нияте белән хәтта күрәзәче, дога белән дәвалаучыга барырга да мәҗбүр була «*Башыңа төшсә, түмгәккә дә сәлам бирерсең...*».

«*Бәхетсезгә, эремчек ашаса да, кылчык эләгә*», ди, эшкә дип киткән ире Иван юл һәлакәтендә вафат булгач, язмышның ачы сынауларына дучар булган Сәвиягә туган абыйсы Салих «*Дөнья булгач, була инде, сеңлем, уты да, төтене дә*», дип юатырга тырышып, ярдәм кулын суза: «*Туган бар җирдә – ярдәм бар*!».

Язмышның «*Ялгыша белгәч – төзәтә дә бел*», дигән искәртүенә карамастан, Сәвия ялгышын тагын кабатлый: Иванның соңгы истәлеге булган, туарга да өлгермәгән баласын югалту ачысын бераз җиңеләйтергә булышкан Николай белән язмышын бәйли. Ләкин Николайның әнисе Сәвияне кабул итми, аларның борын төбендә ишекне дөңгердәтеп ябып куя. «*Кунак ишегеңне ачса, син йөзеңне ач*», – дигән тәгъбир белән тәрбияләнгән Сәвиягә бик тә авыр була, әлбәттә: «*Бер баткан сазлыкка кабат кермиләр бит!*».

Николай белән «мама» сының хәер-фатихасыннан башка булса да, ярыйсы гына яшәп китәләр, ләкин, еллар үткән саен, гаиләдә, мәхәббәттән тыш, башка чишелмәслек мәсьәләләр барлыкка килә. «*Болыт купса – яңгыр китәр, сүз курса – тавыш китәр*», дигәндәй, дини, йола бәйрәмнәре ызгыш-талаш белән тәмамлана торган булды... Борынгыларның *«Өлешеңә тигән көмешең», «Ирне ир иткән дә – хатын, юк иткән дә – хатын»* дигән сүзләренә күңел юатып яшәрә тырышса да, Сәвия яңадан бик җитди бәлага дучар була. Умырткасын имгәтү бәхетсезлеге ир белән хатынны бик озакка аерды: «*Иртә уңмаган – кич уңмас, кич уңмаган – һич уңмас*».

Мәкальләр арасында кешенең характер үзенчәлегенә, аның эчке дөньясына, рухи халәтенә, әдәп-әхлагына кагылышлылары да шактый урын алып тора. Мисалга, әсәрдә әле Сәвия мәктәптә укыганда ук, гәрчә ул аны

яшерен, беркемгә дә белгертми генә яратып йөргән булса да, яңа гына армия сафларыннан кайткан Илгизнең аңа карап җырлавын сизгәч, бит алмалары кызышты, башы түбән иелде: *«Эш күлмәк белән сәдәптә түгел шул, оят белән әдәптә»*. Егетнең үзен озата килгәч тә, ни өчен армиягә озатып калган Нәсимә янына бармавын сорагач, Илгизнең җавабы кыска булды: *«Дәлиле азның – сүзе озын...», «Өлгергән өрек сабагында тормый шул», - дип,* кызның вәгъдәсендәтормавын аңлатты.

Билгеле булганча, мәкальләрнең төп идея-максаты кешеләргә, бигрәк тә яшьләргә әхлак һәм әдәп тәрбиясе бирүгә багышланган. Нурзия Мирхазова, гомерен балалар тәрбияләүгә багышлаган язучы буларак, әсәрләрендә уку-гыйлем, белем алу турындагы мәкальләргә дә игътибар итә. *«Бер баскан тырмага кабат-кабат басса да»,* Сәвия, әнисенең ярдәме белән, кызы Газимәне әдәпле, инсафлы чын татар кызы итеп тәрбияли алды, укытты, кеше итте. Укытучылыкка укыганда, Газимә игътибарын бары тик укуына гына багышлады. *«Тән рәхәте – сәламәтлек, җан рәхәте – гыйлемле булу»*ны яхшы аңлады ул. Кызыл диплом алып кайтып, әбисе белән әнисен шатландыргач, «Белем – бәхет ачкычы, дәрәҗәнең баскычы», – диде әбисе, оныгының булганлыгына куанып.

Димәк, мәкальләрдә халыкның әдәп-әхлак кануннары, эш сөючәнлеге, өлкәннәргә мөнәсәбәте, дуслык, дөреслек, сафлык, белемгә омтылышы кебек сыйфатлары чагылыш таба. Мәкаль-әйтемнәрнең яшь буынны, гомумән халыкны, әхлакый тәрбияләүдә роле аеруча зур. Алар әсәрнең эмоциональ көчен арттыру өчен, телен сәнгатьчә бизәү, фәлсәфи-дидактик хөкем чыгару, киңәш-нәсыйхәт бирү, әсәрнең эчтәлеген ачар өчен, чорның тормыш-көнкүрешен, халыкның көндәлек тормышын, рухи-әхлакый сыйфатларын, дөньяга карашларын ачык итеп күз алдына китерүдә искиткеч әһәмиятле роль уйныйлар [5].

КУЛЛАНЫЛГАН ӘДӘБИЯТ

1. Исәнбәт Н. Татар халык мәкальләре. Кереш сүз һәм аңлатмалары белән 3 томда. I т. / Н Исәнбәт. – Казан: Татар.кит.нәшр., 1959. – 913 б.

2. http://smi.kazanobr.ru/4/901.php

3. https://botana.biz/prepod/klassnomu_rukovoditelyu/om1kduga.html

4. https://infourok.ru/vahit-imamov-srlrend-tel-surtl-charalari-458214.html

5.https://nsportal.ru/shkola/rodnoy-yazyk-i-literatura/library/2016/01/17/g-bshirovnyn-tugan-yagym-yashel-bishek-srend

6. Нурзия Мирхазова. Уяну. Повесть, хикәяләр, педагогик-публицистик язмалар һәм драматик әсәр. – Казан: «Ихлас» нәшрияты. – 2015. – 176 б.

**Назад**

## Галимҗан Ибраһимовның “Казакъ кызы” романындагы экзотизмнарның лексик-семантик катламнары

*Гыйлаҗетдинова Г.М., ДАҺБУ “Муса Җәлил исемендәге Минзәлә педагогия колледжының татар теле һәм әдәбияты укытучысы*

Хәзерге татар әдәби теленең экспрессив-стилистик катламына стилистик яктан чикләнгән, билгеле бер кулланылышка карый торган, нигездә язма сөйләмгә хас сүзләр керә. Китап теле сүзләре, көнкүреш сөйләменнән аермалы буларак, нормага салынган әдәби сөйләмдә, публицистик, фәнни сөйләмдә, эш кәгазьләрендә, рәсми стильдә һәм матур әдәбият телендә кулланылалар. Сөйләмдә кулланылган тәкъдирдә дә, бу сүзләр китапчалык бизәген югалтмыйлар. Шуларның бер төркеме – экзотизмнар. Минем фәнни мәкаләмнең темасы – Галимҗан Ибраһимовның “Казакъ кызы” романындагы экзотизмнарның лексик-семантик катламнары.Хезмәтемнең максаты – Галимҗан Ибраһимовның “Казакъ кызы” романында кулланылган экзотизмнарны лексик-семантик катламнарга аерып, төркемнәргә туплау.

**Бурычларым:**

1. Галимҗан Ибраһимовның “Казакъ кызы” романындагы экзотизмнар буларак карала торган лексик берәмлекләрне туплау.
2. Шушы берәмлекләрне лексик-семантик катламнарга аеру.

Галимҗан Ибраһимов “Казакъ кызы” романында казах халкының үзенчәлекле милли сыйфатларын чагылдыручы бик күп сүзләрне куллана. Әсәрне уку барышында моңа кадәр татар тормышы, аңа хас булган вакыйга-күренешләр белән очрашып килгән ктиап укучы беренче тапкыр тугандаш казах халкының гореф-гадәтләре, тормыш-көнкүреше дөнясына кереп китә. Шуңа бәйле рәвештә үзенә бөтенләй таныш булмаган сүзләр белән очраша. Бу сүзләрне өч төркемгә аерып карарга мөмкин:

1. Татар телендә үз эквивалентлары булган казах теле сүзләре. Мәсәлән: *Карлыгач-Сылу бу кич кабул кыла алмый: карагым (сөеклем) үпкәләмәсен, бик каты наукасланып (авырып) калдым, ди. Яман телләр аның калымлыгы белән Карлыгач-Сылу белән белән Танабугаларның Арысланбай дигән бер егете арасында тамырлык (дуслык) барын сөйлиләр иде.* Мондый сүзләр варваризмнар дип атала. Варваризм дип, әдәби тел нормаларын боза торган чит тел сүзләре. Тик бу очракта автор аларны теге яки бу персонажның сөйләм теленә хас кимчелек итеп түгел, ә милли колоритны бирү максатында куллана. Боларга тагын мисал итеп, *арзу (теләк), ту бия (кысыр бия)* һ.б. китерергә мөмкин.
2. Атама белдергән күренеш, татар халкының тормыш-көнкүрешендә бөтенләй булмаса да, теге яки бу сәбәпләр белән алынма сыйфатында телгә килеп кергән сүзләр. Мәсәлән: *“Шунда укучының күз алдына көтү-көтү елкылар, нәсел төяләре, исәпсез куйлар килеп баса.”* Бу сүзләрдән *“төя” (дөя)* сүзе татар укучысы өчен алынма сүз, ә калганнары аңа яхшы таныш булган *“ат”,“сарык*” сүзләренең төрки вариантлары. Алар татар теленең аерым диалектларында да очрыйлар. Мондый гомумтөрки сүзләр югарыда күрсәтелгән төркемгә керәләр.
3. Татар тормышы һәм татар теле өчен бөтенләй ят булган сүзләр. Мондый сүзләр тел белемендә экзотизмнар дип атала. Алар, башлыча,

матур әдәбият стилендә кулланылып, теге яки бу халыкның тормыш-көнкүрешен тулырак чагылдыру өчен хезмәт итәләр. Мәсәлән: *“Киң дала, күрәсең гуй, ана җаткан, Җебәктәй җәсел чүптә битен җапкан*” өзегендәге *гуй* сүзе Урта Азиядә яшәүче төркиләргә хас лексик берәмлек. Моннан тыш автор казах хатын-кызларының киемнәре, торак, ашау-эчү белән бәйле сүзләрне дә шактый еш куллана. Мәсәлән: *Туктының симезләре суелды, кымыз мул куелды, байбичә, кунакларның кадерен белеп, бик сирәк ашлардан булган <u>куырдак,</u> <u>көйгәнбөйрәк</u>* (аш төрләре) *кебек сыйлар хәзерләтте. Катык, әйрән, эремчек, <u>күҗә</u>* (бодайны киледә төеп ваклаганнан соң, казанда яки чуенда кайнатып пешерелгән сыек ботка*) белән төрле-төрле савытлар, зур-зур казаннар шунда ук урын алдылар.Өстендә буй-буй сырып тегелгән яңа <u>көпе</u>...* (сарык йонынннан сырып тегелгән бишмәт*). Шуның алдында гына <u>тукалның</u>* (яшь хатын, ирнең икенче, өченче яисә дүртенче хатыны*) ак <u>урамал</u>* (казах хатын-кызларының милли баш киеме) *сарган башы, казан астындагы утның ялкыны күренә.*

Галимҗан Ибраһимовның “Казакъ кызы” романындагы экзотизмнарны түбәндәге лексик-семантик төрләргә аерырга мөмкин:

1. Азык-төлек өлкәсенә караган сүзләр: *бөйрәк, күҗә, локма.*

2. Абстракт төшенчәләр: *арыз, мумын, наукаслану, тамырлык, чарчау.*

3. Иркәләү сүзләре: *карагым, сәүләм, чырагым.*

4. Кием-салым өлкәсенә караган сүзләр: *көпе, җөббә.*

5. Мал-туар, терлек өлкәсенә караган сүзләр: *асау айгыр, кара, ту бия, тукты, җот.*

6. Кешене атау өчен кулланыла торган сүзләр: *аял, кимпер, тукал, чичә.*

7. Кешенең эчке һәм тышкы сыйфатларын билгеләү өчен кулланыла торган сүзләр: *мыктый, әбдән, тәвер.*

8. Иҗтимагый-сәяси һәм дин өлкәсенә караган сүзләр: *аләүмәт, бата кыйлу.*

9. Этнонимнар: *танабуга, сарман, кара-айгыр, найман, кызылкорт һ.б.*

10. Топонимнар: *Алтын-Күл, Якты-Күл, Сары-Арка, Дүрткара һ.б.*

Әдәби әсәрләр уку барышында очраган сүзләрне безнең үз туган телебез сүзләре белән чагыштырып бару әсәргә карата тагын да зуррак кызыксыну уята. Шуңа күрә татар теле сүзлек хәзинәсенең экспрессив-стилистик катламнарының берсе булган экзотизмнарны өйрәнүгә күбрәк игътибар бирү кирәк. Татар теле фәнендә экзотизмнарның роле зур. Укучы матур әдәбият аркылы теге яки бу халыкның гореф-гадәтләре, көнкүреше белән генә танышып калмый, ә бу халыкның милли теле турында да азмы-күпме мәгълүмат ала. Экзотик лексика белән күбрәк очрашкан саен, укучының сүзлек байлыгы үсә, күзаллаулары һәм дөньяга карашлары формалаша.

Галимҗан Ибраһимовның “Казакъ кызы” романындагы экзотизмнарның роле нәкъ менә шунда дип уйлыйм.

Назад

## Ф. Латыйфиның «Хыянәт» романында татар халкының милли характер үзенчәлекләре

*Гыйльметдинова Илгизә Миркасыйм кызы*
*Зиязиева Раилә Шәрипҗан кызы*
*татар теле һәм әдәбияты укытучылары*
*Муниципаль бюджет гомуми белем учреждениесе*
*Татарстан Республикасы Минзәлә шәһәре*
*“1 нче санлы гомуми белем бирү мәктәбе”*

Без, үзебезнең эшебезне“2021 елны Туган телләр һәм халыклар бердәмлеге елы” белән бәйләп, үземнеңхалкыма булган ихтирамымны, горурлык хисен, халкымның милли характер үзенчәлекләренФ. Латыйфиның «Хыянәт» романы ашакүрсәтәсем килде. Якташ язучыларнын иҗаты күңелгә бик тә якын, чөнки мин үзем дәМөслим ягыннан. Татарстанга гына түгел,

хәтта башкамилләтләргә дә билгеле булган данлы якташларыбыз белән хаклы рәвештә горурланыбыз. Шулар арасында милләтебез язмышы, аның үткәнетурында уйланып, халкыбызның рухи дөньясын баетуда, матурлауда зур хезмәт куючы, әдәбиятыбызга намуслы хезмәт итүче әдипләребезнең берсе Ф.Латыйфи.

Ф. Латыйфиның 1989-1990 нчы елларда иҗат ителгән «Хыянәт» романы да татар әдәбиятының зур казанышы буларак кабул ителде.

Теманың актуальлеге шунда: «Хыянәт» романын тикшерү, бер яктан, аерым язучы иҗатында тарихи әсәр халыкның үсешен, милли характер үзенчәлеген, көнкүрешенкүзалларга мөмкинлек бирсә, икенчедән, Ф.Латыйфи кебек талантлы язучы хакында гомуми караш тудырырга, аның иҗади тәҗрибәсен күрергә ярдәм итә.

**Максат**итеп түбәндәге проблемалар тикшерелде:

- язучының тарихи фактлар нигезендәхалкынабулган ихтирамын,горурлык хисен,халкымныңмилли характер үзенчәлекләреначу;
- әсәрнең тарихироман буларак хасияте.

Ф.Латыйфи “Хыянәт” романындамилли каршылыыкка корылган сюжетҗебе сузып, милли чынбарлыкны аерыптергезүюлын таба, шунын ярдәмендәмилли фәлсәфә тәкъдим итәһәм милләткә бәя бирү мөмкинлегенкүрсәтә.

Шушы уңайдан милли характер тудыру язучының үз алдына куйган максатларның берсе булып тора. Мәмәт би һәм Шәһит, Гөлйөзем һәм Галиәкбәр агай, Нургали һәм балыкчы карт, Әҗем һәм Кол Шәриф – һәрберсе шушы максатка ирешү өченхезмәт итә, үзенчәлекле сыйфатлар белән бергә, уртак хасиятләргә ия.Төп сыйфатларны язучы текстта да аерып билгеләп бара. Геройларның тышкы кыяфәтендә, эш-гамәлләрендә беренчел куелган сыйфат-сабырлык.

Милли характерны формалаштыру казанышлар өчен тискәре саналган сыйфатларны формалаштыру казанлылар өчен тискәре саналган сыйфатларны барлау аркылыдәвам итеттелә: “Күңелеңдә хөсетлек, калебеңдә комсызлык,

саранлык юкмы, кулың кәкре түгелме, күзеңне нәфес пәрдәсе капламаганмы, йөрәгеңне май басмаганмы, эчке хасиятләрең тышкысына туры киләме?”. Шунда ук уңай сыйфатлар да ачыклана: аягың җитез, зиһенең йөгерек, кулың нык, сүзең акыллы, йортың, авызың биктә булсын!”. Тискәре сыйфатларны башка милләт вәкилләрендә төп комсызлык, Иван патшада һәм аның иярченнәрендә – нәфес һ.б. милли характерны да каршы китерә.

Вакыйгалар барышында геройларны батыр һәм тәвәккәл, чыдам һәм түзем итеп сурәтләгәнавторбу сыйфатны да төп герое Сәетавызыннанәйттерә: “кызларның түземлеген, чыдамлыгына хәйран калды Санька“. (“Хыянәт“, 1993. – Б.278 б). Тагын бер сыйфат - аерымбер күренешләрдә ныгытылып барган үзенчәлек – горурлык. Урыс гаскәрләренә тере калкан ителгән тоткыннарны автор түбәндәгечә сурәтли: алар горур иде. Аерым урыннарда казанлыларның холык-фигыле авторхикәяләүчеавызыннан да бәяләнеп барыла.

Милли логика, фикерләү үзенчәлеге дәшактый тулы һәм җентекле белдерелгән. Бу яктан, хикәяләүче - автор геройларның фикере кебеккитерелгән бәяләмәләр шулай ук әсәр тукымасынабиктабигый ялганып бара: казанлыларның кунак сыйларга, назланып, ялындырып кына сыйланырга яратуы мәгърибтә дә, мәшрикътә дәбилгеле анысы. “Казанлылартар күнелле түгел“. Бу халыкның башкаларга хөрмәт белән каравы игътибарга алына.

Автор үзенең карашларын татар халкындагы матур сыйфатларга рус кешеләренең соклануларын күрсәткән эпизодлар аша үткәрә. Саньканы татар кызы Гөлйөземнең“ эре – эре чәчәкле искиткеч матур яшел яулыгы “һуштан яздыра:” Юка , затлы ефәктән баш әйләндергеч хуш ис аңкый. Ул ис борынны кытыклый , сулыш юлларыннан җанның үзәгенә барып җитә , йөрәген еш-еш тибәргә мәҗбүр итә иде. (“Хыянәт“1993.-Б.62). Шулай итеп, тирәлек, интерьер, кием салым, казанлыларның көнкүрешендә очрый торган күпсанлы детальләр, холык – фигыль һәм дөньяга караш үзенчәлекләре аркылы Ф.Латыйфи татар милләтенең сурәтен,характерын тудыруга ирешә.

Нәтиҗә ясап әйтсәк, Ф. Латыйфи Казан ханлыгының дәүләтчелек билгеләрен сәнгатьчә тасвирлаганда тарихи фактлар белән иҗади уйланманы бәйли. Роман битләреннән ханлыкның гөрләп чәчәк атып утырган дәүләт булуы күз алдына килеп баса. Казан тарихы белән кызыксынучы укучы бу романнан күп бай мәгълүмат белә ала.

Әдип үзенең белгәннәрен, тарихи мәгълүматларын укучысына көчләп такмый. Дәүләтнең эчке һәм тышкы сыйфатлары вакыйгалар белән бәйләнештә гәүдәләнеш ала.

Ф.Латыйфи «Хыянәт» романында, тарихи дәреслеккә хилафлык китермичә, Казан ханлыгында барган вакыйгаларны күз алдына бастыра. Дәүләт булып яшәгән татар халкының гореф-гадәтләре, милли характер үзенчәлеге, әхлак ягытурында сөйләп, автор татар тарихын бозып күрсәткәнхезмәтләргә төзәтмәләркертә.

ӘДӘБИЯТ ИСЕМЛЕГЕ

1. ӘшрәфҗановХ. Тамырыбыз тарихта/Х. Әшрэфҗанов//Казан утлары. 1998. - №2.

2. Әшрәфжанов Х. Язучы **һәм** тарих / Х. Әшрәфҗанов - Уфа: Башкорт. кит. нәшр. 1998.

3. Галиуллин Т. Тарихыңны онытсаң, юк киләчәгең... /Т. Галиуллин Казан утлары. - 1992. - №11.

4 .Заһидуллина Д. Әдәбиятта Казан образы/ Д. Заһидуллина// Мәгариф. - 2005. - № 8.

Назад

## Ислам и мусульмане в литературе

*Ибрагимова Фаниля Гильмулловна,*
*преподаватель русского языка и литературы,*
*ГАПОУ «Мензелинский сельскохозяйственный техникум», г.Мензелинск*

Республика Татарстан славится своими достопримечательностями, своей историей. Но главное богатство нашей республики - это люди. За многовековую историю на нашей земле подружились между собой люди

разных национальностей и религиозных конфессий. Основную массу населения составляют татары и русские. Среди других наиболее многочисленных групп – представители титульных народов соседних республик: чуваши, мордва, удмурты, марийцы и башкиры. Такая этническая структура складывалась веками.

В Республике Татарстан большое внимание уделяется вопросам сохранения отношений добрососедства и веротерпимости между народами, а государственная национальная политика строится на двух фундаментальных положениях: необходимости всестороннего развития татарского народа и укрепления Республики Татарстан как исторически сложившейся формы его государственности, с одной стороны, и обеспечения равных условий жизнедеятельности представителям всех народов республики.

Татарстан-полиэтническая республика. Мы все знаем , представители свыше 173 национальностей проживают на территории республики, в том числе 8 национальностей, численность населения которых превышала 10 тысяч человек: татары, русские, чуваши, удмурты, мордва, марийцы, украинцы и башкиры. И религия в республике выполняет важную роль не в разрешении, а в предупреждении межнациональных конфликтов.

На территории республики зарегистрировано более тысячи религиозных объединений. Наибольшее распространение получили две религии: ислам и православное христианство. В ежегодном Послании Президента Республики Татарстан Р.Н. Минниханова Государственному Совету Республики Татарстан подчеркнуто, что «..Нашим безусловным достижением было и остается позитивное состояние межнациональных и межконфессиональных отношений, дух мирного взаимодействия и сотрудничества представителей различных этнических групп и вероисповеданий». Поэтому я считаю, что студенты и вообще молодежь, дети должны знать и понимать, что человека красит не цвет кожи и форма лица, не язык его, а добрые и красивые поступки, доброжелательное отношение и веротерпимость друг другу. В этом, конечно же, большое место отдается и религии.

Роль религии в жизни людей и народов была огромной испокон веков. Об этом писали великие русские писатели и поэты, творцы разных народов. Сегодняшняя статья называется «Ислам и Мусульмане в русской литературе».

Пушкин, Лермонтов, Тютчев, Достоевский, Толстой и другие имена великих русских поэтов и писателей известны всему миру. Их произведения - золотой фонд мировой классической литературы. Но, наверное, не все читатели и почитатели их таланта знают, что эти люди уделяли большое внимание в своем творчестве исламу и мусульманам.

«Аллах! Пролей на нас Твой свет!
Краса и сила правоверных!
Гроза гяуров лицемерных!
Пророк Твой-Магомет!...»
«О наша крепость и оплот
Великий Бог! Веди нас ныне,
Как некогда Ты вел в пустыне
Свой избранный народ!»
Глухая полночь! Все молчит!
Вдруг… из-за туч луна блеснула-
И над воротами Стамбула
Олегов озарила щит!

*(Отрывок из стихотворения Ф.Тютчева «Олегов щит»)*

В пещере тайной в день гоненья,
Читал я сладостный Коран
Внезапно ангел утешенья.
Влетев, принес мне талисман.
Его таинственная сила
Слова святые начертила
На нем безвестная рука.

*(отрывок из стихотворения А.С.Пушкина «Пещера»)*

Клянусь я первым днем творения,
Клянусь его последним днем,
Клянусь позором преступленья
И вечной правды торжеством.
*(отрывок из поэмы М.Ю.Лермонтова «Демон»)*

Творцу молитесь; он Магомету
Он правит ветром; в знойный день
Нам небо насылает тучи;
Дает земле древесну  сень.
Он милосерд: он Магомету
Открыл сияющий Коран,
Да притечем и мы ко свету,
И да падет с очей туман.
*(А.С.Пушкин «Подражания Корану»)*

Проклят тот, кто велений Корана не слышит.
Проклят тот, кто угас
Для молитвы ии битв,-кто для жизни не дышит,
Как бесплодный Геджес.
*(И.А.Бунин «Зеленый стяг»)*

Тяжела, темна стезя земная.
Но зачтется в небе каждый вздох:
Спите, спите! Он не спит, не дремлет,
Он вас помнит милосердный бог.
*(И.А.Бунин «Тэмджид»)*

Это только часть отрывков стихотворений русских поэтов. Стихов много, и в каждом из них мы слышим серьезность и торжественность, строгость, не допускающую пререканий, и красоту, не любящую одеяний популярности.

Ведь время Пушкина, Лермонтова – цветение русской словесности. В их творчестве она богата «всемерной отзывчивостью», чудесным даром перевоплощения, готова мощно ответить на сильный зов иных культур, народов, верований, в том числе и ислама.

Такие же мотивы мы видим в произведениях татарских поэтов-классиков.

О Тукае – великом татарском поэте – много писали его современники, и в наше время мы часто обращаемся к нему, размышляем над его творчеством. Ответ на вопрос: «Почему Тукай тревожит души людей?» - нужно искать в вековой истории народа. Нет у татар другого столь исконно национального поэта. Тукай – душа татарского народа, его истинный, глубинный дух. В этом кроется секрет его притягательной силы. Величие Тукая в национальном характере его творчества, которое как у истинно великого поэта стало интернациональным. Он не рассматривает свой народ в отрыве от судеб, истории других народов, он стремится поднять его до уровня прогрессивных, высокоразвитых, культурных соседей. Он звал свой народ к высотам, на которые способен подняться дух человека. Но не только традиции национальной и классической восточной поэзии питали его творчество. Мы сегодня с гордостью говорим, что Тукай учился у русских поэтов. Каждый из нас знает творчество этого незаменимого поэта, читает стихи наизусть, живет с теми героями, которые встречаются в произведениях поэта.

Так же большое количество населённых пунктов России, названы татарскими словами. Например «Саратов» — Сары тау (жёлтая/золотая гора), Тюмень — Төмен (десять тысяч или тьма), Тобольск – Тубыл, Кременчук — кирмән (укрепление, крепость). Река Соть — сөт (молоко). Азовское море связано со словом «азак». Этот список можно продолжать и продолжать. Так же, очень много татарских названий за пределами России. В Испании есть город Бильбао. Татарское название (Билбау). Их в Европе вообще очень много. Они появляются уже со времен Атиллы. Да и Золотая Орда состояла в тесных отношениях с очень многими государствами. Не было такого места, куда бы ни добрались татарские войска.

Таким образом, лексический материал, созданный в условиях развития иной культуры, иной «языковой стихии», отражает особенности восприятия мира окружением и контактами татарского и русского языков. Особая роль в обогащении лексического состава татарского языка принадлежала русскому языку, ататарские слова, в свою очередь, активно пополняли лексику русского языка.

СПИСОК ЛИТЕРАТУРЫ

1.Еникеев, Г. Р., Наследие татар. Что и зачем скрыли от нас из истории Отечества / Г.Р. Еникеев. - Казань: Китабчы Ш., 2015. –115с.

2.Юсупова, А. Ш.Татарско-русские и русско-татарские словари XIX века как лексикографические памятники и источники изучения лексики татарского языка: дис.доктор фил.наук:10.02.02: утв. 26.03.2009 / Юсупова Альфия Шавкетовна. – Казань, 2009. – с. 30-36

Назад

## М.Мәһдиевнең “Без – кырык беренче ел балалары” повестенда юмор тудыру чаралары

*Төхфәтуллина Әлфия Госман кызы,*
*Г.Тукай исемендәге Арча педагогия көллияте,*
*татар теле һәм әдәбияты укытучысы*

Иҗатын авыл җиренең гүзәл табигатен,аның гап-гади, әмма намуслы, иманлы кешеләрен сурәтләүгә багышлаган М.Мәһдиевнең әсәрләрендә иң яратып кулланган сурәтләү алымы гади сөйләм сүзләре дип әйтсәк, һич ялгышмабыз. Бу хәл гадәти дә, авыл малаеның авыл тормышы турында язуы башкача була да алмый. Аеруча, яңа гына урамнан кереп, парта арасына утырган авыл малайлары турында язганда. Гомумән, М.Мәһдиевне язучы итеп таныткан “Без кырык беренче ел балалары” повесте һәр укучы күңеленә үзләренең сөйләм галәмәтләре белән кереп кала. Теге яки бу персонажны башкача сөйләтеп тә булмас иде. Биредә авторның уңышы – җанлы сөйләм теленнән оста файдалана белүендә. Нәкъ менә шулар ярдәмендә язучы укчы күз алдында юмор катыш реаль сурәт тудыра: “Алайса, безде *алпавыт калдыгы* укыта *икәд,–* дип куйды. Әркәшәнең һәрвакыт борыны тыгылган була һәм ул бервакытта да борын авазларын *әйтеп мәшәкатьләнми иде.*

Ләкин алпавыт калдыгы безне *ормады-сукмады*, ә кемнең нәрсәгә сәләтле икәнлеген белү өчен өстәл өстенә тумбочка утыртып куйды да шуны кәгазьгә төшерергә кушты. *Иа хода! Кемнәрдән нәрсәләр генә чыкмады! Ну, тапты эш бу картлач үзе дә!* Ирекле рәсем дисен иде ул *хет!*

Тумбочканы *әмәл-чөмәл китергәч,* Иван Георгиевич, нәкъ безнең теләкне белгәндәй, ирекле рәсем ясарга кушты. ”

Гади сөйләм сүзләре янәшәсендә килгән уртак сөйләм, риторик эндәшләр дә әлеге сурәтнең эмоциональ яңгырашын тагын да көчәйтеп җибәрә.

М.Мәһдиев җанлы сөйләм сүзләрен аерым персонажларның сөйләү рәвешен күрсәтергә (тел характеристикасы өчен) кирәк булганда, аеруча, еш куллана:

*Ата кара таракаттык... Кара ата таракаттык... гаять... гаять...*

*Ах, бу «гаять»не! Явызлар да соң инде китап авторлары* ***ач калгырлары****!* *Кара тараканның кан әйләнеше гаять... гаять...*

*– Син,* ***пнимаешь, оятсыз рәвештә*** *хөкүмәтне таларга килгәнсең. Хөкүмәт сиңа көненә биш йөз грамм ипи бирә, ә син,* ***пнимаешь****, икеле аласың. Менә мин синең ипи карточкаңны тоттырып калдыртыйм әле****, булгахтырга*** *әйтеп... Ата кара тараканның кан әйләнешен белмәгән көе кая бармакчы буласың син, ә?* ***Оятсыз син, пнимаешь, актык сүз*** *шул сиңа... – дип сүгеп тә алды.*

*Ата кара тараканның кан әйләнеше яңадан бөтен классның* ***тамак төбенә төен булып утырды. Ну бу ата кара тараканны****! Кансыз гына яшәсә булмаганмы соң аңа, кансызбөҗәкләр әнә бит* ***дачурта!***

Прозадагы диалог – үзмаксат түгел. Ул геройларның фикерләү үзенчәлеген, алар арасындагы каршылыкларны һәм уртак фикерләрне, вакыйгаларның үстерелешен, әсәрнең композицион төзелешен дә бирергә тиеш. Моның өчен диалогтагы репликаларның бәйләнеше дә тормыштагы кебек табигый, берсе икенчесенә бик тыгыз бәйләнгән булу кирәк. М.Мәһдиев үз әсәрләрендә әлеге үзенчәлекне яхшы аңлап эш итә.

Әсәрдә алынма сүзләрне бозып әйтү җирлегендә туган гади сөйләм сүзләре дә күп. Аларны авторның нәкъ менә авыл кешеләре сөйләмендәгечә бирүе укучыга аеруча якын. Мәсәлән: *ачтроумно, булгахтыр, шту син, вчу, чистый жулик, пачум-зрә, черт, тульке, уптым-илахи, кумнып һ.б.*

Әсәрдә алар һәр геройның холык-фигылен, характерын ачарылык итеп уйланылган: “Дүрт малай – Әлтафи, Гыйззәтуллин, Зарифуллин һәм Әркәшә *пачум зрә* карта сугалар. Уенны Әлтафи алып бара. Гөр килә.

*– Яле, яле син, нәрсә Зөлхәбирә белән поп Василийны басасың? Уен тузын оныттыңмыни?*

*– Шалишь, агайне, мин сине хәзер Мостафа мулла белән бәрәм...*

*– Зөлхәбирәне күтәр! Зөлхәбирәне күтәр!*

Ф.С. Сафиуллина әйткәнчә, “М. Мәһдиев геройлары үзләренең сөйләм галәмәтләре белән дә күңелгә кереп калалар. Теге яки бу персонажны башкача сөйләтеп тә булмас иде кебек.. «Без – кырык беренче ел балалары»ндагы, һәрвакыт борыны тыгылган булганга «борын авазларын әйтеп мәшәкатьләнмәгән Әлтафи», һәр җөмләдә «пнимаешь» сүзен калдырмыйча сөйли торган завхоз – зоология укытучысы Исмәгыйль агай; китапчарак тел белән һәм мишәрчәрәк сөйләшүче немец теле укытучысы, *«хуч ичле тәмәке», «чин нәрчә»* дип сөйләүче география укытучысы; балаларны яратып, «ребятки» дип дәшә торган рус теле укытучысы... Болар һәммәсе тормышчан, хәтердә сөйләмнәре белән, дә яшиләр [3, б.157].”

Әсәрдә рус алынмаларны гына түгел, татар сүзләрен дә бозып сөйләүче геройлар бар. Әйтик, лирик герой тасвирлавында бирелгән немец теле укытучысы сурәте: “татар сүзләрен дә үзенчә бозып сөйләп үзәккә үтә. «Бүген» дими, *«бөгөн», «*соңга калдың» дими, *«сыңа калдың»*... Шуның дәвамы булып килгән чагыштыру һәм фразеологик әйтелмә дә җанлы сөйләмнән алынып, элеге укытучы сурәтен тагын да катлауландыра: “Шуңа күрә сүзе авыр, һәр җөмләсе *баш миенә чүкеч белән суккан кук.* Һәр *сүзе – ярага тоз”.* Әлеге сурәт аша укучыларның укытучыга түгел, ә немец теленә булган нәфрәте (автор аны дошман теле дип атый) чагыла. Шуңа күрә дә бу дәрестә *миләр кабара*, баш шаулый, ә *укытучы тукуын* дәвам итә. Шул рәвешле, җанлы сөйләм сүзләре әсәрдә персонаж сөйләмен үзенчәлекле итеп сурәтләргә генә түгел, юмор тудырырга һәм төрле мөнәсәбәтләр белдерегә тә ярдәм итә.

Икенче бер очракта, гади сөйләм лексикасын тагын да баетып, автор персонажларның дулкынланудан иҗекләрне алыштырып сөйләвен куллана. Фәндә аны метатеза дип тә йөртәләр һәм сөйләмдә аны гаять табигый дип исәплиләр. Гыйззәтуллинның рус теле дәресендә «Надание на дом... Надано за дом... Занадо за нам» дип интегүе, зоология дәресендә «Саф һава» урынына «Хаф сава» дип сөйләвен, “елга хламидоманадасы”н “елга Хәмидулла анасы” дип әйтүен укып,елмаймыйча калу мөмкин түгел[2, б. 102].

Повестьта гади сөйләм сүзләре арасында үзгәрмәс сүзтезмәләр – шактый зур урын били. Алар нигездә, җөмләгә өстәлмә рәвешендә килеп, юмор тудыралар. А*ты коргыры фән, шайтан белсен, иманыңны өшкерер бу,чәнчелеп китсен, җелек суыру, җан кәһәрләү, әҗәткана, җаныңны корт чаккыры* һ.б. шундый бары тик сөйләм телендә генә яңгырый торган, хәтта вульгар сүзләр дип әйтелергә хаклы,дорфа, төксе әйтелмәләрне еш очратырга мөмкин. Язучы кайчак уку газабыннан шулай дорфаланырга да сәләтле геройларын менә шулай, табигый итеп сурәтли. Бу авырлыкны автор күп сүз белән тасвирлапутырмый, ә кызыклы итеп, персонаж сөйләменә кертеп җибәрә.

Гомумән, М.Мәһдиев әдәби телдә чын мәгънәседә каләм остасы. Аның үз теле, язма һәм сөйләм теле гаҗәеп дәрәҗәдә бай, үзенчәлекле, халыкчан. Ә геройларының сөйләме искиткеч. Характерларына ябышып-ятып тора.

Әсәрдә кайбер сүзләр үзләренең күчерелмә мәгънәсендә килеп, гади сөйләм сүзләренә әйләнгән очраклар да бар. Мәсәлән: “Шул хикмәтле сүзне Әлтафига *ябыштырып* куйдылар бит әле!; Зарифуллин бүген үк училищедан качарга карар бирде. Аның кашлары, керфекләре тирләде. Шул минутта ул үзенең баш миен бик сыек хәлдә итеп күз алдына китерде. *Баш мие шулпаланган!* Тизрәк качарга кирәк! ; Зарифуллин ябыгып киткән, *педагогика дәресе аның итен суырган кебек иде.*; Гыйззәтуллин көче җитмәсен тоеп, бер читкә *таю* ягын карады.; Мондыйларны гына *бөккән* бар!; *Каптык...* Кем генә котыртты соң безне укырга?.. Нинди хәерсез сәгатьтә юлга чыгылды соң? Ну, бу ипи карточкасы! Шуңа кызыгып кына педучилищены сайлап алдык бит!; Уң

кулындагы озын урта бармагын күзеңә терәгәндәй *чукый-чукый белем бирә* һ.б.лар. ”

Язучы урыны белән хәтта эпитетларны да гади сөйләм сүзләре аша ясаган. Мәсәлән, *кәҗә сакаллы бабай,метмелдәп торгантешсез аңкау, ноябрьнең алама бураны һ.б.*

Сөйләмтеле элементларының матур әдәбият әсәрләренә кереп, язучы тарафыннан максатка яраклы рәвештә үзгәртелү мөмкинлеген истә тоткан хәлдә, түбәндәге төп нәтиҗәгә килергә мөмкин: матур әдәбияттагы персонаж теле белән җанлы сөйләм телен тәңгәлләштерергә ярамый, әмма шулай да җанлы сөйләмнең төп үзенчәлекләре матур әдәбият, телендә типиклаштырылган хәлдә чагылыш таба, ә моның дәрәҗәсе язучының тел байлыгына, осталыгына турыдан-туры бәйләнгән була [3, б. 69].

Нәтиҗә ясап әйткәндә, М.Мәһдиевнең сугыш чоры авырлыкларын гаять үзенчәлекле итеп сурәтләгән “Без – кырык беренче ел балалары” исемле тәүге повестенда дашул елларның кырыс вакыйгаларын, ачлык газапларын, шул чор балаларының керсез күңелләрен тасвирлауда телнең сүзлек байлыгыннан уңышлы файдалана. Аның үз теле, язма һәм сөйләм теле гаҗәеп дәрәҗәдә бай, үзенчәлекле, халыкчан. Ә геройларының сөйләме искиткеч.

ӘДӘБИЯТ ИСЕМЛЕГЕ

1. Мәһдиев М. Сайланма әсәрләр. 3 томда. т.1: Повестьлар. / М.Мәһдиев – Казан: Татар.кит.нәшр., 1994. –534 б.

2. Курбатов Х.Р. Сүз сәнгате: Татар теленең лингвистик стилистикасы һәм поэтикасы / Х.Р.Курбатов. – Казан:Мәгариф, 2002. –199 б.

3. Сафиуллина Ф.С. Сүз иясе белән йөри / Ф.С.Сафиуллина. - Казан: Тат.кит.нәшр., 1985. - 165 б.

**Назад**

# Татар әдәбиятында әдәби чаралар куллану һәм аларның әһәмияте (Экзотизмнар, варваризмнар, диалектизмнар, профессионализмнар, жаргоннар)

*Хамаева Гөлфинә Әзәр кызы,*
*татар теле һәм әдәбияты укытучысы,*
*Минзәлә шәһәре 2 нче урта мәктәбе*

**Аннотация.** Мәкаләдә әдәби чараларга күзәтү ясала. Алар әдипләр иҗатына нигезләнеп дәлилләнә, аларның әһәмияте ачыклана. Сөйләм дә, тел дә - иҗтимагый күренеш. Әдәбият тормышны, андагы үзгәрешләрне, яңалыкларны ачып бирә. Алынмалар белән эш итү дә, аларны ялгышмы, дөресме куллану да үзебездән тора. Матур әдәбиятның диалектизмнар белән эш итү юнәлешендә үз кагыйдә, закончалыклары, үз нечкәлекләре бар. Әсәрдә алар мәгънә төгәллегенә өстәп, хис төсмере бирергә кирәк булганда, персонажны тасвирлау максатында, авторның сөйләменә милли үзенчәлек ихтыяҗы туганда, шушы төбәкне тасвирлау өчен, этнографик чара буларак кулланыла. Шушы максатларда бик урынлы, нияткә ярашлы табып кулланылган диалектизмнар укучыда уңай хис тудыра, өстәмә мәгълүмат бирә. Җәмгыять үзгәргән саен, жаргон лексика составы да үзгәреш кичерә. Әдәби телгә жаргон сөйләмә тел аша, матур әдәбият аша үтеп керәләр, әмма аларның телдә кулланылуы нормалардан читләшүгә, телнең сафлыгына зыян китерә. матур әдәбият теле - образлы тел. Анда сурәтләү чаралары аша һәр язучының сөйләм үзенчәлеге күренә. Автор кулланган чаралар, алымнар җыелмасы язучының дөньяга карашын, иҗат ысулының юнәлешен дә билгели.

**Ачкыч сүзләр һәм сүзтезмәләр:** әдәби чаралар; экзотизмнар; варваризмнар; диалектизмнар; профессионализмнар; жаргоннар; халык алынмалары.

Татар әдәби теле үзенең табигате һәм вазыйфасы белән катлаулы күренеш тәшкил итә. Аның лингвистик нигезе язма истәлекләрдә чагылыш тапкан традицияләр, нормалар һәм билгеле бер төбәккә хас булган җанлы сөйләмә формалар, әдәби чаралар белән бәйләнеш-мөнәсәбәттә формалаша. Шул ук

вакытта әдәби телнең табигатендә  тормышта бара торган төрле вакыйгалар, үзгәрешләр, яңалыклар да  чагылыш таба.

Кайсы әдәбиятны, аның телен өйрәнмик, без таныш булмаган сүзләргә, сүзтезмәләргә юлыгабыз. Бер генә әдәбият та, тел дә үз сүзләреннән генә тормый. Аларда төрле әдәби чаралар, алынмалар очратабыз; экзотизм, диалектизм, жаргон сүзләрне күрәбез.

Татар әдәби телендә  алынма сүзләрнең күпчелеген экзотизмнар, варваризмнар, һөнәри сүзләр һәм башкалар тәшкил итә.

***Варваризмнар*** (*гр.* barbaros - *чит, ят)* — чыганак телдәге бөтен үзенчәлекләрен саклаган чит тел сүзе. Варваризм кабул итә торган телнең закончалыкларына тулысынча яисә бөтенләй буйсынмаган хәлдә телдә яшиләр: *мадам, дэнди, хобби, блендер, демо, гаджет.* Еш кына чыганак тел хәрефләре белән дә биреләләр: *baby, alma mater h.б.*

Ләкин шуны әйтәсе килә: алар тел фәнендә дә, мәктәптә дә юньле-башлы өйрәнелми; тискәре күренеш дип кенә бәяләнеп кителә. Варваризмнарны бүгенге көндә без борчу буларак кабул итәбез. Әмма  аларның да  үз тарихы бар.  Ул төр алынмалар - телебезнең һәм сөйләмебезнең тарихи күренеше.

Варваризмнарның иң беренче үрнәкләрен  халык җырларында  очратабыз. Алар  фикерне төгәл, үтемле, хисле  итеп җиткерү өчен кулланылганнар.

*Синең буй-сының бигрәк зифа,*

*Сад алмасы ашап үскәнгә;*

*Колагыңа элгән серганы*

*Алтынчылар каеп биргәндер.*

Варваризмнар белән төгәллеккә, нечкә образ тудыруга ирешеп булуы да җырлардан яхшы күренә:

Әй зимагур, ни хәлең бар, илеңә хат саламсың?

Какой илгә хатлар салу, күлмәк сатам – аламсың?

Габдулла Тукайның “Тотса мәскәүләр якаң” шигыре тулысы белән варваризмнардан тора, дисәк тә була.

Ни кыйлырсың, хаҗи абзам, тотса мәскәүләр якаң? Как ты будешь отвечать там, тотса мәскәүләр якаң?

Сыгъмаз ирдең киң җиһанга, малыңа мәгърур булып; Даже в тюрьму сыярсың, тотса мәскәүләр якаң.

“Типтереп” йөрдең тәтәйләрдә, театрны сүгеп; “Нет, князь, постой!” — диерләр, тотса мәскәүләр якаң.

Тукай монда аларны ачы көлү өчен куллана.

Галиәсгар Камалның “Беренче театр” комедиясендә варваризмнар юмор һәм сатира алымы буларак кулланылалар. Әсәрнең язылу вакыты - татар әдәби теленең гарәп – фарсы сүзләрдән арынган чоры, ә алмашка әле чын татар сүзләре килмәгән. Мәсәлән, *“Әхмәтҗан, ул һәркөнне өчәр мәртәбә сакалларын китәреп, пудырлар сөртеп йөри”.* [ 6, 35]

*“Биби. ... чәй урыны әзерли... аның янына эмалированный пласкательный куя”.* [ 6, 46]

*“Пристефне өйдә туры китереп булмады, главага менгән идек, ул да алар яклы булырга кирәк...”* [ 6, 46]

Фатих Әмирханның “Хәят” повестенда да моңа мисаллар күп. Ә бу әсәрдә инде алар татар һәм урыс гаиләсенең үзара аралашып яшәүләрен, татарларның урыс гадәтләрен үзләренә кабул итә башлауларын, шул ук вакытта Хәятнең зәвык белән киенүен күрсәтә. Үз – үзен тотышы, киеме аның эчке халәтен ачып бирергә ярдәм итә.

*“Хәят прическасын ясап бетергәч, дуслар ничек киенү турысында кызу гына сөйләшеп алдылар...”* [6, 51]

Бәйләү чаралары вазифасын үтәүче берәмлекләргә дә тукталып үтик. Без аларны “паразит” сүзләр дип тә атый алабыз. Мәсәлән*: ызначыт, наканис, нүжәли, пака, зерә, перәме, тәк, ычто, ычтобы, но, только, канса канис, действительно, нечего, ә какже, такчто, и, или, да, итәкдәли* һ.б. Дөрес, соңгы вакытта без бу сүзләрдән арынырга тырышабыз, чистарына барабыз.

Шәриф Хөсәеновның “Әни килде” драмасында Сәяр белән Римма рус сүзләре кушып сөйләшәләр. Бу аларның заманага иярүләредер, мөгаен. *“Сәяр.*

*Ошыймы сиңа минем хозяйкам? Римма. Яратам. Приходи к воротам...”* [ 6,158]

Мондый сүзләр бүгенге көндә күп очрый. Бигрәк тә, журналистлар телендә, төрле очрашуларда. Мәсәлән, алар сүз таба алмаганда, *“Кемнәргә ул файда, урысча әйткәндә, “Кому это выгодно”, “Урыслар әйтмешли, комментарий излишни”, “Урыс әйткәндәй”, так чту, китап укыйсың килсә...” һ.б.*

Димәк, сөйләм дә, тел дә - иҗтимагый күренеш. Әдәбият тормышны, андагы үзгәрешләрне, яңалыкларны ачып бирә. Алынмалар белән эш итү дә, аларны ялгышмы, дөресме куллану да үзебездән тора.

***Экзотизмнар*** — теге яки бу халыкның үзенчәлекле милли сыйфатларын һәм көнкүрешен белдерүче чит тел сүзләре. Бу сүзләр фәнни, публицистик һәм матур әдәбиятта кулланылалар.

Экзотизмнарның үзенчәлеге:

- алар бер милләткә, дәүләткә карыйлар;
- татар кешесенә бик үк таныш түгел;
- телдә синонимы юк;
- әсәр тукымасына бизәк өстиләр.

Экзотизмнарны түбәндәге төркемнәргә бүләргә мөмкин:

1) Дәүләт, хәрби оешмаларга караган сүзләр: рейхстаг, сенат, парламент,
2) Акча берәмлекләре: франк, доллар, иена, су, лира, песо, юань;
3) Кием – салым исемнәре: чалма, сари, кимоно, галстук
4) Дәрәҗә, һөнәргә караган сүзләр: спикер, полисмен, канцлер;
5) Җил исемнәре: торнадо, арменаз, мистраль.

Фатих Әмирханның “Хәят” әсәреннән мисал китереп үтик.

*“Аның быел тектергән ал ефәк декольте күлмәге инде җиткән кызлар кия торган модаларның иң соңгысы белән тегелгән иде”.* [ 6, 51] “Декольте” сүзе Хәятнең портретын ачып бирергә ярдәм итә.

Шакир Мөхәммәдевның “Япон сугышы, яки доброволец Батыргали агай” исемле повестенда экзотизмнар сатира тудыру өчен ярдәм итәләр. *“Французларга мәхәббәте шул хәтле артты ки, акча хисапларын да франк хисабы илә йөртә башлады...”* [ 7, 96]

Аяз Гыйләҗевның “Җомга көн кич белән” повестеннан: *“Иртәгә корреспондент килеп төшәчәк... Зингер машинасы күренсә...”* [ 6,153]

Шулай итеп, экзотизмнар әдәби әсәрләрдә эстетик функция башкаралар,

ягъни әдәби образ, портрет тудырырга ярдәм итәләр; юмор барлыкка китерәләр.

Телнең билгеле бер төбәктә генә таралган төрен ***диалект, җирле сөйләш*** дип атыйлар. Шул төбәккә генә хас, гомумхалык теленә кермәгән сүзләрне диалекталь лексикага кертеп карыйлар. Диалекталь сүзләр территориаль яктан чикләнгән булалар.

Татар теле өч диалекталь берәмлеккә бүленә:

1) урта диалект;

2) көнбатыш диалект (мишәр);

3) көнчыгыш диалект (Себер татарлары теле).

Урта диалектның кайбер лингвистик үзенчәлекләре:

1) җ-ләштерү: *җул, җегет*.

2) [к], [г] авазларының калын әйтелеше: *къарга, къамыш*;

3) [а] авазының о-лаштырылуы: *ба°ла°лар*.

4) ф//п күчеше: *Патыйма*;

5) х//к күчеше: *катын*;

6) III зат тартым формасының кабатлануы: *ансысы*;

7) инфинитив формасы -мага, -малы: *бармалы*.

Көнбатыш диалектның кайбер лингвистик үзенчәлекләре:

1) й-ләштерү: *Йамали, йаңы*;

2) [а] авазының ачык итеп әйтелүе: *бала*;

3) ирен-ирен [о], [ө], [у], [ү] иренсезләштерү: *кен, беген, тен, кыяш*;

4) дифтонгларны монофтонглаштыру: *сүләү, әдә, ү, бәрәм*;

5) [ķ], [г] авазларының [к], [г] булып әйтелүе яисә төшеп калуы: *кар, афу*.

Көнчыгыш диалектның кайбер үзенчәлекләре:

1) ц-лаштыру: *пыцак, бырцак*;

2) [б], [д], [з] тартык авазларының саңгырау парларына алмашынуы: *Пыел урашай полса ярар иде*.

Диалекталь сүзләр көнкүреш сөйләм стилендә һәм матур әдәбиятта ешрак очрый. Әлбәттә, диалектизмнар куллану күпмедер дәрәҗәдә каршылыклы бара: бер яктан сөйләм иясенә үз ягында күнеккән сүз, гыйбарәләр якын, аһәңле *(ызба, богыл, җылау, карагат, мөеш, бармай, кайтмай һ.б.);* икенче яктан, аларны бары бер шарт үтәлгәндә генә кулланырга мөмкин.

Гаяз Исхакый әсәрләреннән мисал китереп үтик. *"Теге абзый тагы бер ашаяк бәрәңге белә бер башкорт тустагы шурпа да алып керде".* [ 3,171] *"Тәрилкәнең агы затлы, ди. Муллаларда һәрвакыт ак тәрилкәләр!"* [ 3,239] *Үземнең күңелемнең* ***йемешен*** *сезгә тәкъдим итәм".* [ 3,152]

Димәк, матур әдәбиятның диалектизмнар белән эш итү юнәлешендә үз кагыйдә, закончалыклары, үз нечкәлекләре бар. Әсәрдә алар, мәгънә төгәллегенә өстәп, хис төсмере бирергә кирәк булганда, персонажны тасвирлау максатында, авторның сөйләменә милли үзенчәлек ихтыяҗы туганда, шушы төбәкне тасвирлау өчен, этнографик чара буларак кулланыла.

***Һөнәрчелек лексикасы (профессионализм)*** - билгеле бер кешеләр төркемендә яисә коллективта, билгеле бер сөйләмдә (стильдә) генә, билгеле бер иҗтимагый катлам яисә аерым бер шәхес сөйләмендә генә кулланыла. Шушы үзенчәлеге белән бер - берсенә охшаш, кардәш булсалар да, куллану ягыннан алар бер - берсеннән аерыла.

Әдәби әсәрдә профессионализмнар гади укучыга мәгълүм һөнәр ияләрен якыннан аңларга булыша; өстәмә мәгълүмат та бирә; шул ук вакытта әсәрне тиз укырга комачаулый, укудан бүленергә мәҗбүр булудан ризасызлык тудыра. Габдрахман Әпсәләмовның "Ак чәчәкләр" әсәрендә табиблар, "Сүнмәс утлар"да – эшче, "Яшел яр" әсәрендә укытучы һөнәренә караган сүзләр очрый. Мәсәлән: *"Хирург, аның ярдәмчеләре авыру өстенә*

*иелгәнннәр”.* [ 6,121] *“Икенче инфарктны да җиңеп, аякка баскан Николай Максимович бүген өенә кайтып китәргә тиеш”.* [6 ,125]

Миргазиян Юнысның “Шәмдәлләрдә генә утлар яна”, “Юлда уйланулар” әсәрләре очучы, диңгезче хезмәте турында. Әсәрләрдәге һөнәри сүзләрне укыгач та, вакыйгаларның кем яки нәрсә турында барачагы аңлашыла. *“Җилкәләренә парашют салып, караңгылыкны ерып баручы өч егет моңсу торнаны хәтерләтә иде”.* [ 6,135] *“ПЕ -2 , ерактан урап, аэродром өстенә чыкты...”* [ 6,136*]* *“Марсель Ялчинскийның самолетта калып янган гәүдәсе иде бу”.* [6 ,140]

***Жаргон*** - бердәй һөнәр, көнкүреш шартларында, уртак кызыксынулар белән бергә вакыт үткәрүче бер төркем кешеләр сөйләмендәге үзенчәлекләр.

Гомумхалык сүзләре, жаргон рәтенә күчкәндә, семантик яктан үзгәреш кичерәләр, мәсәлән, якынрак утырту - тегүчеләр телендә ваграк атлатып тегүне белдерә. Жаргон лексика телнең үз сүзләре һәм алынмалар исәбенә тулылана (ычкыну - качу, мотор - машина һ.б.). Характерлары ягыннан жаргон сүзләр шаярту - ирониядән алып, тупас - вульгар төсмерләргә кадәр ия булырга мөмкиннәр.

Жаргон лексика, нинди иҗтимагый катламда куллануга карап, 2 төргә аерыла: киң катлам кешеләр телендә кулланыла торган (яшьләр, студентлар телендә: *«телик» - телевизор, «картлар» - әрмедә приказ көтүче солдат, «стипа» - стипендия, «шпора», «бомба» - шпаргалка һ.б.);* тар, ябык коллективларда, башкаларга аңлашылмаслык итеп, конспирация максатыннан кулланыла торган жаргон - <u>арго</u>.

Җәмгыять үзгәргән саен, жаргон лексика составы да үзгәреш кичерә. Әдәби телгә жаргон сөйләмә тел аша, матур әдәбият аша үтеп керәләр, әмма аларның телдә кулланылуы нормалардан читләшүгә, телнең сафлыгына зыян китерә.

Мәсәлән, жаргонизм иң төгәл, өстәвенә әле сурәтле-образлы да, кызыклы әйтелешле-яңгырашлы да. Бүген яшьләрнең теләсә кайсы төркеме сөйләменә колак салсаң, теләсә кайсы темага, хәтта көнкүреш, иҗтимагый-сәяси

темаларга сөйләшүләрендә дә жаргонизмнар тулып ята: *тулай торак аларча общага, телевизор – телик, аяк – тәртә, кул – тырма, кеше – эшләпә, ашханә – тошниловка, ресторан – кабак, кабактерий, акча – бабки-тугриклар-боксы, ун сумлык – кәгазь, йөзлек – кисәк (кусок)* һ.б.

Мәдинә Маликованың "Чәчкә балы" повестенда, Макар – Мохтарның характерын ачып бирү өчен, бу төр сүзләр шактый кулланылган. *"Синең баруыңнан миңа ни файда? "Доза"ны барыбер алып бирмәячәксең бит!"* [ 6, 218] *"Аннары... шәһәргә барсаң да, сине анда ак порошокны әлүмин кашыкта эретеп көте тормыйлар".* [6, 218] *"Әллә телевизорны алып чыгып шыларгамы?"* [ 5, 218]

Жаргон, арго берәмлекләре сөйләм иясенең кем икәнен ачыкларга, аның телгә, үз-үзенә мөнәсәбәтен тоемларга юл ача, сөйләмне төгәл, үтемле, сурәтле, җанлы итә; күп кенә тарихи мисалдан күренгәнчә, телне баетуга да берникадәр өлеш кертә.

Күзәтүләрдән күренгәнчә, матур әдәбиятта персонажның холкын-характерын тулырак ачу, вакыйга-ситуацияне сурәтлерәк күзаллау өчен, мондый төр лексик чаралар бик кулай да бит, әмма матур әдәбиятның барлык укучылар өчен дә язылуын онытмаска кирәк.

Мәкаләне тәмамлап, шуны әйтәсе килә: матур әдәбият теле -образлы тел. Анда сурәтләү чаралары аша һәр язучының сөйләм үзенчәлеге күренә. Автор кулланган чаралар, алымнар җыелмасы язучының дөньяга карашын, иҗат ысулының юнәлешен дә билгели. Әдипләребез иҗат итсен, сөйләмебез шундый энҗе бөртекләре белән дә тормышчан-җанлы, үтемле-тәэсирле булсын.

КУЛЛАНЫЛГАН ӘДӘБИЯТ

1. Әхмәдуллин, А. Г. Әдәбият белеме сүзлеге. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1990.

2. Галиуллин, Т. Н. Шигърият баскычлары: Әдәби тәнкыйть мәкаләләре. – Казан, 2002. – 135-140 б.

3. Исхакый, Г. Зиндан. – Казан: Татар кит.нәшр.,1991.

4. Низамов, И. Ана теле. Фикерләр. Матбугат.ру. 07.11.2017

5. Сафиуллина, Ф.С. Хәзерге татар әдәби теле. Лексикология. – Казан: Хәтер, 1999.
6. Фәрдиева, Х.Г.Татар әдәбияты. 9 нчы сыйныф. – Казан: Татар кит.нәшр., 2017.
7. Хәсәнова, Ф. Ф. Татар әдәбияты. 9 нчы сыйныф.- Казан: “Мәгариф – Вакыт” нәшр., 2016.

Назад

## Камил Кәримов әсәрләрендә һөнәрчелек лексикасының кулланылышы

*Хәйруллина И.М., Талипова Г.Ф.,*
*ДАҺБУ “Муса Җәлил исемендәге Минзәлә педагогия көллияте”*

Һөнәрчелек лексикасы - билгеле бер һөнәр кешеләре генә куллана торган сүзләр. (Һөнәр - фарсы сүзе - осталык, булганлык, булдыручанлык дигән мәгънәне аңлата). Алар махсус төшенчәләрне, эш коралларын, хезмәт процессын белдерәләр. Диалекталь сүзләрдән аермалы буларак, һөнәрчелек лексикасы иҗтимагый яктан чикләнгән була. Һәр һөнәр иясенең үзләренә генә хас сүзләре була: табиблар, укытучылар, балыкчылар, хәрбиләр һ.б. Кайбер һөнәрчелек сүзләренең кулланылыш даирәсе киңәергә дә мөмкин.Аерым очракларда  әдәби әсәрдә профессионализмнар гади укучыга мәгълүм һөнәр ияләрен якыннан аңларга булыша; өстәмә мәгълүмат та бирә; шул ук вакытта әсәрне тиз укырга комачауларга да мөмкин. Һәрхәлдә һөнәрчелек сүзләре һәр төр сөйләмдә, беренче чиратта, матур әдәбият әсәрләрендә, публицистикада стиль чарасы, өстәмә мәгълүмат, белем чыганагы буларак урын ала алсалар да, монда һичшиксез чама белү сорала; урынсыз әйтелгән (язылган) бер генә сүзнең дә әллә күпме зарар китерүе ихтимал. Бер кисмәк балга төшкән бер кашык дегет шул булыр.

Әсәрләрендә һөнәрчелек лексикасы белән артык “мавыккан” язучыларыбызны байтак димәс идек. Хәзерге әдәбиятта бигрәк тә. Әмма араларында билгеле бер һөнәр ияләрен алып, аларның тормышларын да,

хезмәтләрен дә яктыртып, иҗатында специфик сүзләрне яратып кулланган Камил Кәримовны атамый калып булмый. Аның артезиан коелары бораулап, халыкны су белән тәэмин итүчеләрнең тормышларын, эш-гамәлләрен, уй-хисләрен, үзләренең дә кешечә яшәргә тырышу-омтылышларын сәнгатьчә тәэсирле, ышандырырлык итеп тасвирлаган "Ком сәгате" дилогиясе әдәби тәнкыйтьтә авторның зур уңышы итеп бәяләнә. Әдипнең биографиясенә күз салсак, К. Кәримов урта мәктәпне тәмамлагач, 1969 елның көзеннән «Татмелиоводстрой» тресты системасында бораулау станогы дизелисты булып эшли. Бер елдан Ростов-Дон өлкәсендәге Батайск шәһәренә бораулау мастерлары әзерли торган һөнәри-техника мәктәбенә белемен арттырырга җибәрелә. 1972 елда укуын тәмамлап кайткач, К.Кәримов 1976 елның көзенә кадәр Казан шәһәрендә әүвәл су скважиналары бораулаучы, соңыннан сантехника җиһазларын ремонтлаучы слесарь булып эшли. Шунлыктан ул әлеге һөнәр ияләренең лексикасын бик белеп һәм урынлы итеп куллана.

1. Сиксәненче елларда "Ак Чишмә"дә унбиш бригаданың һәркайсы көне-төне колхоз-совхозлар өчен *су скважиналары* бораулый торган иде. (10 б.)

2. "Иң зур *долото* белән бораулыдым коены. Ун метр төшкәч чуерташ башланды. Ну, шәп су чыкты. *Асбест* торба төшереп, эшне төгәллибез дигәндә, Самат абый кое төбенә борылып карыйсы итте, ну.....суы калынмы, янәсе..." (18 б.)

3. *Инженер*ыбыз яшь. Көне-төне Наил Кадыйрович йомышы белән, малай-шалай шикелле чабып йөри шунда.

4. Ул *инжен*ерың чыксын иде безнең белән! Бригадаларда башына кияргә *каска* таба алмыйча интегәчәк ул! Егетләр унсигезәр метрлы *вышка*га бернинди *страховка*сыз менәләр. Менгәч, билдән каптыра торган чылбырларны берәрсенең күргәне бар микән? Утызар градуслы суыкларда көзге пәлтә калынлыгы вагоннарда *электр спирален* сүндермичә өч ир-егеткә йоклап ятарга ярый дигән кагыйдә бармы?

5. Ә Зәмир – Раштуа суыгында, *су шлангасы* ярылып, йөз дә ун *атмосфералы фонтанга* коеныл, шул вагонда катып үлде. (25 б.)

6. Минем яраткан чишмәләрем бихисап! Утыз ел эчендә өч йөздән артык авылда *артезиан чишмә* казып киттем.... Бораулап бетерәсең, *насосн*ы тирәнгә төшерәсең, утны тоташтырасың да ком сәгатенә карап көтәсең. Баштарак балчык боламыгы бәреп чыга, әкренләп су фонтаны язгы инеш төсенә керә, инеш төсе аертылган сөт белән алышына, сөтле су әкренләп яктыра башлый... һәм, ниһаять, чык бөртеге сыман саф чишмәгә әверелә. Аны иң беренче булып син эчәсең... (81 б.)

7. Яшелчә бакчаларын коендырганда, мунчалар якканда, фермаларга су үткәргәндә табигый чишмәләрне борчымас өчен юньле хуҗа *су скважиналары* казыта. Халык телендә *су бораулаучыларны*, гади итеп, *кое казучылар* дип кенә йөртәләр, *электр чишмәләре* инешкә агып ятмый, тирә-юнендә таллар яшәрми, суының пакьлеге лабораторияләрдә тикшерелгән һәм бер эчеп түгелгәч, табыннарга кире әйләнеп кайтмый.... Бүгенгесе көндә Татарстан җирендә әнә шундый алты мең *су скважинасы* бар. (85 б.)

8. Бүген *монтажлау* көне. *Вышканы* күтәрәсе, *долотоны* әзерлисе. Чокырга бер-ике машина су китерәсе – сеңә торсын. (88 б.)

9. Менә бу *агрегат – вышкасы, грязь насосы, платфомасы,* яшел вагоны белән бергә *бораулау җайланмасы.* .... завод чыгарган исеме *"УРБ-3"* аның, ягъни *разведкага бораулау җайланмасы*.... Хәзер тыңлап тор. Мәдияр Богадыга суга киттеме - китте. Ул алып кайткан өч *цистерн*а суны менә шушы *зумфка, отстойникка...* сусыз бораулап булмый.

10. ... Менә бу *грязь* насос чокырдагы суны бораулау торбалары аша үткәреп, *долотоны* майлап, казылган балчыкны юдырып өскә чыгарып тора. (91 б.)

11. Татарстанның *Мелиорация һәм су эшләре министрлыгына* буйсына торган "Ак чишмә"дә йөз егерме *бораулаучы*, ягъни кое казучы бар. (136 б)

12. Кызыл балчык тирәнгә төшкәч тә каты токымнардан исәпләнми, ләкин ул *долотоның тешле тәгәрмәчләренә* сыланып, аяк чолгавы сыман урала һәм тиз борауларга ирек бирми. Таш катламын тишүе җиңелрәк – анда долото бушка әйләнми, тешләре, ташны уалап, бии-бии барыбер аска төшә...

Лексик берәмлекләрне тикшергәннән соң, бу очракта һөнәри лексика әдәби әсәрне кабул итүгә комачаулык тудырмый дигән фикергә килдек.

Гомумән, татар милләте хезмәт яратучан, кызыксынучан, белемле һәм белдекле, дөньяның төрле кыйтгаларына таралып, төрле һөнәргә җәлеп ителгәнлектән, ул күп һөнәрле дә; шуңа күрә аның һөнәрчелек лексикасы да телендә бик борыңгыдан тупланып килеп, бай хәзинәгә әверелгән. Җир эшкәртеп иген игү, урман кисеп, сал агызу; шахтада күмер чабу; нефть чыгару; туку, чыпта, палас сугу, кием кисү-тегү; мех эшкәртү, күн ясау; балта эше; слесарьлек, тимер-чуен кою, аны эшкәртү, очкычлар, кораблар, автомобиль ясау һәм башка бихисап хезмәт-һөнәрчелек өлкәсендәге тәҗрибә катлам-катлам булып телебез хәзинәсендә дә саклана.

Назад

## Муса Җәлилнең “Алтынчәч” либреттосында күчерелмә мәгънәдәге сүзләрнең кулланылыш үзенчәлекләре

*Хуснуллина Зилина Магфуровна,*
*преподаватель татарского языка и литературы*
*ГАПОУ«МЦК-КТИТС», г.Казань*

Сүзләрдәге күчерелмә мәгънәләрнең төрләре һәм аларның барлыкка килү юллары элек-электән игътибар үзәгендә торды. Халкыбызның мәкаль-әйтемнәре, чагыштырулар, метафора, эпитет һ.б. сөйләмнең яңгырашын көчәйтәләр генә, тормыш күренешләрен кыска, җыйнак һәм образлы итеп сурәтләп бирәләр.

Чагыштыру – дөньяны танып белүдә әһәмиятле алым ул. Бер әйберне яки күренешне икенчесе белән чагыштырып, без үзебезнең белемебезне арттырабыз, ике әйбер яки күренеш арасындагы охшаш якларны билгелибез. Әмма чагыштыруда охшашлыклар гына бирелми, шулай ук аерым яклар да чагыштыру юлы белән күрсәтелә ала. Чагыштырулы төзелмәләр матур

әдәбиятта киң һәм яратылып кулланыла. Яшь буынга фән нигезләрен аңлатуда да чагыштыру алымы ярдәмгә килә.[1]

"Әдәбият белеме сүзлеге"ндә чагыштыруларга түбәндәге билгеләмә бирелгән: "**Чагыштыру** – тропларның иң гади һәм иң таралган төрләреннән берсе; нинди дә булса күренешне аңа охшаш үзенчәлеге булган икенче күренеш үзенчәлеге белән сыйфатлап чагыштыру – охшату.[2] Алар телдә бик күп. Ләкин күбесенә күнегелгән һәм игътибар ителми. Чагыштыруларның төрле формаларын файдаланып, язучы күренешләрне, кешеләрне сурәтләүдә ачыклыкка, аларның сыйфатларын калку итеп тасвирлауга ирешә.

Чагыштырулар сөйләмгә җанлылык, эмоциональлек бирә, автор хикәяләвенә төрле сурәтле төсмерләр өсти. Мәсәлән, "сагынганда айга карыйм, ай да ялгыз минем күк" дигән халык җырында "мин" – чагыштырыла торган өлеш, яки чагыштырылмыш туры мәгънәсендә килә, "ай да ялгыз" өлеше чагыштырмыш буларак, ялгызлыкның нинди булуын калкулатып күрсәтүче яки чагыштырмыш вазыйфасын үти. Охшату өлеше сурәтне тирәнәйтеп, нәфисләп күрсәтә. Шулай ук "Татар теленең аңлатмалы сүзлегендә" дә чагыштыруга төгәл билгеләмә бирелә: "Күренешләрнең, предметларның һ.б. охшашлыкларын яки аермаларын, яисә берсенең икенчесеннән өстенлеген билгеләү, ачыклау өчен тикшерү. Кем яки нәрсә белән дә булса тиңләү, кемгә яки нәрсәгә булса да охшату"[3], - дип аңлатыла.

Чагыштырулар янында сүзләрнең кабатланып килүе сөйләмнең экспрессивлыгын тагын да арттыра. Халкыбызның йөз меңләгән мәкаль һәм әйтемнәрендә чагыштыруларның барлык төрләре дә очрый.

Чагыштырулар төрле грамматик чаралар белән башкарыла алалар:

1) бәйлекләр белән

*Кебек, күк, төсле , шикелле, сыман, чаклы, хәтле, кадәр* бәйлекләре, -*дай/-дәй, -тай/-тәй*кушымчалары охшату-чагыштыру өчен кулланылалар.

---

[1]Ибраһимов С.М. Татар телендә синтаксик синонимнар / С.М. Ибраһимов. – Казан: Казан ун-ты нәшр., 1976. – Б.149.
[2] Әдәбият белеме сүзлеге / Төз.-ред. Әхмәдуллин А.Г.- Казан: Тат.кит.нәшр., 1990.- Б.207.
[3] Татар теленең аңлатмалы сүзлеге: 3 томда. 3т. – Казан: Тат.кит.нәшр., 1981. –Б.400.

Шулардан *кебек , күк, төсле, шикелле, сыман* сыйфат ягыннан, *чаклы, хәтле, кадәр* бәйлекләре күләм ягыннан чагыштыруны аңлаталар. *Төсле , шикелле*бәйлекләре *төс, шикел* (шәкел – форма) сүзләренә сыйфат ясагыч *–ле* кушымчасы ялганып ясалганнар; *чаклы, хәтле* бәйлекләре *чак* (*чик*)*, хәт* (гарәпчә *чик* мәгънәсендә) сүзләренә шул ук кушымча ялганып ясалганнар, *кебек* сүзенең этимологиясен дә проф. Н.К. Дмитриев *кеп* (форма) дигән сүзгә бәйли. *Күк* бәйлеге исә *кебек*, тән кыскартып ясалган. Димәк, төс һәм форма белдерә торган сүзләрдән килеп чыккан бәйлекләр сыйфат буенча чагыштыруны, *чик* мәгънәсеннән килеп чыккан бәйлекләр күләм ягыннан чагыштыруны белдерәләр.[4]

Чагыштыруларда бәйлекләр бик еш кулланыла. Телнең тарихи үсешендә аларның төрле формалары барлыкка килгән.[5]*Кебек, шикелле, төсле* бәйлекләре, *-дай/-дәй, -тай/-тәй*кушымчаларыннан белән килгән чагыштыруларны М.Җәлил үзенең “Алтынчәч” либреттосында бик еш һәм уңышлы куллана:

А) *кебек* бәйлеге ярдәмендә ясалган чагыштырулар:

“Үлсәм-нитсәм каурыйлар
Каралырлар **көл кебек...**”[6]

Б) *шикелле* бәйлеге ярдәмендә ясалган чагыштырулар:

Син аргансың, Алтынчәч!
Ял ит чишмә буенда,
Чишмә акканын кара,
Алтын чәчеңне тара!
Буең зифа, сөйкемле,
**Йөзең кояш шикелле,**
Чәчеңнең һәр бөртеге
Алтын нурлар шикелле!

---

[4]Тумашева Д.Г. Хәзерге татар әдәби теле / Д.Г. Тумашева. – Казан ун-ты нәшр., 1978. – Б. 260.
[5]Хаков В.Х. Татар әдәби теле: ( Стилистика) / В.Х. Хаков – Казан: Тат.кит.нәшр., 1999.- Б.304.
[6]Җәлил М. Әсәрләр / М.Җәлил; Төз., кереш сүз авт.: Т. Н. Галиуллин, Н. М. Гафиатуллина. - Казан: Мәгариф, 2004 – Б. 213.

В) *төсле* бәйлеге ярдәмендә ясалган чагыштырулар:

**Кояш төсле** ал йөзле

Угыл таптың. Каракаш!.. 165

Тормыш-көнкүреш вакыйгаларын, табигать күренешләрен сурәтләгәндә, чагыштыру чараларыннан элек-электән иркен файдаланганнар. Алар арасында кушымчалар да бик зур урын алып торалар. Муса Җәлил гадәттә чагыштыру мәгънәсен бирүдә **-дай/-дәй, -тай/-тәй** кушымчаларыннан да актив файдалана. Мисаллар:

Җир җиләген җыйганда,
Карагайлы урманда,
Калды бездән адашып
Гөл чәчәге—Алтынчәч!..
Буйга үсеп булганда,
**Йөзе айдай** тулганда,
Һәлак була күрмәсен
Бәхет кошы — Алтынчәч. 180

Буең — диңгез камышы,
Тавышың — былбыл тавышы,
Йөрәгемдә сагышың,
Таңыма Чулпан булсаңчы...
Кара нәркис күзләрең,
**Гөлчәчәктәй** йөзләрең,
Өзелә бит үзәгем,
Мәңгелек яр булсаңчы... 188

Әлеге өзектә лексик чара ярдәмендә ясалган чагыштыру да бар: Алтынчәчнең буен (озын, зифа буйлы кыз) диңгез камышы белән чагыштыра.

**Буең — диңгез камышы**...188

Сурәтләү чаралары халык телендә дә, әдәби әсәрләрдә дә мул кулланыла. «Бер әйберне икенче әйбердән аеру өчен туры мәгънәсендә кулланылган сүз

*логик эпитет,* логик аергыч дип атала: *ак* чәчәк, *зур* бакча, *давыллы* көн һ. б. Ләкин туры мәгънәсендә генә кулланылгач, андый эпитетлар әдәби әсәрдә образлы булып килә алмыйлар икән дип уйларга ярамый. Образлылык сүзнең ялгыз торганында түгел, күп вакыт сүз сөрешендә ачыклана. Билгеле бер сүз сөрешендә *логик эпитет* та янәшә сүз (аерылмыш) белән берлектә сүз-сурәт ясый. Метафорик эпитет ул — күчерелмә мәгънәле сүз яки сүз тезмәсеннән торган аергыч, ягъни аергыч булып килгән метафора[7].

Чыннан да, әйберләрнең үзенчәлеген, сыйфатын, характерлы билгесен ачыклаганда язучы логик эпитет белән дә, метафорик эпитет белән дә эш итә. А. М. Пешковский әйткәнчә, “мәсьәлә образлы тәгъбирләрдә генә түгел, ә бәлки гомум образлылык планында, сәнгатьлелек максатында кулланылган һәр сүзнең котылгысыз образлы булуында “.

Муса Җәлилнең “Алтынчәч” либреттосы эпитетларга бик бай: *матур ак муен, тыныч; матур ил; буең зифа, сөйкемле;, зәһәр агулы баш; каргалган нәсел курыкмас батыр* һ.б. Аларның һәрберсенең үзләренә хас стилистик үзенчәлекләре бар. Әйберне бер үзенчәлек буенча характерлаганда ялгыз эпитет куллану да җитә[8]. Әсәрдә персонажны төрле яклап характерларга кирәк була. Бу очракта аның портретын тасвирлау, эчке дөньясын ачыклау өчен берьюлы берничә эпитет ярдәмгә килә. Эпитетларның түбәндәге төрләренә тукталып үтәбез:

1. Метафорик эпитетлар: *канлы үч, канлы тир, канлы яшь, канлы кул; якты йолдыз, алтын каурый, яшел хәтфә алан.* Беренче төркем авыр көрәш елларын чагылдыра.

Тугзак иле чиксез күк булса,
**Якты йолдызларым** сез минем!
Тугзак иле төпсез күл булса,
Шаян кондызларым сез минем!

[7]Поварисов С.Ш. Тел – күңелнең көзгесе / С.Ш.Поварисов. – Казан: Тат. кит. нәшр., 1982. – Б. 108.
[8]Поварисов С.Ш. Тел – күңелнең көзгесе / С.Ш.Поварисов. – Казан: Тат. кит. нәшр., 1982. – Б. 109.

2. Тезмә һәм җәенке эпитетлар: *бөтен илне таңга калдырган табыш; коллык сөймәс бабагыз; мең яшәрле юхалар; сер сынатмас ат; ялгыз янар йолдыз* һ.б. Мисаллар:

Кара урманның артында

Ялгыз янар йолдыз бар.

Либреттода ана образы – символик образ. Автор әсәрнең пролог өлешендә 13 мәртәбә ана образына – Тугзакка мөрәҗәгать итә һәм түбәндәге эпитетларны куллана: *бөек ана, данлы ана, кадерле ана, газиз ана, туган ана,*

Шулай итеп, Муса Җәлил “Алтынчәч” либреттосында бик матур чагыштырулар, эпитетлар, метафоралар кулланып, метонимия, гипербола, сынландыру кебек сурәтләү чараларыннан гаять отышлы файдалана, алар ярдәмендә әсәрнең телен баета, матурлата.

## ӘДӘБИЯТ ИСЕМЛЕГЕ


1. Арсланова С. М. Җәлилнең "Алтынчәч" һәм "Илдар" либреттоларының лексик-семантик, стилистик үзенчәлеләре һәм поэтик ономастикасы (текст) / С.М.Арсланова: Филол. фән. Канд...дис. - Казан, 2004.

2. Вәлиева Р. Шагыйрь турында җыр: поэма: урта һәм олы яшьтәге мәкт. балаларына/ Р. Вәлиева. - Казан, 2006. – 210 б.

3. Ибраһимов. С.И. – Казан: Таткитнәшр., 2008. – 150 б.

4.Курбатов Х.Р. Сүз сәнгате: Татар теленең лингвистик стилистикасы һәм поэтикасы Х.Р.Курбатов. - Казан: Мәгариф, 2002. – 199 б.

5. Нуриев Р. Сәнгатьле уку: Методик ярдәмлек / Р.Нуриев. - Казан: Мастер Лайн, 2000. – 152 б.


Назад

## Мөхетдин Корбангалиевнең татарларда аваз методын фәнни нигезгә салудагы эшчәнлеге


*Шәйдуллина Фәнүрә Миншәеховна, Заһирова Гөлназ Миннәхмәтовна*
*татар теле һәм әдәбияты укытучылары*
*Казан шәһәре, ДАҺБУ “Казан педагогия көллияте”*


Мөхетдин Корбангалиев – татар мәгариф фронтының, бигрәк тә аның совет чорындагы иң күренекле вәкилләренең берсе. Аның 1912 елда басылып

чыккан беренче әлифбасыннан башлап 1945 елга кадәрге әлифбалары белән берничә яшь буын укырга-язарга өйрәнде. Яшь буын дию генә дә төгәл булмас. Чөнки авторның зурлар өчен төзелгән әлифбалары да берничә. Алар наданлыкны бетерү елларында халыкка шулай ук зур хезмәт күрсәттеләр.

Октябрь революциясе алдыннан иҗат ителгән башлангыч дәреслекләр арасында аның “Татар әлифбасы” күренекле урын тота. Бу әлифба 1912 елда чыга.

Мөхетдин ага әлифбалар авторы гына түгел. Ул башка фәннәрдән дә бик күп дәреслекләр яза. Әлифбасы белән  бер чорда, хәтта аннан элегрәк, аның “Хисап мәсьәләре һәм гадәти мисаллар”(I – II – III кисәк), “Дөнья җәгърафия рисаләсе” (I – II кисәк), “Татарча уку китабы” (I, II, III китаплар) исемле дәреслекләре басылып чыга һәм алар революциягә кадәр башлангыч мәктәпләрдә кулланылып килә.

Татар алфавитын камилләштерүгә, телебезнең имласын (орфографиясен) эшкәртүгә Мөхетдин ага шулай ук гаять күп көч сала.

М.Корбангалиев үзенең башлангыч укыту дәреслеген “Татар әлифбасы” дип атый. Мондый исем әлифбалар тарихында әле беренче тапкыр очрый.

1910 еллардан башлап, ул татар алфавитына 10 сузык хәреф кертү тарафдары булып китә. Гыймад Нугайбик белән бергәләп, шушы максатка ирешү өчен туктаусыз көрәш алып бара. Алар алга куйган максатларына тик 1929 елда гына, латин графикасына нигезләнгән яңа алфавит кабул ителгәч кенә ирешәләр. Мөхетдин ага “Татар әлифбасы”на кереш сүзендә (1912) башка авторларны сузык авазга бер хәреф алырга, ишетелгәнчә язарга чакыра. “Һәрбер мәдле тавышка бер хәреф (галәмәт) алып әлифбаларымызны тәкмил итү (хәрефләребезне камилләштерү. – Ф.И.) бик лазем... Ансыз безнең әлифбаларымыз да вә имламыз да төзәлми, ә бәлки көннән-көн артык чуалачаклардыр... Сүзләремез ишетелгәнчә язылсалар, имламыз да шиксез җиңеләер вә берләшер иде һәм балаларымызга зәвык вә ихлас илә укырга зур сәбәп булыр иде”,  - ди ул [2, 116 б.].

М.Корбангалиев үзенең әлифбасын аваз методы белән төзи.

1918 елга кадәр “Татар әлифбасы” 7 тапкыр басылып чыга. Автор үзенең әлифбасын басмадан – басмага камилләштерә бара. Икенче басмасында, мәсәлән, имласын яхшырту белән бергә, мисалларын ишәйтә төшә. Өченче басмада әлифбага рәсемнәр урнаштыру өстенә, күп урыннарын яңадан төзәтеп, мисаллар арттырыла. Бишенче басмада хәрефләрнең дүрт төрле язылышы урынына ике төрле (баш һәм урта) язылышын гына ала. Җиденче басмасында язу күнегүләре кертә, авазлары бер-берсенә якын булган хәрефләрнең тәртипләрен алмаштырып, аны өр яңадан эшкәртә. Аның имласы Бөтенроссия мөселман укытучыларының I съездында (1917 ел, август) кабул ителгән имлага туры китерелә.

М.Корбангалиев укырга – язарга а, з, р, с, к, л, м, н кебек яңгыравыклы, хәтердә тиз калучан, бала лексикасында ешрак кабатлана торган авазларны (хәрефләрне) һәм сүзләрне өйрәтүдән башлап җибәрә. Моңа кадәр чыккан күп кенә әлифбаларда очрый торган аңлаешсыз сүзләр бу әлифбада бөтенләй юк. Сүзләр бик гади, баланың күңеленә бик якын, һәр дәрестә бер хәреф күрсәтелә дә, уку күнегүе итеп, моңа кадәр өйрәнелгән хәрефләрдән төзелгән бер яки ике иҗекле сүзләр бирелә. Күнегүләр башта эре хәрефләр белән күрсәтелә, соңга таба ваграк хәрефләргә күчелә. Беренче басмасында әлифбага Г.Тукайның “Елның дүрт фасылы” шигыре генә кертелсә, соңгы басмаларда, Г.Тукай шигырьләреннән тыш, С.Рәмиев (“Уку”), М.Гафури (“Укуга өндәү”), М.Укмасый (“Яз башы”) һәм башка шагыйрьләрнең дә шигырьләре урнаштырыла. Уку өчен китерелгән текстлар, җиңел булу белән бер үк вакытта, танып-белү ягыннан да бик әһәмиятле. Табышмак һәм әйтемнәрнең дә булуы әлифбаны уку өчен кызыклы ясый. Соңгы басмалардагы грамматик биремнәр балаларның активлыгын, мөстәкыйльлеген арттырырга, сөйләм телләрен үстерергә ярдәм итәләр.

Автор әлифбасының беренче басмасыннан ук балаларга белем генә түгел, дөньяви тәрбия бирү бурычын да куя.

“Татар әлифбасы” – революция алды елларында татар мәктәпләрендә киң таралган әлифба. Бу әлифбаның кыска вакыт эчендә шулай абруй казануына,

билгеле, аның 1915 елда, Уфада, дәреслекләр сайлау өчен җыелган киңәш мәҗлесендә тикшерелеп, мәктәпләргә куллану өчен тәкъдим ителүе дә сәбәп була.

М.Корбангалиев 1912 елда “Гавам мәктәбе татар әлифбасыны тәгълим өчен бәгъзе тәнбиһат вә дәресбирү нәмунәләре” (халык мәктәбе өчен чыгарылган татар әлифбасын укыту өчен кайбер киңәшләр һәм дәрес бирү үрнәкләре. – Ф.И.) һәм “Мөтәхәррик әлифба” да (күчмәәлифба) бастырып чыгара. Боларның укытучылар өчен әһәмияте гаять зур була. Алар “Татар әлифбасы” белән эшләүне бик нык җиңеләйтәләр һәм фәнни нигезгә куярга ярдәм итәләр.

“Дәрес бирү нәмунәләре”, башкача әйткәндә, дәрес эшкәртмәләре, 1918 елда кайбер өстәмәләр белән кабат басыла (икенче басма), бу хәл аның укытучылар арасында киң кулланылуы турында сөйли.

“Дәрес бирү нәмунәләре”нең беренче абзацыннан ук автор укырга-язарга иске методлар белән өйрәтүне каты тәнкыйть астына ала. “Борынгы заманда , - ди ул, ысулы хәрфия белән укыту заманнарын күз алдында тотып, - укытучы да һәм ата-аналар да балаларын укырга тизрәк өйрәтү ирадәсе (теләге. – Ф.И.) белән тугрыдан-тугры укытырга башлаганнар. Безнең иске мәктәпләремездә балаларга әвәлге көндә үк хәрефләрнең исемнәрен һәм шәкелләрен ятлатырга керешкәннәр. Ләкин бу эш тәгълим вә тәрбия фәненә хилаф булганлыктан хәзер бөтенләй ташланып бара” [2, 118 б.].

Дөрес, безнең методик әдәбиятта аңа кадәр дә әлифбагача чор дәресләре кертү кирәклеген күтәреп чыгучылар була. Алардан аермалы буларак, М.Корбангалиев аны фәнни яктан нигезли. Үзенең укыту тәҗрибәсенә таянып, ул балаларны мәктәпкә килгән көннән үк укырга-язарга өйрәтү эшенә керешү практикасына каршы чыга. Атаклы рус педагогы К.Д.Ушинский өйрәтүләрен яклап, беренче сыйныфка Мөхетдин ага килгән балаларны әлифба укыта башланганчы бераз әзерләргә кирәклекне алга сөрә. Чөнки мәктәп бусагасыннан беренче тапкыр атлап кергән 7-8 яшьлек баланың дәрес тыңларлык халәте булмый, игътибары җитми, аларның юашраклары куркып,

каушап кала. М.Корбангалиев балаларны мәктәп тормышы белән таныштыру вакытын “Керешү дәресләре” дип атый. 1912 елда ук “Керешү дәресләре”н икегә бүлә: 1) башта укытучы балаларны укырга әзерләү өчен сүздәге авазларны аера белергә өйрәтә, әңгәмәләр үткәрә, 2) язуга әзерләү өчен сызыклар сыздыра.

1918 елда чыккан икенче басмада ул “Керешү дәресләре”н, Галимҗан Ибраһимов кебек, өчкә бүлә. Бу дәресләр, - ди ул – балаларны максатыбыз булган укыту һәм яздыру эшенә керешергә эзерләп, өчкә бүленәләр: 1) башлау дәресләре, 2) әзерлек дәресләре, 3) әлифба укыта башлау дәресләре.

Автор шушы өч төрле дәресне оештыру методларына бәйнә-бәйнә туктала. Татар методик әдәбиятында беренче буларак, ул әлеге мәсьәләне җентекләп эшкәртә.

1.**Башлау дәресләре** укытучы белән балалар арасында кара-каршы сөйләшү рәвешендә алып барыла. Шушы вакытта балалар мәктәп җиһазлары, укыту әсбаплары, тәртип кагыйдәләре белән, укытучы исә, үз нәүбәтендә, укучыларның табигате, үзенчәлекләре, фикер йөртү һәм зиһенгә алу дәрәҗәләре белән таныша. Боларга түбәндәгеләр кирә: мәктәпкә кайчан килергә, мәктәптә дәрес һәм тәнәфес вакытында үзеңне ничек тотарга, укытучыларың һәм иптәшләрең белән нинди мөгамәләдә булырга, китап, такта, каләм, грифель, карадан ничек файдаланырга, кирәкмәгән вакытта аларны кая куярга, кирәксә ничек алырга, партада ничек утырырга, урыныңнан ничек тавышсыз торырга. Менә бу гадәтләргә, ди күренекле педагог, балаларны укытучы ачуланмыйча сабыр гына, даими өйрәтергә тиеш.

2.**Әзерлек дәресләрендә**балаларны укырга-язарга өйрәтергә әзерлек башлана. Әзерлек дәресен Мөхетдин Корбангалиев, К.Ушинский кебек икегә бүлә: а) язуга әзерлек, б) укуга әзерлек дәресләре.

а) **язуга әзерлек дәресләрендә**укытучы балалардан башта төрле-төрле сызыклар сыздыра, соңга таба шакмаклы сызыклар өстенә гади генә төрле (тәрәзә бүлемнәре, өчпочмаклы, дүртпочмаклы һәм күппочмаклы) шәкелләр

ясата. Болар балаларны хәрефләрнең аерым өлешләрен язарга әзерли, чөнки язуның нигезендә хәреф ята.

б) **укуга әзерлек дәресләрендә**балалар иң элек авазлар белән таныштырыла, чөнки укуның нигезен аваз тәшкил итә. Укытучы иң элек җөмләне сүзләргә аерттыра, моның өчен ул ике, өч, дүрт сүзле җөмләләр ала да башта үзе, сүз араларында бераз тукталып, ачык итеп укып күрсәтә. Соңыннан шул ук җөмләләрне укучылардан кабатлата һәм һәр җөмләдә ничә сүз булуын сорап бара.

Балалар әйтелгән җөмләләрнең ничә сүздән торуларын аңлагач һәм сүзләрдән җөмлә ясый белгәч, сүзләрне авазларга бүлдерү башлана. Хәзерге җөмләнең мәгънәсе укучыларга әйтелми, сүз белән аваз турында гына аңлатырга тырышыла. “Авазны белми торып, - ди автор, - әлифба башлау һич мөмкин түгел; ничаклы озакка сузылса да, хәзерлек дәресләрен ясарга һәм авазны аңлатырга кирәк” [2, 120 б.].

Автор “Керешү дәресләре”нә билгеле бер вакыт билгеләми. Димәк, һәр укытучы, классның мөмкинлегеннән чыгып, моңа күпме вакыт китәсен үзе билгели. Әмма әлифбагача чор дәресләренең төп максаты ачык: балалар шушы вакытта сүз һәм авазларның нәрсә икәнен аңларга тиешләр.

3. **Әлифба укыта башлау дәресләре.** Мөхетдин Корбангалиев “Дәрес бирү нәмунәләре”ндә дүрт дәреснең барышын язып күрсәтә.Дәресләрне ул, гомумән түгел, үзенең “Татар әлифбасы”н укыту өчен эшкәртә.

М.Корбангалиев әлифба укыту өчен генә түгел, гомумән башлангыч мәктәпләр өчен күп методик китаплар һәм мәкаләләр яза, үзенең бай тәҗрибәсе белән уртаклаша. 1913 елда “Мәктәп” журналында аның мәкаләләре басыла. Уфадагы мәҗлестә кайбер әлифба китапларына анализ ясап доклад белән чыга. Ул “Яхшы әлифба нинди булырга тиеш?” – дигән сорау куя да, үзе үк моңа җавап бирә: 1) әлифба татар теленә муафикъ булсын, ягъни телебездә ничаклы аваз булса, шул кадәр үк хәреф тә булырга тиеш. Шунсыз әлифбаларыбыз мөкәммәл булмаячак. 2) Әлифбаның материалы баланың акылын эшләтердәй эзлекле булсын.Бу әсасдан әлифбаның ысулы

саутия белән тәртип кылынуы кирәк. Чөнки ысулы мәддия белән төзелгән әлифба баланың акылын эшләтми, бала мөгаллим әйткәнне ятлап кына бара. 3) Әлифбада мәгънәсез, шулай ук балалар аңламастай чит сүзләр булмасын. 4) Әлифбаның материалы баланың рәгъбәтен (омтылыш- кызыксыну. - Ф.И.) җәлеп итеп,аны дулкынландырырдай булсын. Моның өчен әлифбага мөмкин кадәр балаларның аңына муафикъ булган мәкальләр, табышмаклар, әйтемнәр, хикәя вә шигырьләр кертелергә тиеш, - ди ул [2, 120 б.].

Тәҗрибәле педагогның бу таләпләре коры декларация генә булып калмыйлар, ул аларны үзенең хезмәтләрендә тормышка ашыра. Без моны аның берничә ел буена язылып килгән һәм 1918 елда басылып чыккан "Ана теле методикасы" исемле шактый күләмле хезмәтендә бик ачык күрәбез.

М.Корбангалиевкә кадәр дә әлифба укыту методикасын язучылар, аерым дәресләрне эшкәртүчеләр булмый түгел, була. Әмма ул хезмәтләрдә гомумиләштерү җитәрлек түгел, алар аваз методының йә аналитик, йә синтетик төре белән укытуны бәян итәләр. М.Корбангалиев исә үзенең эшкәртмәләрендә аваз методы белән татарча укырга-язарга өйрәтүнең тулы системасын эшли, аны фәнни нигезгә сала.

КУЛАНЫЛГАН ӘДӘБИЯТ ИСЕМЛЕГЕ

1. Гайнетдинов М.Л. Татар халык педагогик культурасының чыганаклары һәм тарихи үсеше. – Казан, 2004. – 36 б.

2. Ибрагимов Ф.И. Белем әлифбадан башлана. – Тулыландырылган, яңартылган басма – Казан: Мәгариф, 1994. – 116 б.

3. Рашитов Ф.А. История татарского народа. – Саратов, 2001.

Назад

## Минем уйлануларым

*Шәймарданова Мәүлүзә Касыйм кызы,*
*Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы 1нче урта гомуми белем мәктәбенең татар теле һәм әдәбияты укытучысы*

*"Кешене иң бөек дәрәҗәләргә җитештергән һәм исемнәрен соңгы буын кешеләргә калдырган нәрсә-гыйлемдер. Укытучы – гыйлем өйрәтүче, дәрес укытучы һәм балаларның җаннарын тәрбияләүче дип атала".*

*(Ризаэддин Фәхреддин)*

Үсеп килүче буынга акыл-тәрбия бирүдә, аларны актив тормышка сәләтле шәхесләр итеп тәрбияләүдә, гаиләдән кала, икенче урында мәктәп тора. Укытучы, тирән гыйлемле булу өстенә, сабыр, күркәм холыклы, йомшак сүзле, шәфкатьле, әмма таләпчән дә булырга тиеш.Укытучыга,чыннан да, әйтеп бетергесез олы вазыйфа йөкләнгән. Укучыда остазына хөрмәт тәрбияләү, аның казанышларыннан хәбәрдар булуын тәэмин итү - монысы да нигездә мөгаллимнәр җаваплылыгында.

Мәгариф өлкәсендә алып барыла торган теләсә кайсы үзгәртеп кору чараларының үзәгендә дә укытучы тора. Педагоглар буларак,әлеге статус бездән үзебезнең эшчәнлекне кыска вакыт эчендә заман таләпләренә туры китереп яңача оештыра белү таләбен куя. Хәзерге заман мәктәбендә иҗади уйлаучы,белем бирүнең заманча методлары һәм технологияләре белән коралланган, үз эшенең соңгы нәтиҗәләрен ачык күзаллаучы мөгаллимнәр эшли.

Безнең мәктәбебез тарихына 176 ел. Мәктәбебез-рус.Татар теле һәм әдәбияты дәресләрен ике төркемдә алып барабыз. Бүгенге вәзгыять татар теле һәм әдәбиятын укытуды зур тырышлык сорый. Мәктәптә эшли башлаганнан бирле,мине дәресләрне ничек итеп ярattырырга дәгән сорау борчый.Без балаларга татар телен өйрәнүдә бик зур таләпләр куярга өйрәнгәнбез,башта өйрәтергә,аннан гына таләп итәргә кирәк. Теләп башкарылган эш кенә истә кала,баланын аңын үстерә.Материалны үзләштерү кызыклы һәм уңайлы булса гына укучының күңеле үсә,тел өйрәнергә теләге арта.Мин үзем күбрәк рус телле балаларга татар теле һәм әдәбияты дәресләрен бирәм. Әлеге фәннәрне өйрәтү гаять дәрәҗәдә тырышлык,иҗадилык таләп итә. Төп сәбәп-рус телле укучыларның тел өйрәнү белән кызыксыну дәрәҗәсенең һәм бүгенге балаларның гомумән белем алуга карашының төрлелегендә. Шунлыктан, безгә –ана теле мөгаллимнәренә эзләнергә, уйланырга һәм дәресләрне укучы игътибарын җәлеп итәрлек итеп уздырырга омтылырга кирәк, дип саныйм. Бала синең фәнне яратсын,аңа тартылсын өчен,син аны- укучыны үз ит,

баланы кайгыртучы олы җанлы шәхес тә, аны төрле фәнни ачышларга алып керә алучы галим дә ,кирәк чакта ярдәм кулын сузарга әзер торучы дус та син икәнлегеңне расла.

33 ел буе балаларны укыту дәверендә мин үткән педагогик юлымны уйлыйм да үз-үземә шундый сорау куям. Без бит белем биреп кенә калмыйча,белем сыйфаты турында да уйларга тиеш,чөнки белем сыйфаты-милли үзаңны, мәдәниятебезне күрсәтә торган критерийларның берсе. Һичшиксез,укытучы һөнәрен сайлаган кешегә иң элек табигать сәләт биргән. Шуңа өстәп,тирән белем,сабыр холык һәм тагын шундый үрнәк сыйфатлар...

Укытучы дигән бөек, кирәкле һөнәрне сайларга миңа, беренчедән,туган авылым- Аксарда белем биргән ачык йөзле,киң күңелле,олы йөрәкле мөгаллимнәрем тәэсир иткәндер, диеп уйлыйм. Без укучы вакытта безгә шәхес итеп карап,уңышларыбызны,мөмкинлекләребезне күреп,сәләтне үстереп,үз фәннәренә карата мәхәббәт уята белде алар.

Татар теле һәм әдәбияты укытучысы буларак, белем бирү сыйфатын тагын да яхшырту һәм камилләштерү,уку-укыту барышында яңа технологияләрне,шул исәптән мәгълүмати технологияләрне куллану-иң төп максатларның берсе булып тора.

Һәрбер фән методикасының үзенең эчтәлеге, системасы, өйрәнү объекты һәм тикшеренү методлары, исбатлау алымнары бар. Билгеле бер шартларда аларның нәтиҗәлерәк булганнарын сайлап ала белергә генә кирәк. Укытучы эш процессында дөрес юнәлеш алырга тиеш. Бу очракта ул үзенең методик ялгышларын төзәтә һәм тупланган методик базадан иҗади файдалана алачак.

Укыту методларын билгеләгәндә һәм материал сайлаганда, укучыларның яшь аерымлыкларын да, материалның укучыларга аңлаешлы булуын да исәпкә алып эш итәргә кирәк. Укытучы барыннан да элек түбәндәге сорауларга җавап бирә: ничек, нәрсәне, һәм күпме өйрәтергә? Ни өчен шулай өйрәтергә, ә башкача түгел?

Телгә укыту методикасы дәресләрдә һәм дәресләрдән тыш чараларда аңлы һәм белемле укучылар тәрбияләүне игътибар үзәгенә куя. Шуңа күрә

укытучы дәрес өчен материал сайлаганда, аның укучыга төрле яклы тәрбия бирерлек икәнлеген күз алдында тота. Бирелә торган материалны өйрәтергә керешкәнче, укытучы укучыларны аны тыңларга әзерли. Моның өчен укучылар алдына төрле кызыксындыру сораулары куя. Укучыларда кызыксыну уяна, алар төрлечә җавап бирергә омтылалар һәм, шулай итеп, аларда дәрестә бирелә торган материалны өйрәнү теләге арта.

Укыту барышында укытучы психологик күзәтүләр дә алып бара, чөнки аның өчен укучылардагы үзгәрешне өйрәнеп тору мөһим. Дәрес – мәктәптә укыту-тәрбия процессын оештыруның төп формасы. Ул процесс – укытучы һәм укучының бердәм-эзлекле эшләве.

Дәресләрне ничек оештырырга кирәклек турында төрле карашлар булды. Шулай да укучы актив эшләгән, укытучы аның активлыгын оештыра алган дәресләр генә нәтиҗәле була ала.

Дәрес үткәрү укытучыдан яшь һәм класс үзенчәлеген истә тотуны да, мәгълүмати технологияләрнең тулы җыелмасыннан файдалана алуны да, үз эшенә иҗади якын килүне дә таләп итә. Дәрес күңелле һәм файдалы үтсен, нәтиҗәле булсын өчен, укытучыга уйланырга, дәреснең төп ысул һәм алымнарын алдан билгеләргә, эзләнергә кирәк.

Хәзерге заманда һәрбер мәктәп, һәрбер укытучы үз йөзен булдырырга, мөстәкыйль, иҗади шәхес үстерергә тырыша. Шәхеснең камилләшү һәм үсүендә әхлак тәрбиясенең әһәмиятен педагогика элек-электән исбатлап, раслап килгән. Әле борынгы грек философы Сенека ук: “Гыйлемлелектә алга китеп тә, әхлак ягыннан артта калган кеше алга китүдән дә бигрәк артка калып яши”, - дигән гыйбәрә әйткән. Мәгълүм ки, кешедә әхлаклылык, намуслылык сыйфатларын формалаштыру – катлаулы бурыч.

Методик алымнар һәрдаим үзгәреш кичереп торалар. Яңа методлар кулланганда махсус дәресләр үткәрелә. Аннан соң бу алымның нәтиҗәле була алу-алмавы тикшерелә, нәтиҗәсе элек кулланылган метод һәм алымнар белән чагыштырыла. Бу эш укытучының методик базасын баетырга ярдәм итә.

Бүгенге мәктәп укытуда ятлау һәм формализм белән килешә алмый. Лланып эшләүне күздә тота.Ул дәресләр нәтиҗәле,укучылапга кызыклы булсын өчен, укытучы үз дәресләрен укучыларны дәрескә алып кереп китә алырлык итеп оештырырга тиеш. Һәр дәрес аша укучынычын мәгънәсендәге югары идеаллы Кеше итеп тәрбияләүне онытмаска тиеш. Яңа Федераль дәүләт стандартлары да укучыларда шәхескә кагылышлы универсаль уку гамәлләрен формалаштыруны алгы планга чыгара. Дәрес эшкәртмәләребез эш төрләренә һәм метод-алымнарга бай булырга тиеш:әңгәмә,презентация карау, өлешчә-эзләнү, фикер алышу, төркемнәрдә эшләү һәм башкалар. Шуңа өстәп, ана телен укыту методикасы яңа эш төрләрен, яңа технологияләрне ку әдәбияты укытучысының үз алдына куйган бурычлары түбәндәгедән гыйбарәттер, дип уйлыйм мин:

-татар теле һәм әдәбиятыбуенча фәнни белемнәрдән хәбәрдар булу;

-белем бирүнең яңа методик алымнарын.ысулларын куллану;

-максатка ярашлы методиканы һәм методика технологияләрен сайлап алу, үзеңнең методик осталыгыңны камилләштерү;

-әлеге фәннәр буенча төрле типтагы һәм формадагы дәрес үткәрү күнекмәләрен үзләштерү һәм аларны куллану;

-яңа мәгълүмати технологияләрне курыкмыйча куллану.

Әгәр укытучы дәресләрне иҗади якын килеп, төрле метод һәм алымнар кулланып үткәрсә, эшне төрлеләндерсә, төрле авырлыктагы күнегүләр һәм иҗади эшләр эшләтсә, шулай ук төрле күрсәтмә әсбаплардан файдаланып, өйрәнә торган материал белән кызыксындырса, укучының активлыгы үсә, ул дәресне аңлы рәвештә үзләштерә һәм белеме дә ныклы була.

Укытучы эше – иҗади эш. Үз эшендә ул төрле методик алымнарны куллана, укыту процессында аларны үзгәртә, тулыландыра, иҗади файдалана ала.

2017 нче ел милләтебез, телебез һәм аеруча милли мәгариф өчен авыр сынау елы булды. Ана телен өйрәнү мәсьәләсе, мәгариф системасы, кысаларыннан чыгып,киң җәмәгатчелек фикеренә тапшырылды,хөкүмәт

Дәүләт Думасы дәрәҗәсенә менде, милли мәгариф өлкәсендә хәл ителәсе бик күп проблемаларны ачып салды. Ана телен сайлау мөмкинлеге чыкса да, безнең мәктәбебезнең әти-әниләре балалары белән берлектә татар телен сайладыдылар. Билгеле, бу - мәктәп җитәкчелегенең һәм без-укытучыларның уртак эш күрсәткече. Телне дәресләрдә генә өйрәнеп бетереп булмый. Мәктәп тә тел мохите тудыру, туган телне саклау һәм үстерү юнәлешендә кызыклы чаралар оештырырга кирәк,дип саныйм. Галимнәр, язучылар, сәхнә йолдызлары белән очрашулар, балаларның үзләрен дә сәхнәгә тарту, аларга җаваплылык биреп, үзләренә дә тәкъдим белән сыгарга мөмкинлек бирү-болар өчен бернинди киртәләр юк,җиң сызганып эшләргә генә кирәк.

Бала туган телендә сөйләшсен өчен,татар теле һәм әдәбияты дәреслекләре белән генә чикләнергә ярамый. Татар теле һәм әдәбияты атналыкларында татарча хатасыз язылган элмә, мәгълүмат такталарын, эш кәгазьләрен; мәктәп күләмендә оештырылган чараларны ике телдә алып бару, әти-әниләр катнашында әдәби кичәләр, милли уеннар, шигырь бәйгеләре, театр көннәре үткәрү һәм башка күп юнәлешләрдә татар теленә юл бирү. Һәрдаим мәктәп җитәкчеләре, мөгаллимнәр, әти-әниләр белән бергә кулга-кул тотынып эшләгәндә генә, туган телебезне, гореф-гадәтләребезне саклап кала алабыз.

Заман бездән көннән-көн яңа технологияләр кулланып, яңача эшләүне таләп итә. К.Д.Ушинский мең кат хаклы: “Укытучы үзе өйрәнгәндә генә яши”- дигән ул да, яңаны өйрәнүдән туктамаска өндәп.

Заман алга бара... Ләкин УКЫТУЧЫ һөнәре җир йөзендә иң гүзәл һөнәрләрнең берсе булып кала бирә.

Ана теле укытучысы чираттагы дәресен бирә... Ул илебезнең киләчәген кайгырта,ил һәм милләт гаме белән яши, шәхси тормышын мәктәп тормышыннан аерылгысыз итеп күрә. Мәгариф системасында барган һәртөрле яңарышлар чорында, укытучы укытып кына калмый, ә заманга яраклы шәхес тә тәрбияли. Ә инде укытучы һөнәренә игътибарның артуы аның күңелендә киләчәккә ышаныч уята.

КУЛЛАНЫЛГАН ӘДӘБИЯТ ИСЕМЛЕГЕ:

1.З.Габдинова: «Татар теле укытучысы-заман укучысына».-Казан: «Мәгариф» журналы.-2020.-№9-12-14нче битләр.

2. Р.З.Хәйдарова, Г.М.Әхмәтҗанова, Л.Ә.Гыйниятуллина:Рус телле балаларның «Татар теле» предметы буенча белү күрсәткечләре 1әм аларны тикшерү биремнзәре: укытучылар өчен кулланма. Казан: ААҖ «Фолиант» нәшрияты, 2019.-3-5 нче битләр

Назад

## Халыклар дуслыгы – әдәбиятлар дуслыгы (Зариф Бәшири иҗатында милләтара дуслык темасы“Чуаш кызы Әнисә” мисалында)

*Шайхатарова Эльмира Гафурҗан кызы,*
*ДАББУ “Минзәлә авыл җуҗалыгы техникумы”,*
*татар теле һәм әдәбияты укытучысы*

Халыклар дуслыгы — тарихи төшенчә. Тарихтагы катлаулы һәм каршылыклы вакыйгалар, билгеле сәбәпләр аркасында тудырылган дошманлык һәм бер-береңне аңларга теләмәү дәверләре аша, гасырлар дәвамында, бик зур авырлыклар белән, әкрен-әкрен генә тернәкләнеп килә ул дуслык чәчәге һәм уртак гамь белән яшәүче миллә тләрнең күңелендә үзенең тамырларын тирән җәя.

Татар иле – күп төрле милләтләрне сыендырган, татар, рус, чуаш, мари, удмурт, мордва кебек гасырлар дәвамында шушы җирлектә яшәүче милләт вәкилләрен канаты астына алган җир. Сер түгел, Татарстан халыклары үзара бәйләнешләр нәтиҗәсендә, тел, мәдәният һәм башка өлкәләрдә бер-берсенә йогынты ясап, күркәм тормыш итәләр. Аларның киләчәккә омтылышлары, уй-хыяллары бер-берсенә охшаган кебек. Татар шагыйре Һади Такташ үзенең шигырендә:

“... нинди охшаганбыз,
Ничек охшаганбыз,
Бертуганнар дисәң,
Мин – Тамбовтан, ә син –

Казан артыннан,

Мин бер мишәр улы, кыргый үскән,

Ә син

Күрше чуаш халкыннан...”  дип язган.

Татар әдипләренең әсәрләрендә халыклар дуслыгы темасы даими яктыртыла. Тулы бер әсәрнең үзәк өлешен биләмәсә дә, әдәби мирасның шактыенда милли дуслык, бердәмлек, Рәсәй халыкларының бердәм булып дус атлавы каләм ияләре тарафыннан игътибар үзәгеннән читтә калмый. Бу тема Бөек Ватан сугышы чорын яктырткан әсәрләрдә киң чагылыш таба. Сүз дә юк, Ватанны саклау өчен барган изге көрәштә алгы планда бердәм совет халкы торды. Милләтләр бердәмлеге бу чорны яктырткан  М.Юныс  “Шәмдәлләрдә генә утлар яна”, Н.Дәүли  “Җимерелгән бастион”, “Яшәү белән үлем арасында”, Ш.Рәкыйпов “Кызлар – йолдызлар”, Т.Гыйззәт “Төнге сигнал”, “Изге әманәт”, Л.Ихсанованың «Лачын кыз» һәм башка  күп кенә каләм ияләренең әсәрләрендә үз урынын тапкан.  Моннан тыш, төрле чорларда язылып, тормышның башка якларын  сурәтләгән әсәрләрдә дә халыклар бердәмлеге, дуслыгы темасы  читтә калмый. 20 гасыр башында да  язучылар бу теманы читләп узмаганнар. Моңа мисал итеп Ф.Әмирханның “Хаят”ын китерергә мөмкин. Хәзерге чор әдәби үрнәкләреннән булган А.Хәлимнең “Хунвейбин” эпопеясе, Р.Зәйдулланың “Ильяс Алкинның соңгы мәхәббәте” ендә дә безнең тарафтан телгә алынган темага урын бирелгән.

Ерак тарихның кайбер сәхифәләрен генә актарып караганда да,  ачык күренә: бу дуслык турында гасыр башында ук татар әдәбияты классигы Габдулла Тукай әйткән сүзләрдә гаҗәеп зур хаклык бар икән:

*Рус җирендә без әсәрле, эзле без,*

*Тарихында бер дә тапсыз көзге без.*

*...Һич бетәрме тарихи бу бергәлек? —*

*Без туган бер җепкә бергә теркәлеп.*

Урта Идел буе җирләрендә яшәгән халыкларның тарихи берлеге, гасырлар дәвамында бердәм атлаулары Тукайның замандашы язучы, шагыйрь, публицист Зариф Бәшири иҗатында да киң яктыртыла.

Егерменче йөз башында татар көндәлек милли матбугаты барлыкка килгәннән соң әдәбият мәйданына күтәрелеп чыккан дистәләрчә яңа исемнәрнең күренеклеләреннән берсе – шагыйрь, язучы-прозаик, мәгърифәтче – педагог Зариф Бәшири. Зариф туып–үскән авыл - Чүти (хәзерге Кайбыч районыны керә) – тау ягының Гөбенә елгасы буена урнашкан һәм Казан ханлыгы чорыннан ук билгеле зур авыл булып, тирә-ягында чуваш авыллары да күп булганлыктан, төбәк халкы милли яктан бер-берсе белән якыннан аралашып, “тел-лөгать алмашып” яшәгән. Шуңа күрә, булачак язучы балачактан ук чуаш телен һм гореф-гадәтләрен тирәнтен белеп үсә, һәм аның әдәби иҗатында да чуаш темасы аерым бер урынны били. Чүти авылы тагын шуның белән данлыклы: ул – халык арасында легенда рәвешендә сөйләнеп йөргән атаклы юлбасар Шәкүр Каракның туган авылы. Алай гына да түгел, бу Шәкүр Карак дигәне Зариф Бәширигә туган да туры килә: Зарифның ата ягыннан бабасы Таҗи хәзрәт белән Шәкүрнең анасы бертуганнар була. “Авылда мәчет салу, мәктәп ачу, мулла–мәзин кую, староста сайлау, җир бүлү, йорт урыннарын билгеләү кебек җәмәгать эшләренең һәммәсе дә Шәкүр Карак һәм шәкүрчеләр теләгән тәртип буенча йөртелә иде”, - дип искә ала З. Бәшири үзенең “Замандашларым белән очрашулар” исемле истәлек китабында. Чуаш, мишәрләр белән күрше булып яшәгән Зариф, аларның тормыш–яшәешләрен тирәнтен өйрәнеп, чуаш халкының шул замандагы тормыш хәлләре һәм гореф-гадәтләре турында Оренбургта чыккан “Шура” журналында берничә мәкалә дә бастыра, “Мишәрләр” дип исемләнгән публицистик әсәрен яза.

1910 елда язылган “Чуаш кызы Әнисә” повесте әдипнең иҗатында күренекле урын тота. Чуаш кызы Унисса (Әнисә) белән татар егетенең (Заркай) фаҗигале мәхәббәтен романтика катыш реалистик буяулар белән

сурәтләгән әлеге повесть, кат-кат басылып, соңыннан 1960 нчы елда чуаш теленә тәрҗемә ителә.

Зариф Бәшири беренчеләрдән булып татар халкын күрше милләт халыклары мәдәнияте белән таныштыра башлаган кеше.

Зариф Бәширинең туган авылы һәр яктан чуаш авыллары белән чорналган була, шунлыктан Зариф әфәндегә чуашлар белән еш аралашырга туры килә. Яшь чагында әдип Гөбенә суы буенда әтисенең яшелчә бакчасын каравыллаган. Шунда күрше чуаш авылы болыны каравылчысының улы Симук исемле малай белән дуслашып китә (без аны “Чуаш кызы Әнисә” повестенда да очратабыз. Семек - чуаш балалары арасында беренчеләрдән булып җәдитчә укыта торган мәктәптә белем алучы, киләчәккә зур өметләр белән караучы үсмер). Балачагында булачак әдип чуаш халкын белеп-күреп үсә, үз истәлекләрендә ул чуаш малайлары һәм кызлары белән уйнап йөрүләрен әйтеп уза.

Зариф Бәширинең Сәгыйть Рәмиев киңәше белән иҗат ителгән, беркадәр автобиографик характердагы “Чуаш кызы Әнисә” повестенда татар яшүсмере («мин») белән күрше чуаш авылының ятимә кызы Унисса (Әнисә) арасындагы самими дуслык күренешләре матур, тормышчан детальләр ярдәмендә тасвирланган. Повесть 1910 нчы елда басылып чыга, ләкин әсәр дөнья күргәч, авторга күп кенә үтенеч хатлары килә, укучылар бу әсәрне яңадан тулырак язуын үтенеп сорыйлар. “Бигрәк тә чуашларның үзләренә генә хас тормыш гадәтләрен киңрәк итеп күрсәтүемне үтенәләр”, - ди әдип, үзенең истәлек китабында [2 б.127]. Бу хатларны алганнан соң Зариф Бәшири әсәрен тулыландыра. Сюжет араларында чуашларның гореф-гадәтләрен, көнкүреш тормышларын, татар һәм чуаш халыклары арасында үзара җылы мөнәсәбәтләрен күрсәтә. Бу әсәр күрше булып яшәүче халыклар арасындагы көчле дуслыкны күрсәтүе белән кыйммәтле. Чуаш кызы образында хезмәт сөючән, яхшы күңелле, шаян табигатьле авыл кызы мәхәббәтенең вакыйгасы сурәтләнә.

Зариф ага үзенең тормышындагы мизгелләрне әсәрендә дә оста итеп гәүдәләндерә. Шундый бер вакыйганы искә ала: Зарифның әтисе үзенең Энәледәге дусты Васек дәдәйгә бара. Үзе белән улы Зарифны да ала. 10 яшьлек малайның авылга җитәрәк үк, күңелен шом биләп ала, тыны кысылып киткәндәй була. “Салам түбәле, тәбәнәк кенә өйләрнең агач стеналары кап – кара корымдай булып, каралып торалар”. [1,б.304] Үз авылыннан ерак китмәгән баланың башында сорау туа. Нишләп болар кара мунчаны шулай иң түргә салалар икән? Татарның бит мунчасы бакча артында, су буенда. Язучы татар һәм чуашларның яшәеш рәвешенә малай һәм аның атасы Шәрәфетдин мулла күзлегеннән бәя бирә. Өйгә керәләр. Өй уртасында мич янып тора. Аның морҗасы юк. Шуңа күрә төтен яртылаш ачып куелган ишектән чыга. Чүтидә күптән инде мондый мичләр булмаганлыктан, кечкенә Зариф моңа аптырап кала. Шунысы кызык: бу өйләрне “кара” өйләр дип түгел, ә “кар” өйләр дип атаганнар. Аларның мондый шартларда яшәвен Зарифка атасы мондый сүзләр белән аңлата: “Аларның наданлыклары морҗа чыгартмый. Әнә шул наданлык аркасында искелеккә теше – тырнаклары белән ябышып ятулары морҗалы мич чыгартып кеше төсле яшәргә ирек бирми. Ата – баба гадәтен ташларга ярамый диләр. Элек безнең бабаларыбыз да әнә шулай кара урман буйларында, шундый ук морҗасыз мичле, кара өйләрдә торган”. [1,б.305] Шәрәфетдин авызыннан чуаш халкының беркадәр артта калган яшәү рәвешенең сәбәбе шулай аңлатыла. Язучы үзенең бәянында чуашларның мондый сыйфатларына туктала: “Чуашлар, алар, тормышлары әшәке булса да, эчләре, намуслары белән пакъ халык. Алар урламый, хыянәт итми, ялган сөйләми, теләнчелек кылмыйлар. Алар бик эшчән халык, уңганнар. Соңгы вакытта укуга да бик нык ябышты. Менә күрерсең әле, унбиш – егерме елдан соң бездән дә аграк тормышлы булып китәрләр” [1,б.317]. Шулай итеп, Зариф Бәшири күрше милләтнең киләчәктә югарыга күтәрелүенә һич шикләнми. Бу чор мәгърифәтчелек тенденцияләреннән читләшмичә, милләтнең үсешен аның белем дәрәҗәсендә күрә.

Автор күрше булып гомер кичергән ике милләтнең дус,туганнарча иңгә иң куеп яшәүләрен әсәр дәвамында ассызыклый. Татар чуашка килеп, ипи һәм тоздан авыз итмичә китсә, чуаш өчен хурлык. Бер – берсенең гореф – гадәтләренә ихтирам белән карап, бәйрәмнәрдә йөрешәләр, бер чишмә суын эчәләр, күрше болында гына печән чабалар, татар чуашның сырасын, ә чуаш татарда чәен эчеп кайта.

Васек дәдәй гаиләсендә аның сеңлесе ятимә кыз Унисса тәрбияләнә икән. Бу кыз Зарифтан өч-дүрт яшькә кечкенәрәк, чем кара күзле, бик матур кыз була. Ләкин өсте-башы бик сәләмә. Зариф аны бик кызгана. Үзләренең өйләрендәге тормышны күз алдына китерә дә: "Әти, бу кызны алып китик әле?" – ди. Ләкин әтисе – Шәрәфетдин мулла – бу эшнең мөмкин түгеллеген, җитмәсә, әле бу кызның икенче диндә булуын аңлата. Зариф өйләренә кайткач та бу кызчыкны оныта алмый. Кечкенә чакта ук ул аны сеңлесе дип күз алдына китерә, үсә барган саен ул аңа хыялында гашыйк була. Аны сөеклесе итеп күз алдына китерә.

"Чуаш кызы Әнисә" повестен язганда менә шушы хыялларын эшкә җиккән дә инде ул. Әсәрнең үзәгенә нәкъ менә чуваш кызы образы алыну очраклы хәл түгел. Бу тирәдәге татарлар һәм чувашлар борын-борыннан шактый дәрәҗәдә «тел, лөгать, гадәт вә әхлак алмашып» яшәгәннәр. Бәшири дә боларны күреп, күңеленә алып үсә. Шуңа күрәдер дә әсәрдә чувашларның гореф-гадәтләре, традицияләре дә, ике халыкның үзара мөгамәләсе дә җылы буяулар белән белән сурәтләнгән.

Әнисә образы аша Энәле һәм Чүти халкының тормышын, гореф-гадәтләрен тасвирлый. Чуаш хатын-кызларының тырышлыгын, теләсә нинди авыр эш башкаруларын күрсәтә. Әсәрдә шулай ук тәрбия, әхлак, намуслык темасына да шактый урын бирелгән.

Әнисә белән Заркай арасындагы җылы мөнәсәбәт, дуслык еллар үтеп, чын мәхәббәткә әверелә. Кызганыч, бу дуслыкны заманасының кырыс чынбарлыгы, иске гореф-гадәтләр җимереп ташлый. Әнисә, агу эчеп, бу фани дөньядан китеп бара.

Зариф Бәшири чуашлар турында әсәрләр генә түгел, этнографик очерклар да яза, аларны китап итеп бастыра. Аның “Чуашлар” исемле хезмәте – егерменче йөз башы татар мәдәниятендә уникаль күренеш. Чөнки бу әдип беренчеләрдән булып чуашларны уңай яктан күрсәтә, аларның телләрен, гореф-гадәтләрен өйрәнә, борынгы ышануларын, әйтемнәрен язып чыга һәм татар теленә тәрҗемә итә. Зариф Бәширинең күрше халык әдәбиятын өйрәнүдә “Чуаш әдәбияты” дип исемләнгән беренче җыентыгы 1928 нче елда Казанда басылып чыга. Ул җыентыкта чуаш язма әдәбияты турында кыска очерк, чуаш әдипләренең шигырьләре һәм хикәяләре беренче тапкыр татарча дөнья күрә.

ӘДӘБИЯТ ИСЕМЛЕГЕ


1. Зариф Бәшири Сайланма әсәрләр: истәлекләр, бәян/ - Казан: Татарстан китап нәшрияты, 2014 - 430 б.

2. Зариф Бәшири “Замандашлар белән очрашулар”: язучы истәлекләре/ - Казан: Татрастан китап нәшрияты, 1968 – 292 б.


Назад

## Хисаметдин Исмәгыйлевнең “Никах” повестендә тел-стиль үзенчәлекләре


*Шаһиева Нәсимә Миргарифҗан кызы.*
*ДАҺБУ “Муса Җәлил исемендәге Минзәлә педагогия көллияте”татар теле һәм әдәбияты укытучысы.*


Язучы Х. Исмәгыйлевнең иҗаты белән “Казан утлары” журналы китапханәсе сериясендә басылып чыккан “Никах” китабы аша таныштым. Бу җыентыгына аның “Никах” һәм “Мин - Абрек” повестьләре кертелгән. “Никах” повестендә Әфганстанда хезмәт иткән солдат язмышы бирелә.

Шунлыктан Әфган илендә солдат тормышын ачу өчен кулланылган сүзләр шактый: *Ә теге* ***“старик”***, ***“дед”*** *дигәннәре күрше* ***казармаларда***.*(10 бит). Ярый әле аш булучы гадел* ***“черпак”(****бер ел хезмәт иткәннәрне шулай атыйлар) (11 бит).Таң алдыннан таулар арасындагы бер* ***кышлакка*** *килеп урнаштык(12 бит).Юлның ике ягында ватык, янган* ***БТРлар***, *“КамАЗ”лар аунап ята(13 бит).Тирә-як тауларда нинди үзгәрешләр була, кем килә, кем китә****”дух”лар*** *күренмиме – һәммәсен игътибарга алып тикшерергә икән.(15*

*бит). Кемнең чираты – шул **дозорда** тора.(15 бит). **“Шурави”** дип безне гади әфганлылар атыйлар иде бит (63 бит).*

“Чагыштыру – танып белүнең анасы”,- диләр. Һәр язучы үз әсәрләрендә табигатьне сурәтләгәндә бик теләп чагыштыруларга мөрәҗәгать итә. Чагыштырулар аша предметларның, күренешләрнең охшаш, аермалы якларын ачыклап була. Мәсәлән: *Безнең авылдагы иң зур исәпләнгән Мөгәзәй тавы бу таулар белән чагыштырсаң, **бер көрәк җир кебек кенә** булып кала(12 бит). Икенче ягында – текә таулар, **йә кеше башы әйләнерлек** кыялар. Тирә-яктагы таулар карап торуга гаҗәеп матур да, **сискәндерерлек** шомлы да (13 бит). Барыбыз да **күшеккән тавыкка охшап** калдык(24 бит). Шуңа да окоплар **сукыр тычкан оясын хәтерләтә** башлады(20 бит).*

Сынландырулар әсәрдә төрле максат белән кулланылалар. “Никах” әсәрендә автор тауларны, йолдызларны, солдатлар халәтенә хас сыйфатлар төрлелегендә сурәтли.

*Кайбер көнне тау йә **ыңгыраша**, йә **ухылдап көрсенеп куя**. Тик күктә йолдызлар гына, синең куркуыңны күреп, **чекерәешеп көлә** сыман (16 бит).*

Гади сөйләм сүзләре дә әсәрдә кулланылып, авторның әсәрдәге башка геройларга карата тискәре мөнәсәбәтен көчәйтә.

*Әмма теге дух йорт хуҗасын төртеп җибәрде дә тамак төбе белән каты итеп **җикерде** (25 бит).Командир **котыра**, йөзе кара көйгән(32 бит).Бөтенләй **җенләнде** (37 бит).Инсаф, гадәте буенча, бер яртыны **түңкәрде** дә гырлап йокыгы да китте.(56 бит).*

Х. Исмәгыйлев Башкортостан Республикасының Стәрлетамак районында яшәп иҗат итә. Шушы төбәккә хас сүзләр язучының әсәрләрендә дә урын алган.

*Егетләр болай **ару** гына күренә. Шуңа да взвод командирын **тәүдә** үк яратмадым. **Әмәлгә** калгандай, Әфганга бәйле һичбер нәрсә искә төшми (12 бит).Әллә нинди **берчә** куркыныч, **берчә** бик тә матур төшләр күрәм(48 бит)*

*Мин йә йоклап китәм, йә **исемне** югалтам(49 бит). Әмма иң гаҗәпләндергәне шул: мине коткарган малай госпиталь **ихатасы** алдында*

*һаман күренгәли икән(50 бит).**Теттереп** дөнья көтәләр(54 бит).Шулай күрше Әкълимә әбинең **тәпәш** ишеге кәсәгенә башны бәргәч, бер сәгатьтән артыграк аяксыз булып яттым(58 бит).*

Әсәрнең телен халыкчан, үтемле итүдә фразеологизмнарның өлеше зур. ***Шыр җибәрдем**, шулай да: ”Үлсәк, бергә үләбез инде , -дигән булам ( 63 бит).Минем **котым очы**, чәчләр үрә торды(28 бит).Дөнья **шау килә**(42 бит).Эчеп, бәйрәм итеп йөрер булсаң, үзем тотып**, арт сабагыңны укытам**, парень,- дип кисәтеп куйды(54 бит).*

Карап үтелгән мисаллардан күренгәнчә, Х. Исмагыйлевнең сүзнең көчен, тасвирлау мөмкинлекләрен тоеп, үзенә генә хас иҗат стилен тудырган, сүзнең үзенчәлекле мәгънә төсмерләрен тоеп сурәтләгән.

Назад

## Алынмалар белән чуарланган әдәби тел

*Юсупова Гөлнур Фаил кызы,*
*Зәй районы “Мансур Хәсән улы Хәсәнов исемендәге*
*Бигеш урта гомуми белем мәктәбе”нең*
*I категорияле татар теле һәм әдәбияты укытучысы*

Кечкенәдән, мәктәп укучысы булганда ук, теге яки бу сүзнең никтер бары русчасын гына куллануыбыз, татарчасын, гомумән, белмәвебез гаҗәпләндерә иде үземне. Аннары, институтта укыганда берәр рус кешесе янында рус сүзләре кыстырып сөйләргә ояла идем мин. Бүгенге көндә, телебезнең хәле, Рабит ага Батулла әйтмешли, чыннан да мөшкел. Әлбәттә, бу татар теленә генә түгел, ә рус теленә дә кагыла. Моны күреп торган минем йөрәгемә кан савып тора.

Тәнкыйтьче Э.Нигъматуллин: “Туган телебезне камил белеп, аны газиз анаңны зурлаган кебек зурларга, кадерләргә, халкыңны, иленне яратырга, аның өчен гомер буе армый-талмый хезмәт итәргә кирәк.”,- дигән иде.

Татар теле белемендә дә, рус теле белемендә дә лексикология тел берәмлеге буларак сүзләрне төрле аспектларда өйрәнә, мәсәлән: лексик мәгънәсен, килеп чыгышын, кулланылыш функциясен һ.б. Хәзерге

язучыларга, әдәби әсәр язарга алынганчы, әлеге аспектларны тирәнтен үзләштерергә кирәк.

Татар теле алынмалар белән чуарланган, үз сүзләребез инде калмаган да дигән фикерне ишетергә туры килә кайчак. Рус һәм башка телләрдәге сүзләрне никадәр еш кулланабыз соң?

Лексикологияне өйрәнгәндә исә гарәп-фарсы алынмаларының күплеге шаккаттыра. Дәүләт төзелеше, икътисад, сәясәт, мәгариф кебек өлкәләрдә татар сүзләре бөтенләй юк диярлек.

Хәзерге татар әдәби теленең сүзлек составы борынгы чордан ук яшәп килгән төрки халыкларның барысы өчен да уртак булган төрки тел сүзләре һәм нигездә гарәп-фарсы алынмаларыннан, шулай ук рус теленнән яки аның аша башка телләрдән кергән алынмалардан тора.

Хәзерге рус әдәби теленең сүзлек составы исә шулай ук бик борынгыдан яшәп килгән рус теленең үз сүзләре (исконно русская лексика) һәм башка телләрдән, нигездә грек (мәсәлән: баня, котёл, математика, философия, история, грамматика, стихи, комедия һ.б), латин (мәсәлән: агроном, академия, экзамен, экскурсия  һ.б), инглиз (мәсәлән: трамвай, митинг һ.б) һ.б. телләрдән кергән алынмалардан (заимствования) тора.

Алынмалар телебездә ныклап урнашып калганнар, татарлашканнар, яңа сүзләр ясау өчен нигез булып хезмәт итә башлаганнар. Әйтик, гарәп теленнән кергән *тәртип, ватан, хат, рәсем, сабыр, сер, сәгать, китап ,сәлам, алгебра, бәхәс, җавап, җөмлә ,мисал, дөнья, мәгънә, фикер, гади, галим, магазин, мәҗлес, гадәт* кебек сүзләрнең алынма икәне яшь буынга хәзер бөтенләй сизелми.

Фарсы теленнән кергән *сәүдә, сәүдәгәр, шәһәр, бәхет, бичара, пөхтә, рәвеш, каһарман, начар, гәүһәр, һөнәр* кебек сүләр дә телебезнең үз сүзлек байлыгына әйләнеп киткән.

Һәрбер телнең үзенә генә хас үзенчәлекләре булганга күрә, алынмалар кабул ителгәндә, алар еш кына төрле үзгәрешләр кичерәләр. Алынмаларның үзгәреш дәрәҗәсе кайсы чорда һәм ничек кабул ителүгә нык бәйле. Әйтик,

телебезгә элегрәк һәм сөйләм теле аша килеп кергән алынмалар, язма тел аша кергән сүзләр белән чагыштырганда, бик зур үзгәрешләргә дучар булганнар. Аларның күбесе татар теленең артикуляцион үзенчәлекләренә җайлашканнар: сингармонизм законына буйсынган (мәсәлән: пинҗәк, әбәт һ.б), ике тартык янәшә килгән урынга сузык аваз өстәлгән (мәсәлән: эшләпә, эскәтер, бүрәнә һ.б) һ.б. Соңгы еллардагы алынмалар татар теленә үзгәртелмичә дип әйтерлек кабул ителә (мәсәлән: инстограм, бургер, роллы, чипсы, һ.б).

Татар теленә дә, рус телендә дә кулланылыш өлкәсе ягыннан сүзләр билгеле бер төркем, билгеле бер сөйләштә генә кулланылучы сүзләргә бүленәләр.

Татар телендә дә, рус телендә дә диалекталь лексика, ягъни аерым төбәк, сөйләмгә генә хас булган сүзләр (әлеге төр сүзләр татар телендә урта (Казан-татар), көнбатыш (мишәр) һәм көнчыгыш (себер-татар), ә рус телендә-төньяк, көньяк һәм урта рус диалектларына бүленәләр, һөнәрчелек лексикасы (рус телендә “профессионализмы”), ягъни аерым һөнәр ияләре генә куллана торган сүзләр (мәсәлән: табиблар лексикасы, химия белгечләре лексикасы һ.б) һәм арготик (жаргон) лексика (рус телендә-“жаргонизмы”), ягъни уртак максатлар белән бергә вакыт үткәрүче бер төркем кешеләр сөйләмендәге аерым сүзләр. 20 гасырда иҗат ителгән әдәби әсәрләр әле алардан башка гына укучысына килеп ирешсә, 21нче гасыр әдәбиятына алынма сүзләр ургылып керә. Хәзерге әдәбият алынма сүзләрдән генә языла дисәм, бер дә ялгыш булмас.

Мин кечкенә генә авыл мәктәбендә эшлим, еш кына укучыларыбыз телендә жаргон сүзләр ишетергә туры килә. Аларның күбесен мин аңлап та бетермим. Моңа гаҗәпләнергә дә юк. Балалар көне-төне интернет челтәрендәге төрле төркемнәрдә утыралар. Шунысы игътибарга лаек, яшьләр сөйләмендәге жаргон – интернациональ күренеш. Әмма аны төрле милләт вәкилләре төрлечә аңлата. Мәсәлән, Сергей Образцов болайрак фикер йөртә: “...Яшьләрдә жаргон куллану ихтыяҗы каян килә? Минемчә, бу – олыларның штамп белән тулы килбәтсез теленә үз сөйләмнәрен каршы куярга омтылу. Без инде күп нәрсәне калыпка салдык, ә яшьләр әле өлгермәгән... Чын уең,

мөстәкыйль фикерең булмаганда штампка ябышасың, беренче эләккән формуланы аласың да шуңа иярәсең. Ә яшьләр аерылып торган, яңачарак сүзләр эзли. Әлбәттә, миңа яшьләр жаргонының күпчелеге ошамый, чөнки алар асылда әдәби нормага каршы куела. Арада килбәтсез сүзләр күп. Әмма шул ук вакытта яңача, көлке, иҗат очкыны кебек сүзләр дә җемелдәп китә...”

Монда тагын шуны да билгеләп үтәргә кирәк: элеге төркемнәргә керүче сүзләр арасында даими үзгәрешләр булып тора. Еш кына нигездә икенче төркемдәге сүзләр гомумхалык лексикасына күчеп тора. Бу- сүзлек составындагы туктаусыз үзгәрешләр баруын раслаучы күрсәткеч.

Икенче телләрдән алынган сүзләр алучы телнең сүзлек составында үзләренең элгәреге күренешләрен еш кына төгәленчә саклап тора алмыйлар. Алучы тел аларны үз законнарына җайлап үзләштерә: алынмалар күбесенчә фонетик һәм морфологик үзгәрешләргә дучар булалар. Ишетү юлы белән генә кереп үзләшкән сүзләр аеруча зур үзгәрешләргә очраучан була.

Рус теленнән алынма сүзләрнең үзләштерелүе бүген генә түгел, ә Бөек Октябрь социалистик революциясенә чаклы татар теленең үз фонетикасы нигезендә кулланылып килде. Боларның да борынгырак катлавы, аеруча ишетү юлы белән үзләштергән өлеше, татар телендә тирән фонетик үзгәрешләр кичергән. Әдәби әсәрләрдә рус телендәге борозда сүзен буразна рәвешендә, бревно сүзен бүрәнә, стол сүзен өстәл, озим сүзен уҗым, очередь сүзен чират, солома сүзен салам рәвешендә очратабыз.

Рус теленнән алынма исем төркеменә кергәннәре хәзер, кагыйдә буларак, рус телендәге берлек санында һәм баш килеш формасында барлык элементлары белән алынсалар да, сөйләмдә контекст таләп иткәнчә төрләндерелергә кирәк булганда, татар теленең үз формаларына салыналар, хәтта рус телендә сан һәм килеш белән төрләнми торган сүзләр дә шушы законга буйсыналар: инстограм- инстограмны, инстограмның, инстограмда һ.б.

Сыйфат һәм рәвеш төркеменә кергән сүзләр исә, кагыйдә буларак, русча сыйфатлык һәм рәвешлек билгеләре ташланып, кыскартылган формада

алыналар. Мәсәлән, рус телендә революционный, революционная, революционное, революционно шулай ук практический (ое, ая), практически формаларында кулланылган сүзләр хәзерге татар әдәби телендә революцион, практик рәвешендә кулланыла.

Шул рәвешчә, икенче телләрдән сүзләр алганда, татар теле ул сүзне һәрвакытта да элгәреге, ягъни туган телендәге, формасында ук үзләштерми, аларны ул теге яки бу дәрәҗәдә үз теле законнарына җайлаштыра, һәм алар шул процесста кайбер фонетик, морфологик үзгәрешләр кичерәләр.

Рус телендә дума сүзенең өч төрле мәгънәсе бар:1) уй, уйлану; 2) Украина халык җырларының бер төре; 3) закон чыгару яки идарә итү өчен сайланган вәкилләрдән торган җыелыш-буржуаз учреждение. Татар әдәби телендә дума сүзе шушы соңгы мәгънәсе белән генә кергән: дәүләт думасы, шәһәр думасы һ.б.

Һәр телнең үзенә генә хас үзенчәлекләре була. Шуңа күрә алынмалар, кабул ителгәндә, мәгънә ягыннан да, фонетик һәм грамматик яктан да үзгәреш кичерәләр. Мәсәлән, рус һәм татар телләрендәге авазлар арасында шактый зур аерма булганлыктан, рус сүзләре, татарчага кабул ителгәндә, иң беренче чиратта аваз ягыннан үзгәреш кичергәннәр. Алынмаларның үзгәрү дәрәҗәсе кайсы чорда һәм нинди юл белән кабул ителүгә бәйле. Борынгырак алынмалар фонетик яктан күбрәк үзгәрсәләр, соңрак кабул ителгән алынмалар нигездә үзгәрмәгән.

Сөйләм теле аша кергән алынмалар зуррак узгәрешләргә дучар булганнар. Язма тел аша кергәннәре кимрәк дәрәҗәдә үзгәргәннәр яисә бөтенләй үзгәрмәгәннәр. Борынгырак чорда сөйләм теле аша кереп, төрле узгәрешләр кичергән алынмаларга мондый сүзләрне кертергә мөмкин: җәл, шәл, эскәтер, кәбестә, каравам, пумала, сумала, салам, мунчала, фатир, мич, кесәл, ситсы, буразна, ызба, әбәт, чегән, пинжәк, эшләпә, бүрәнә, арыш, уҗым, камыт, өстәл.

Шулай итеп, әдәби әсәрләрдә килеп чыгышы ягыннан без өйрәнә торган татар һәм рус телләренең сүзлек составында түбәндәге охшаш һәм үзенчәлекле билгеләр күзәтелә:

- бу телләрнең сүзлек составында төп өлешне алынма сүзләр тәшкил итә;

-татар телендә рус алынмалары һәм рус теле аша кергән башка тел сүзләре зур урынны алып тора. Шул ук вакытта рус телендә дә татар теле һәм чит телдән кергән сүзләр бар. Әлбәттә, аларның саны әлегә татар телендәге рус алынмаларыннан кимрәк. Әлегә...

МАТЕРИАЛНЫ ЯЗГАНДА ТҮБӘНДӘГЕ ЧЫГАНАКЛАРДАН ФАЙДАЛАНДЫМ:

1. Ахунзянов Э.М. Русские заимствования в татарском языке.-Казань: Изд-во Казан ун-та, 1968

2. Рамазанов Ш.А. Татар теле буенча очерклар. -Казан: Тат.книг.издат., 1954.-Б.107-120

3. Сафиуллина Ф.С. Ике телне чагыштырып укыту // Мәгариф.- 1996.-№3.

4. Сафиуллина Ф.С. Хәзерге татар әдәби теле: Лексикология. -Казан: Хәтер, 1999.

5. Җамалетдинов Р.Р. Татар һәм рус телләренең чагыштырма грамматикасы: Дәреслек кулланма. -Казан: КДУ нәшр., 2004.- Б. 32-37.

Назад